# Казан УТЛАРЫ

СЕНТЯБРЬ

№ 9

1965

## *ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!*

Журналның сыйфатын тагын да яхшырту теләге белән, „Казан утлары“ редакциясе Сезгә түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итә һәм журнал турындагы фикерләрегезне, тәкъдимнәрегезне язып җибәрүегезне үтенә.

1. „КАЗАН УТЛАРЫ“н („Совет әдәбияты“н) күптән укып киләсезме? Журналны яздырып аласызмы, әллә китапханәдән алып укыйсызмы?

2. Соңгы ике елда журналда чыккан материаллардан (проза, поэзия, әдәби тәнкыйть, очерклар һ. б.) кайсылары Сезгә күбрәк ошады?

3. Нинди әйберләр Сезгә ошамады һәм ни өчен?

4. Киләчәктә „КАЗАН УТЛАРЫ“ журналы битләрендә нинди материаллар укырга, нинди темалар яктыртылуын күрергә теләр идегез?

5. Журналның сыйфатын яхшырту буенча нинди тәкъдимнәрегез бар?

6. Профессиягез, яшегез.

Җаваплар өчен безнең адрес: *Казань, Баумана, 19, Дом печати,* редакция журнала „КАЗАН УТЛАРЫ“.

# Казан
# УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
*КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

СЕНТЯБРЬ **9**

РЕСПУБЛИКА ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАРЫ НӘШРИЯТЫ
КАЗАН 1965

## Бу санда:

### РОМАН, ШИГЫРЬЛӘР

Ә. Давыдов. Яңа шигырьләр . . . . . . . . . . . 3
Ш. Маннур. Муса. Роман . . . . . . . . . . . . . 13
З. Мансур. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . 86
Н. Хәмзин. Соңгы сый. Хикәя . . . . . . . . . . . 92

### ОЧЕРКЛАР

Р. Мостафин. Җирдә эзең калсын. . . . . . . . . . 98

### БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. Галиев. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . 106

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Н. Юзиев. Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән. . . . . 112

### ЯН РАЙНИСНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Я. Райнис. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . 125

### Т. ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Т. Гыйззәт. Уйларым һәм хисләрем — халык белән. Хатлар. . 131

### ИСТӘЛЕКЛӘР

С. Әдһәмова. Галимҗан абый һәм аның белән узган көннәр турында. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. Хәмидуллин. Кирәкле һәм файдалы китап. . . . . . 144

### УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

Хатлардан юллар. . . . . . . . . . . . . . . . 150
Г. Кашшаф. Леон Небенцаль Казанда . . . . . . . . . 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . . 156
Җ. Фәйзи. Гөлшаһидә жыры. Г. Әпсәләмов сүзләре. . . . 160

*Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый.*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана 19, Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 52. Редакция «Казан утлары».*

*Энвәр Давыдов*

## Казанга чакыру

Килегез, дуслар, Казанга!
Чакыруым сезгә җитсен өчен
Ничегрәк мактап язарга?
Юк,
монда
оста челтәрчеләр кулы үргән
ажурлы манаралар юк.
Даһи рәссамнар мәңге бизәп киткән
мәрмәр сарайлар юк.
Ят җирләрдән кайткан могҗизалар,
җиз баганалар юк.
Мактанмамын сезгә күрсәтеп мин
баскычланып югарыга ашкан «Сөембикә»не дә.
Бизәкләрен яңартып купшыланган
иске чиркәүне дә.
Әйдәгез,
иртүк үтик әле бер
уйчанланып
тын урамнардан.
Керик
сабыр гына карап торган
гади йортларга.
Узыйк
адымнардан ашалып беткән
иске баскычлардан.
Менә бу баскыч ташының тузаннары
җитез Ульяновның аягына
ияргәннәр
һәм иске дөньяны җимергән бөек давылда
өерелгәннәр.
Менә бу стеналар
Лобачевский миендә туган
искиткеч геометрик сызыклар энергиясен
саннарның сихри көчен
кабул иткәннәр.
Яңа буыннар
еллар һәм планеталар аша
шуны яңа чорларга
һәм яңа галәмнәргә илтәләр.
Менә икенче университет.
Шунда —
карсак таш өйнең подвалында,
апара парларында
алган белеменнән

Горькийның
күп томлы
Тормыш фәне китаплары
дөньяга килгән.
Менә бу йортта
үзенең ятимлек янчегән
юка күкрәгенә
халыкның бар моңын,
хәсрәтен, нәфрәтен
сөюен сыйдырган
Бөек Тукай
үпкәсеннән тамган кан ялкыны белән
таш идәнне уйдырган.
Ә бу йортның стеналары
аның соңгы сулышын тыңлаган.
Анда хәзер Казанның яңа гражданнары беренче сулышны ала.
Алар беренче ишеткән авазга —
аналарының пышылдавына
бәлки Тукай сулышы да кушылып ишетеләдер һаман,
шуңа буыннан-буынга артадыр
халыкның мәхәббәте Тукайга.
Менә бу тоташ пыялалы
соры йортта
Җәлил белән бер «банкет»та
фашизмны җиңү хөрмәтенә
чәйле бокалын күтәргән
һәм татар дусты белән
бер телем арыш ипиен бүлгән
Җованни Җерманетто.
Ишетәсезме,
монда әле дә җырлар яңгырый.
Ишетәсезме,
алар иңри —
алар Моабитта тоткын булганнар.
Ишетәсезме,
алар әрни —
алар, канга туза-туза,
чәнечкеле чыбык аша
концлагерьлардан
иреккә омтылганнар.
Ишетәсезме,
алар тантана итә —
алар җиңү тәмен татыган.
Ишетәсезме,
алар гөрли —
тыныч хезмәт шатлыгы
һаман артудан.
Әйдәгез хәзер
шаулы урамнарга,
Идел ярларына!
Мин яхшы беләмен,
Бу җырлар белән сез
яхшырак күрерсез
Казанның ямен!
Күрәсезме,
диңгез кояшта ничек балкый,
ефәк кебек,

күзне чагылдырып-чагылдырып ала.
Ә менә тегендә,
мехкомбинатның тәбәнәк корпуслары
эчендәге ярларда
дөнья ярминкәләрендә чибәрләрнең күз явын алган
мех дулкыннары елкылдап ага.
Әнә портыбыз.
Бәхетебез кебек —
күпме төс балкый анда!
Ә нинди ажурлар
андагы мең кранда.
Күрәсезме,
нинди мәһабәт кораблар!
Безнең машиналарны,
мехларны,
китапларны,
хисләрне
диңгезләр,
океаннар аша
кырык илгә алып баралар.
Утырыгыз, дуслар, шул корабларга,
Килегез, дуслар, Казанга!

1964.

## 9 май 1965 ел

Кичерегез.
Күземә чыккан бер тамчы яшь минем
сәер ялтырый бәйрәм яктысында.
Чү, тыңлагыз, күпме иптәшем җавап бирми бүген
тантаналы барлау вакытында.
Действительныйда каршы алып
бу сугышның беренче көнен,
безнең буын бөтен брестларда
беренче сулады сугыш төтенен.
Фашизмның сугыш машинасы
аның күкрәгенә бәрелде.
Киртә булып ятты Мәскәүгәчә
гәүдәләре яшьтәшләремнең.
Сталинградта атакага күтәрелеп,
алга таба карап, гөрс итеп
ауды, ләкин аның кулы ябышты
Рейхстагның бугазына җитеп...
Арган аналар,
битләрен җил кискән сөйгән ярлар,
әрем баскан кырлар,
саламнары коелган түбәле карт өйләр —
болар да
безнең буынны көтте
хәл алырга,
солдат күкрәгенә елышып еларга.
Мөмкин бүген ул елларның хаталарын,
кимчелекләрен дә эзләргә.
Ә без таңнан торып бригадага бардык
күтәрәмгә калган атларны

иске сабаннарга җигәргә
һәм буразнада атын да,
сабанын да үзебез сөйрәргә...
Менә шулай алып килдек илне
күпләр кызыначак җылыга.
Ләкин менә хәзер
авыр күтәрүдән җене өзелгән батыр кебек
яшьтәшләрем минем егыла.
Таза имән кебек ава тора —
давыл өзгән гүя тамырын.
Бер юбилей күрми китеп барды
Шәраф дустым, дустым Гамирым.
Тирә-якта шаулый яшь имәннәр,
карт имәннәр горур шыгырдый.
Миндәй урталары нигә сирәк?
Буш төп күреп тәннәр чымырдый.
Эш киеренкелегеннән
бераз арындыкмы, чир сагалый,
больница чиратында
анализлар кулга җыябыз.
Тукта, өзелеп-өзелеп
ютәлләмә болай, Зыя дус!
Әнә мәхәббәтебез дә безнең чиратта.
Кырык яшьтә төсе уңган. Какчаланган. Чалланган.
Аңардан бүген нәфислекме сорыйк?
Орлык ташыды, салам ташыды ул,
ат урынына җигелеп чанага.
Яшьлекне күрмәде, картлыкка җайлашалмый бу буын.
Ирлек булды бөтен тормышы.
Китә, пенсиягә җитә алмыйча,
бакчаларда
гамьсез яллар өчен
Верандалы йортлар салмыйча...

## Дәһшәт

(Булган хәл)

Танк тора Лондон янында —
фашистныкы төсле тәреле.
Кырда үскән гөлләр тәнендә
чәнечкеле чыбык әрнүе.

Киноларда — кеше үтереп,
хайван һәм кол санап адәмне,
бозыклыклар эшләп, типтереп,
йөри изге Доллар әфәнде.

Мәктәпләрдә исбат ителә
прогрессның һәлакәтлеге.
Шундый хәлдә алда ни күрә,
кая омтыла бала хәтере?

Йөдәп өметсезлек-сагыштан,
бер вакытны Темза ярында
очрашып, дүрт малай ярышкан
батырлык һәм үлем хакында.

Аллан, Берди, Дэвид һәм Ричард
бәхәсләшеп куя шундый шарт:
атылып килгән поездга каршы
кузгалмыйча торырга басып!

Йөрәкләргә соңгы ут каба,
куркынудан йөзләр бозылган.
Атылып килгән поездга таба
Сигез нәни йодрык сузылган.

Мәрхәмәтсез металл күкрәге
белән сытып бала гәүдәсен
үтә поезд, канлы үләнгә
бер минутка төшереп шәүләсен.

Ах, ямьсез шул үлем үены,
тапаган ул аяк-кулларны.
Юкка көтә ана куены
баласының кулы сарылуын...

Танк тора Лондон янында.
Фашистныкы төсле тәреле.
Кырда үскән гөлләр тәнендә
чәнечкеле чыбык әрнүе.

Мәктәпләрдә исбат итәлә
прогрессның һәлакәтлеге.
Шундый хәлдә алда ни күрә,
кая омтыла бала хәтере?

Аңлыйсыңмы икән, инглиз,
нинди дәһшәт килә өстеңә,
сабыйларның бозып күңелен,
үлем юлларына өстерәп?

Аңлагыз сез, аңла, балалар —
Алланмы сез, Дэвид я Ричард;
Батырлыкның башка исеме бар:
Төзүче. Тикшеренүче. Космонавт!

1960.

*
* *

Соңга калган яз. Тау-тау кар. Янәшә —
асфальттан күтәрелә җәйге кайнар рәшә,
газоннар сыртыннан яшеллек тырпая,
чокырда зәңгәрләнеп җепшек кар мүртая.
Кешеләр киемендә нинди чуарлык:
мамык шәл, капрон шәл, французча яулык;
кышкы тун, көзге чикмән, җәйге җилән;
ефәк косынка, назланып, качмакчы салкын җилдән, —
кояш нурлары гына аны иркәләп тынычландыра.
Кыш барыбер үлем куркынычыннан аңгыра —
төнлә туңдырып җыя суларны,
үзен ашаучы яңа гөрләвекләргә ача юлларны.
Бу дөнья да, бер карасаң, шулай күренә:

Менә илләр чыкканнар азатлыкның кояшлы үренә,
һаман яшелләнә, матурая баралар,
ә кайберләре әле бозлы кар астында калалар.
Реакция төннәре туңдыра, кыса агымнарны,
тик иртән ул агымнар котырып ашый карлы ярны,
империализм кантарына казый базны...
Соңгарак калды планета язы...

1960.

*
* *

Ерак калган бер җыелыш минем истә:
Мәгънәсезлек хисе
шүрәледәй тенкәмне кытыклый,
күңелем бер куркынып китә,
бер —
тиледәй көлә, кыткылдый.
Син
торасың басып өстә:
— Ач син безгә пычрак эшегезне!
Штабыгыз кай төштә?
Әйт җитәкче кешегезне!
Синең бу шаяруыңа елмаеп,
күзеңә карадым, тутырып.
Ләкин анда елтырамый шаяру мае,
анда — ачу тутыгы.
Миңа да йоктымы шул тутыгың,
кинәт,
ачуым чыгып,
читкә борылдым...
— Карагыз, масса алдында үз-үзен тотуын!
Аңладыгызмы, — дидең, — дошман булуын?
Ышандылармы сиңа,
белмим.
Әкрен генә,
берәм-берәм генә
күтәрелде куллар.
Комсомол түгел мин.
Кудылар.
Чыктым. Дөнья шундый матур.
Яңа төзелештә биек краннар,
күктә гөрләп узган уннарча мотор,
бар да шул көнгә дан җырлап торалар.
Кара кайгым минем
көннең яктылыгын, аклыгын
ныграк чагылдыра.

...Ул еллар илнең үсү шатлыгы
белән минем күңелдә калдылар.

...Менә бүген тагын җыелыш.
Син тагын трибунада, өстә.
Йөзең чытып, кашларың җыерып,
буйыйсың ул елларны кара төскә.
Шул каралык күләгәсенә
үз мәкерлелегеңнеме яшерү өчен?

Ә мин ул елдан алам исемә
Москва каналының балкыган төсен,
яңа заводлар, төзелешләр биеклеген,
АНТларның куәтле гөрләвен...

Шул көннәрдән нур өстәлгәнгә күрә,
яктырак бүгенге көннәрем!

1964.

## Иделдә

1

Карталарда
син —
бер зәңгәр сызык.
Яр буенда коенганда —
просто рәхәт, кызык!
Ләкин...
Менә чыктым мин
пароходның палубасына.
Күрәм,
күкрәгең еш-еш күтәрелә,
тын алу сыман.
Күкрәгеңне куеп кояшка каршы,
сулыйсың,
дулкынланып,
ярсып.
Син — тере!
Минем кебек үк
синең җаның бар!
Тоям, сиңа да таныш шатланулар.
Сиңа да таныш
Көю-янулар.
Сөеклем, Идел!

2

Тик мин күрәм,
син баерак, Идел, миннән.
Синең картлыгың да,
яшьлегең дә үзең белән.
Әнә, кай җирләрдә
син карт төсле дә,
боек төсле дә:
эштән куылган татар хатынныкы кебек,
яшел бишмәтеңнән
ярларыңда
сары балчык бөселә.
Ә кай җирдә
син шундый яшь,
син шундый яшь күренәсең:
кыска күлмәк кигән бүгенге кыз кебек,
туры сызыклы бетон күлмәгеңнән
ялтыр тезләреңне күрсәтеп,
сикеренәсең!

3

Кума мине, Нина, каютка...
Анда җылылык та, тынлык та,
шома язган шигырь шикелле,
тәнне, җанны рәхәт оета.
Ләкин кума мине каютка,
Мин үзем дә яхшы аңлыймын,
көне буе җилдә җилләгәч
көчәясен кичен авыруның.

Күңелем минем, ярсуларны сагынып,
бүлмәләрдә бик күп тилмергән.
Җилдән куркып кына инде шагыйрь
ничек аерылсын Иделдән?

Кем туктатыр, әнә, дулкынны
ярга ярсып барган вакытында?
Дулкын дулкын инде ул. Ярга
бәрелә. Чәлпәрәмә ватыла.

Дулкын дулкын инде ул,
ярсу өчен
кайналып ул астан калыккан.
Шулай булгач,
кума мине, Нина, каютка.

1964.

## Җилдә агач яфраклары

Җилдә
сөйләшүдән
һич тыела алмый агач яфраклары,
бер туктаусыз сөйли алар —
кайчак — сикергәләп, канатланып,
кайчак — моңаеп, башларын аска иеп,
кайчак —
елап, сулыгып-сулыгып,
ә кайчакта — хәвефләнеп, ашыгып, өзгәләнеп,
агач ботагыннан өзелеп китәрдәй булып...

1962.

## Шәһәрдә явымлы ямьсез көн

Күк — карасу-күксел,
Өйләр — моңсу соры.
Таш өйләр кочагында
Дерелди
Яшь каенның зифа сыны.
Юеш керләрнең канаты
Бәргәләнә балконнарда.
Җылы
Кеше сүзе
Посып тора
Түбәдәге антеннада.

1963.

*
* *

Сиңа ничә яшь? — дип сорыйсың син.
Җавап бирәм:
— Унсигез яшь.
— Ә битеңдә тирән җыерчыклар?
— Аларга да унсигез яшь.
— Ә башыңда күпме чал чәчең бар!
— Аларга да унсигез яшь.
— Ә йөрәгең нигә тигез типми?
— Аңа әле бары унсигез яшь.
— Ярсуыннан арып туктаса ул?
— Күзеңә чыкса, шунда бер тамчы яшь.
Сагынып елмай:
— Аңа, — диген, — бары иде әле унсигез яшь...

1964

*
* *

Ничә тапкыр синең янга кердем,
Бик акыллы сүзләр сөйләдем.
— Тукта, әйт син минем сагынганны! —
Диде, ярсып типте йөрәгем.
Ләкин әйталмадым.

Бу минутта ара ерак безнең,
Шуңа артты төсле кыюлык.
Очрашканда тагын каушап калсам,
Сүз әйталмый, төшсәм коелып,
Аңла, аңла җаным.

Бер елмаеп кара күзләремә,
Уйнатып ал кара кашыңны,
Шул җитә бит миңа бөтенләйгә
Югалтырга җүләр башымны,
Шул җитә бит миңа.

1964

## Мин оныттым сине

Мин оныттым, оныттым инде сине,
Ничә еллар — кичке җилләр истеме,
Тәкрарлыймын эчемнән мин гел шуны:
«Мин оныттым сине,
Мин оныттым сине».

Мин оныттым бакчада язгы кичне,
Йөрәгемдә шул кич уянган хисне,
Күңелемнән тәкрарлыйм бер сабак төсле:
«Мин оныттым сине,
Мин оныттым сине».

Сагынудан, әрнүдән арды бәгырь,
Бушанып-тынып калган күңелем хәзер —
Шундый таш язып куелган бер кабер:
«Мин оныттым сине,
Мин оныттым сине».

1964.

* * *

Була шундый авыр чакларым да:
Кирәгем юк кебек дөньяда.
Шигырь язсам, кемгә хаҗәте бар —
Миндәй аны
ун,
йөз,
мең яза.
Халкымның да юлы ачык инде,
Үз бәхетен тапкан күптәннән.
Сугышасы юк кара көчләр белән,
Тукай кебек —
Кара каным савып үпкәмнән.
Кайберәүләр кебек гамьсез генә,
Бик үк бирелмичә уйларга,
Моңлы җырчы булып калыргамы,
Чәйле-мәйле төрле туйларда?
Моның өчен ләкин тавышым дорфа,
Җитми, диләр, аңа милли моң.
Кафияләр серен аңламыйсың,
Җитми, диләр, моңа гыйлемең.
Шигыремә кайбер гайбәтчеләр
Кыла төрле-төрле ырымнар.
Ситуацияләр шулай булгач,
Күңел төшәргә дә урын бар.
Ләкин... Хәтерлә син:
Көрәш дәрте
Арткан гына бөек шагыйрьдә
Төрле Тальниковлар [1] яла белән
Аны яралаган чагында.
Гамьсез җырлар җирне бассалар да,
Читкә селтәп алар дулкынын,
Көрәш өчен корал булырлык җыр
Эзләп суза эшче уң кулын.
Сиңа үрнәк:
ярминкәләр саен
Медальләрнең алтын-көмешен
Ала безнең туннар — кем онытыр
Шуңа кергән Такташ өлешен!
Тагын бу агитка язган, диеп,
Тәнкыйтьчеләр сөрән салсыннар.
Шигърияттем! Көрәш фронтында
Бул син корал тулы арсенал!

1957—65.

---

[1] Вакытында В. Маяковскийга карата урынсыз тәнкыйть белән чыккан тәнкыйтьче.

*Шәйхи Маннур*

# МУСА

## Роман[1]

### IX

Демблин дигәннәре Висла елгасының калку ярына корылган борынгы крепость булып чыкты. Аның биек таш коймалары һәм артында шомлы сер саклагандай калын, авыр капкалары, нычытманы тыш яктан әйләндереп алган тирән канауда су тулып торуы һәм кайтарма күперләр аркылы гына эчкәре узарга мөмкин булуы Мусаны бик гаҗәпкә калдырды. Әллә кайчангы урта гасыр пәһлеван сарайлары, патша, герцог цитадельләре, хәтта атаклы һәм хөрмәтле Дон Кихот Ламанчский сугышып йөргән заманнар күз алдыннан кичте. Эчкә узгач аның беренче соравы да шул хакта булды. Бу нычытманың «Әби патша» тарафыннан салдырылганын әйттеләр аңа. «Чынлап та, борынгы икән шул бу,— дип уйлады Муса.— Рус феодал империясенең Польшаны йота башлаган чорларында туган яман чир икән. Бездәге Зөя каласы... Сәер бит, Казан җиренә басып кергәндә, башкаласының борын төбенә китереп Иван Грозный иң элек нычытма корган, аннары Казан илен басып алган...»

Хәзер тирән тылда калган бу иске нычытманы Гитлер коллар колониясенә әйләндергән иде. Әсирләр каберлеге өчен бик уңай урын булып киткән. Биек коймалар өстенә чәнечкеле чыбыклар да корып җибәргәннәр, усал күзләр төшәрлек түгел. Шуңа күрә монда инде туксан алты мең әсир шешенеп, тиф бетләренә таланып һәлак булган диләр. Берәү дә күрмәгән, нәразыйлык күтәрмәгән...

«Беребез дә кайтмас, язмас микәнни?.. — дип пошынды Муса. — Юк, кайтырбыз, язарбыз, фаш итәрбез без аны! Дөнья белер! Тик Адольф үзе генә булмас, ул чакта күптән шакмараеннан асып куйган булырлар аны!..»

Кош аулаучылар бер үк читлекнең төрле бүлемтегенә төрле кош япкан шикелле, монда да милләтләрне төрле блокларга тутырганнар иде. Муса татарлар блогын эзләп китте. Аның кулындагы кәгазьләрдә Розенбергның үз имзасы һәм ОКВнең көнчыгыш бүлеге печатьләре булганлыктан, лагерь эчендә тоткарсыз йөри ала иде ул. Нычытманың эче шактый киң булып чыкты, Мусаны блок башлыгына илтүче немец солдаты байтак барганнан соң озынча бер такта барак янына килеп туктады. Аның бер башындагы ишеккә часовой баскан булса, икенче башыннан үзенең бөтен ыс, төтен, сөрем һәм черегән бәрәңге сасылары белән бергә кушылып кухня исе килә иде. Солдат штабның шул баракта икәнен әйтте дә үзе китеп барды. Муса өс-башын кардан каккалап торганда, аргы баштан олы гына чана тартып килүче кешеләр төркеме күренде. Алар якынайгач, часовой баскан ишектән бер ефрейтор җилтерәп чыкты да, төркемне туктатып, нәрсәдер тикшерергә тотынды. Тигез такта төпле ломовой чанасына, әрдәнә шикелле дүрт почмаклап, биек итеп үлекләр төялгән иде. Аларның як-яктан тырпайган шәрә аяклары һәм

[1] Дәвамы. Башы 5, 6, 7, 8 саннарда.

ялангач башлары туңадыр кебек тоела, кызгану хисе уята, һәм бигрәк тә, шул каны кипкән саргылт-ак аякларны нәрсә беләндер төрәсе килә иде. Ефрейтор әле һаман кычкырынуында, нәрсәгәдер бәйләнүендә булды. Аңа ниндидер кәгазьләр, калайлар күрсәттеләр. Шуннан соң гына ул берхәтле тына төшеп, җигелгән әсирләрнең берсен үзе белән ияртте дә конторга табан атлады. Аның артыннан килүче урта буйлы, куе кара кашлы егетнең өстендә таланып беткән кыска тун белән тез күзләре бүселеп чыккан сырма чалбар, аякларында әллә нинди алама чүпрәкләр белән урап кигән агач башмаклар иде. Март башыннан ук күтәртмә тагып чыккан малай шикелле, башмагы белән бозлавык сукмактан шакшок атлап килә ул һәм, озын борынын сузып, кухня ягыннан килгән кытыклавыч исне эченә җыя барган төсле күренә. Якынрак килеп җиткәч, Муса бу егетнең кара каш астындагы матур һәм үткен күзләре үзенә текәлгәнен сизеп алды. Ул ара да булмады, ябык һәм карт чырайлы бу егет куллары белән алга үрлеккәндәй итте дә:

— Муса абый! — дип кычкырып җибәрде.

Муса аптырап, аны таный алмыйча торганда, немец үз командасын биреп өлгерде:

— Һальт! Юлыңда бул, дуңгыз!..

Егет кинәт сүнде дә, иске-москылары эчендә бөрешеп, ефрейтор артыннан атлады. Шулай да аның күзләре Мусада иде әле: «Эх, танымадыгыз да... Әллә теләмәдегез инде...» диләр кебек иде. Алардан соң Муса да эчкә керде һәм, блок башлыгын табып, үзенә кирәк кешеләр турында сөйләште.

Блок башлыгы, кырыклар чамасындагы олы гәүдәле, кипкән сусән чәчле немец, сыек зәңгәр күзләрен кыса төшеп, башын кашыды.

— Мондагы блокта алар ун меңнән артык, әйе... артык... Ничек итеп, әйе, сезгә кирәкле шул ниләрне, музыкантларны, сайлап алырбыз икән?.. — диде, җансыз гына итеп. — Колоннага тезеп сорасак инде, әйе...

— Ун мең кешенеме, әфәндем? — дип көлде Муса, аның теләр-теләмәс кенә чыга торган сүзләрен бүлеп. — Кирәкми. Сез бу эшне үземә тапшырыгыз. Миңа бит бик әллә ни күп кеше түгел, мин аларны болай да сайлаштырып алырмын. Тик миңа бүлмә сымак бер урын гына табыгыз. Үзегез беләсез, ана телендә сөйләшеп, уйнатып карау кирәк ич... Һәм иң элек әнә шул баягы кешене китерсеннәр иде. Чөнки ул үзе дә миңа танышлыгын белдерергә теләгән шикелле тоелды.

Блок башлыгы, үзеннән югарылар белән сөйләшеп алгач, Мусага кабинетына янәшә буш бүлмәне тәкъдим итеп, өенә китте. Аның башы авыртынкырап тора икән, пирамидон белән кара кофе эчеп, бераз ятып торса, бәлки рәтләнеп тә китәр, бик авыр эш бит...

— Әйе, әйе! — диде Муса, аны хуплап ишеккә озата-озата. Ифрат авыр! Ярый, хушыгыз, әфәндем. Әйтә китсәгез иде, теге малайны китерсеннәр миңа...

Муса, үзенә билгеләнгән бүлмәгә кергәч, әлеге шомлы чана кинәт тагын аның күз алдына килде. Ул тәрәзә янәгына килеп сөялде дә тышка карады. Тилмереп үлгәннәр штабелен бөкрәеп, алга сузылып, җан газабы белән тартып баручылар шактый ераклашканнар иде инде. Мусаның, ниндидер күз сукрайткыч нәрсәгә караган төсле, каш өсләре сызлап үтте. Ул тиз генә читкә борылды да ачы чырай белән пышылдый башлады:

Эх, сез, шомлы әбием әкиятләре,  
Кая сезгә житү чынлыкны?!  
Сүз житәрме сөйләп аңлатырга  
Бу йорттагы вәхшәт, коллыкны...

Ишектә баягы егет күренде.

— Әйдүк, дускай! — дип, кинәт үзгәргән якты йөз белән каршылады Муса аны. Әмма теге егетнең баягы дәрте сүнгән иде инде.

— Чакыруыгыз буенча килдем... — диде ул, рәсми тавыш белән.

— Бая мин сезне танып җиткерә алмадым, — дип дәвам итте Муса, гафу үтенгәндәй. — Ялгышмасам, сез минем янга беренче мәртәбә Гаяз Мансур белән килгән идегез. Кырыгынчы ел бугай, икегез дә Бәрәңге педтехникумын тәмамлаган, вуз студентлары булырга йөрисез һәм икегездә дә бер кочак кайнар шигырьләр! Шулаймы? Ә менә исемегезне, асыгыз-кисегез, валлаһи хәтерләмим...

— Гайнан инде... Курмашев... — диде егет, бер дә кирәге булмаган нәрсәне әйткән шикелле генә, һәм бөкшәеп торуында дәвам итте.

— Менә, менә, Гайнан Кормаш! Тел очымда гына тора иде, — дип көлде Муса, имән бармагын сузып. — Утыр, дустым.

Егет икеләнеп калды. Бая булса, беренче күрү куанычы белән ул аны кочаклап үбәргә дә, «абыкаем, синең дә язмышың бу яклардамыни?..» дип, елап җибәрергә дә әзер иде. Ә хәзер әллә нәрсә шунда. Күңеленә әллә нинди ямьсез уйлар килеп туларга да өлгерде. Нишләп йөри бу монда?.. Билгеле, югарыдан, Берлиннан килгән инде ул... Күрәсең, урыны җайлыдыр. Өс-башы бик ыспай күренә, үзләре шикелле үлек чанасы да тартмый инде ул... Эх, дөнья! Шундый кешеләр дә диген, ә?..

— Я, ничек соң, монда да язгалыйсыңмы? — дип сорады Муса, аны йокысыннан уяткандай итеп. — Берлинда газета чыга ич...

— Туктагыз әле... — диде Кормаш, ниндидер тәвәккәл бер фикергә килгән кеше кебек, кайнар күзләре белән аңа карап. — Без бер ил кешеләре, бер халык балалары, кайчандыр без танышлар идек, бер фикердә булган кешеләр идек, хәзер шушы коллыкка дучар булып йөрибез. Бәлки сез?.. Мин белмим, көрешмәгәнебезгә дә әллә мең ел тагы! Сез олылар, без яшьләр. Шулай булгач, иң элек үз халкыбызның изге йоласын үтик әле, аннары теләсә ни булсын. Исәнмесез! — һәм ул, кайнар яшьләрен тыя алмыйча, Мусаны кочаклап алды. — Исәнме, Муса абый! Исәнме, безне кайчандыр поэзиянең серле бакчасына алып керүче! Исәнме, татар шагыйре!..

Мусаның да күз төпләре елтырый иде. Ләкин нечкәлеккә бирешмәскә, көләргә тырышты ул.

— Ай-яй, бик пафослы килеп чыкты бит әле бу! — дигән булды, теш тезмәләрен күрсәтеп. — Син болай бөтенләй камыр ясарсың кешене!.. Я, хәлләрегез ничек соң? Үлемне ничек алдыйсыз?..

— Менә хәзер инде: «сорауларга җаваплар!» — дип куйды Кормаш та, ачы елмаеп. — Берәү үлми, берәү көн күрми, дигән мәкальне күптән ишеткәнем бар иде, әмма шуның туп-туры мәгънәсен хәзер генә ныклап төшендем. Минем иптәшләр чебен урынына кырылып торалар. Ачлык та, канлы эч китү дә, күлмәкләрне өстери торган бет тудырган тиф та, тешләрне кыра торган зәңгелә дә — бары да чалгы белән егып кына баралар монда кешене. Ә мин шуларның кесә төпләреннән, култык асты яки чолгау араларыннан килеп чыккан бер сынык сохарине кимерәм. Шуның белән, үземнекен дә кушып, җан асрыйм. Фәкать шуның өчен генә «капут команда»га язылдым, һәм мин анда үзем генә түгел... Менә шулай алдыйбыз үлемне... Ә калганы — бар да фани... Язу, дисез. Шушы чума базында йөрәкләр куырылып үлгәч — нәрсә ул шигырь? Аның белән кемне уятасың да кемне юатасың?.. Ә газетагыз... Бик йомшак кына итеп әйткәндә, нитим өстенә, Муса абый. Без аны укымыйбыз. Нигә кирәк шайтан шулпасы? Безгә аны монда болай да чиләкләп чөмертәләр!

Бу егетнең шушы хәтле ачы сүзләреннән Мусага мондагы хәлләрнең нинди булуы бик яхшы аңлашылды. Чөнки ул боларның һәммәсеннән үзе дә үткән. Лагерь эченә кереп, тирә-якка бер күз салу да җитә: нихәтле халык әрәм була! Ә шуларның гомерен саклап булса бит, сугыш беткәч өйләренә кайтыр иде, ил кешесе булыр иде алар...

Муса, бу егетнең каты сүзләрен бөтенләй ишетмәгәндәй, шактый гына уйланып утырды да:

— Кемнәр бар соң монда? — дип сорады. — Музыкантлар, җырчылар, берәр артист халкы юкмы арагызда?

Егеткә бу сорау бик сәер тоелды: әҗәл капчыгында нинди сәнгать тә, нинди артист тагы?.. Монда бер генә көй патша ич...

— Чын артистларны белмим, әмма хәзергә атказанып өлгермәгәннәрен табарга булыр иде, — дип җавап бирде Кормаш. — Фәхри Димски белән Зиннәт Хәсәнов «аяк сузу» көенә ярыйсы гына әйттереп җибәргәлиләр кайчакларда. Солтанай Фәритҗанов дигән егет, иске фанердан үзе мандолин ясап, шул ук көйне чиртә кебек. Рушатов та, мин эскрипкәдә уйныйм, дигән була...

— Ә шуларның барысын да җыеп китереп буламы?

— Ник булмасын? Шефблок команда бирсә, үзем үк табып китерәм мин аларны.

Муса, күрше бүлмәгә чыгып, блок башлыгын сорады. Баягы ефрейтор аның адъютанты икән. Кеше чакыруны үзлегеннән генә дә эшли алачагын әйтте һәм шунда ук, ишек ярыгыннан күзен акайтып:

— Алып кил барысын да, — дип кычкырды Кормашка. — Шнелль!

— Айн момент! — дип җавап бирде Гайнан, китәргә җыенып. — Муса абый, монда Батталов дигән бер шагыйрь дә бар диләр, аны да эзләп алып килимме?

Муса чәчрәп төшкәндәй булды:

— Ничек? Батталов? Дөрес әйтәсеңме? Бар, йөгер тизрәк, иң элек аны тап һәм монда җибәр!

Гайнан кош булып очты. Ә Муса, кинәт шулай дулкынлануыннан хәтта урынында утыра алмыйча, ишекле-түрле йөри башлады. Неужели Салих Баттал монда? Ул бит Ерак Көнчыгыш авиациясендә иде, японнарны саклап калган иде. Димәкки, бу якка ташланырга да һәм әсир төшәргә дә өлгергән була инде...

Көткән кеше тиз килми дигәннәр. Муса да Батталны көтә-көтә тас булды. Теге ефрейтор аны, аттестаты буенча кухняга чакыртып, ашатып та чыгарды. Шуннан соң гына, бервакытны, бүлмә ишеге төбенә хәтле ачылып китте. «Чынлап та, Баттал! — дип уйлады Муса. — Ул парашют машы да шулай ишекне төбенә кадәр каерып ачып керүчән иде бит...» Ишеккә сыймастай керүче үзе күренде: аның башында уңып, җәмшәеп беткән кубанка, өстендә сизерәп калган иске шинель, аякларында немец индустриясенең иң соңгы казанышы булган шул ук агач башмаклар, бу кешенең аксаклап атлавы аркасында, бигрәк тә тигезсез һәм ямьсез тавыш чыгаралар. Муса аның уртачарак буйлы һәм битләре сипкелле булуына да игътибар итте. Ул аны танымады, чөнки бу Салих Баттал түгел иде. Әмма шул ук вакытта күзләренең чепиләнебрәк торуында, аскы иреннең, бөрмәсе сүтелгәндәй, кинәт салынып төшүендә Батталга хас ниндидер чалымнар барлыгын да күреп алды. Ә кубанкалы кеше аны керә-килешкә үк танып:

— Исәнме, Муса абый! — дип кычкырды һәм, аксый-аксый алга килеп, аның кулын кысты.

— Исәнме, туганкай, — диде Муса, уңайсызланып. — Ә мин сине танып бетерә алмадым әле.

— Ник, Габдулла бит инде. Сәлих әбзинең энесе! Онытыпсын дамы? Татбаш дивизиядә хезмәт иттем, үзеңнең янына да шылай бер җәйне килеп цыкканым бар, Союзыгызга, этәм...

— Ә-ә, искә төштең хәзер! — диде Муса, яшь кенә, җилкенчәк кенә табигатьле, беркатлы, гади һәм эчкерсез сүзле солдат егетне күз алдына китереп. — Хәтерлим хәзер, әйе!.. Шулай итеп, син Салихның энесе булып чыктың. Ә соң аның үзе дә монда диләр ич...

— Китана-ан! Нишләп монда булсын ул? Җүләрмени Сәлих!

— Һе, җүләрләр генә әләгәме?

— Төгел, кәнишне, ә шылай да миннән акыллы берцәк кенә... Сәлих абый Дальни вастукта!

— Ә миңа Гайнан Кормаш әйтте ич, шагыйрь Батталов та монда, диде. Һәм мин аны чакыра җибәрдем.

— Хә-хә-хәй! Мин утырттым аларны! — диде егет, рәхәтләнеп көлә-көлә. — «Шагыйрь Баттал мин булам!» дидем. Ышандылар, тинтәкләр. Үзем бик важный гына йөргән булам. Бу фриц дигәннәре дә, каз шикелле муенын борып, борнын сузып баккан була минтаба. «Бакгыз, бакгыз, мәтәм, лейтенант абзагыз үзен танытыр әле сезгә!..»

Муса үзенең бу алдануыңа үкенмәде. Киресенчә, мәзәк бер хәл генә булып чыкты ул. Үзе коллыкта йөрү дә бик җиткән ич...

Чакырылган кешеләр берәм-берәм килеп беттеләр. Муса алар белән «Гумеров» дип танышты. Үзенә аптырап караган Кормашка күз кысып ымлап, шулай кирәклеген аңлатты. Ә Габдулла Батталовның моңа исе китеп тә тормады: «Шылай кирәк, кем икәнен цуртым да белмәсен!» — дип уйлады.

Муса барысының да сәнгать, әдәбият өлкәсендәге һөнәрләре белән кызыксынды, һәм шул уңайда, егетләрнең үзләренә сиздермичә, сугышта чакта кем булуларын да сораштыргалады. Башлап Габдулла сөйләп китте.

— Мин Доватор кавалеристы, белсәгез әгәр! — дип җибәрде ул. — Фрицләрнең, әй боларның дигәнем, утлы божрасын Руза ягыннан танклар белән бергәләп өздек тә, әй кереп киттек, атакаем, тылларына, әй чабабыз яшендәй кылычларны айкап; әй ярабыз йелкә тамырларын, әй туныйбыз курыйк төпләрен! Күз дә ачтырмыйбыз үзләренә! Прифронтовой рейд диләр моны, деморализация тыла! — дип тә җиффәрәләр. Мына шында инде катып калган минем аяк бармаклары, кар өстендә, батинкә этчендә, үзем ранит ителгәч дип әйтәм... Да, барые, кәбәм, йөрегән чаклар!..

Габдулла тәэсиренә ияреп, калганнар да үзләренең сугыш тормышындагы серле пәрдәләрен аз-аз гына ачкалап куйдылар. Мусаның эчтән генә сынавынча, берәүнең дә астыртынлыгы, шикле нокталары сизелми иде.

— Сез барыгыз да һәйбәт егетләр икәнсез, — диде Муса, сүзнең кыен өлешенә күчеп. — Кайсыгыз уйный, кайсыгыз җырлый, кайсыгыз бии, бик матур итеп сөйләүчеләр дә бар икән. Кыскасы — үзегез бер концерт, бер коллектив икәнсез. Ләкин монда кемгә күрсәтә аласыз бу һөнәрегезне? Ә менә легионның өченче батальонында мәдәни көчләр, музыкаль капеллада эшләрдәй кешеләр җитми...

— Легионда?

— Татар легионындамы?

— «Идел-Урал» дигән бардактамы? — дип, менә хәзер үк боттан чукып алырга килгән ата казлар шикелле муеннарын сузып, берьюлы ысылдады егетләр. Фәритҗанов дигән карарак чырайлы егетнең күзләрендә аеруча зәһәр очкыннар күренде.

— Сез безне кем дип торасыз, әфәндем?! — дип кычкыра язып, пышылдады ул. Гайнан аңа тилмереп карап куйды, нидер әйтергә теләде, ләкин тыелып калды. Күрәсең, ул аның дусты иде, Муса да аның белгән кешесе. Ул аларны яхшылап таныштыра алмады, ә хәзер менә нәрсә килеп чыга...

— Юк инде, сатылмыйча гына үлсәк иде... — дип куйды тагын берсе.

Арада яшьрәк күренгән Димски дә, кысык кара күзләре белән беркатлы сымак хәйләкәр көлемсерәп, сүз кыстырды:

— Минем әби сөйли торган иде, — дип башлады ул. — Иблис ләгыйн әйтер икән ди: телисезме, мин сезгә оҗмахны, бөтен байлыклары белән, бөтен хур кызлары вә җегетләре белән шушы җир өстенә алып төшеп

бирәм, дир икән, әмма ләкин шулар өчен иманыгыз белән җаныгызны миңа бирерсез дип әйтеп әйтер икән... ди торган иде... Карале, кем, ни, абзый кеше, сез шул Иблис дигәннәреннән илче-фәлән булып килмәгәнсездер лә?.. Мин үзем туганнан бирле бисфартийни кеше булганлыктан, ялгыш сүзләр ычкындырып ташлаган булсам, гафу иткәйсезләр...

Барысы да ширлекле тавыш белән көлешеп алдылар.

Муса бу мәсьәләнең шушылай төпкә килеп төртеләчәген алдан ук сизгән иде. Нишләргә соң, шайтан алгыры! Болар бик куркып сөйләшмиләр бит, көчле аргументлар кирәк монда! «Юк, иптәшләр, мин сезне көрәшкә, ирекка чакырам!» дип кычкырып булмый лабаса... Ул байтак уйланып утырды, тегеләргә кушылып, үзе дә елмайган төс чыгарды, хәтта кайсыннандыр алып бер-ике тапкыр тәмәке суырып та карады. Ниһаять, кыен урында су аркылы сикерүнең әмәлен тапкандай, яңадан сүзгә кереште:

— Алайса мин дә сезгә Гыйльми әбиемнең бер әкиятен сөйләп карыйм әле, — диде ул, Димски көлдерүгә тәмам тынгач. — Борын-борын заманда, кәҗә куманда, үрдәк урәтник, саескан сотник, карга шутник, торна плотник булганда, яшәгән ди бер патша Сабаҗил каласында. Булган ди аның өч улы, иң сөйгәне — кече улы. Олысы булган ди Умыран, уртанчысы — Тукыран, ә кечесе — Йомыран... Сез көлмәгез, мин үземнән чыгармадым бу исемнәрне, Гыйльми әби шулай сөйләде. Бер заманны патшаның үләр көннәре җиткән. Улларын янына җыйган да васыять әйткән. Менә, дигән, патшалыгымны кап өчкә бүлеп, өчегезгә тапшырам. Тату гомер итегез, дигән, һәм үлеп тә киткән. Билгеле инде, патшаның өч малае — өч калай этәч, тату яши аламыни ул: араларында сугыш чыккан. Олысы тоткан да, боларның җирләрен басып, хатыннарын тартып алган, үзләрен богаулап зинданга салган. Кул-аяклары зынҗырлы, кыймылдар әмәлләре дә юк боларның. Ай яталар, ел яталар, әмма котылу юлы бер дә күренми. Бер савыт су белән бер телем икмәк кенә бирә икән боларга Умыран. Йөзтүбән ятып, елый да елый икән Йомыран. Ә Тукыран һаман тәрәзәгә ыргыла, зынҗырларын ташка бәреп өзмәкче була, — ничек тә котылырга тели икән.

— Һи-и, булмый инде ул, өзгәләнмә юкка-а, — ди икән төпчек малай, — чыгалмыйбыз инде без...

— Юк! — дигән Тукыран. — Чыгам мин моннан, чыгам! Ирек бит анда, ирек! Якты дөнья, кояш нуры, кошлар, чәчәкләр, йолдызлар! Сөйгән ярың!..

Шулай дигән дә, төнлә белән Йомыран йоклагач, Умыран патшаның вәзирен чакыртып, пышын-пышын гына үз гозерен әйткән...

Иртәгесен Йомыран уянса, Тукыраннан җилләр искән!

— Ах, имансыз! — дип кычкырып җибәргән кече малай, гаҗәпкә калып. — Шул кара дошманга баш игән икән!.. Юк, мең тапкыр юк — миннән булмый... Шушында зиндан кортлары кимереп бетерсен, әмма үземнең саф вөҗданымны пычратыр хәлем юк! — дигән ул.

— Ә Тукыран, ирекка чыккач, нишләргә кирәген үзе белгән... — диде Муса, бик мәгънәле генә итеп. — Умыранга хезмәт итә, әмма карурман эчләрендә үз кешеләре җыйнала моның. Менә бер заманны Умыранны әйләндереп төшерә бу. Әйләндереп төшерә дә зинданга чаба.

— Кур, Йомыран энем! Дөньяга таң атты, — дип кычкыра ул. — Чык тизрәк бу тәмуктан! — һәм энесен кочаклап үбәргә тели. Ә Йомыранның битләре сып-суык, гәүдәсе таштай каткан — әллә кайчан үлгән булып чыккан ул...

Егетләр «Уф!» итеп тын алдылар. Бер-берләренә карашып куйдылар. Аларның бу әкиятне сабыйларча бирелеп тыңлавы сизелеп тора иде.

— Ирек бик кадерле нәрсә шул, — диде Гайнан Кормаш. — Минем бер китапта укыганым бар: бер народник, бугай ахры, Иркутски төрмәсеннән бәдрәф аркылы кача. Төн урталарында ничектер бәдрәфкә чыга

да, түгәрәк чокырына төшеп китә. Муеныннан арлык тизәккә чума, тын алыр хәле калмый, тончыга башлый. Нәкъ унике тулгач, «алтын» түгүчеләр килә дә, тышкы капкачны ачып, моңа озын черпак сузалар һәм шуның белән тартып чыгаралар. Кыш көне. Пар атлы чанага җигелгән олы-олы мичкәләр була. Шуларның берсенә кертәләр дә, «алтын» төйиләр һәм, тын алырлык кына тишек калдырып, капкалардагы охран күз алдыннан узып китәләр. Шулай котыла революционер.

— Ә ничек белә ул «алтынчылар» киләсен? — дип сорады кемдер. — Әгәр базда тончыгып үлсә шунда?

— Ә, юк, — диде Гайнан, — монда барысы да алдан хат аша сөйләшенеп эшләнгән була...

Күпмедер вакыт тын утырдылар. Һәрберсе авыр уйга чумды. Ике чикнең берсен сайларга кирәк: монда калып үлү — мәгънәсез! Йомыран язмышы. Чыгып китсәң дә, әлеге качкын кебек, нәҗескә буялачаксың. Хыянәт нәҗесенә! Әмма анда — яшәү бар. Яшәү булса — хәрәкәт бар, намусың буялмаса — көрәш бар, котылу бар!..

Кайсылары тәмәке кабызды. Чыккан төтендә, тәмәке исеннән бигрәк, мүк әчесе күбрәк иде. Ул әче зәңгәр төтен, аларның кыен уйлары төсле, баш очларында әйләнде...

— Языгыз мине, кем, ни, Гумеров әфәнде, — диде Зиннәт Хәсәнов, тиктомалдан гына. — Мин риза...

Габдулла Батталов белән Гайнан да, аның артыннан Солтанай Фәритҗанов та шул ук теләкне белдерделәр. Калганнары да язылды. Кайсы шагыйрь, кайсы җырчы, кайсы драматург, кайсы музыкант булды аларның.

Бозның болай кинәт кенә ватылып китүенә Муса гаҗәпләнмәде. Чөнки егетләр бу җәһәннәмнән берәр хәйлә белән ычкыну кирәклеген үзләре дә төшенәләр, тик кай башыннан башларга гына белмиләр иде кебек. Ә шундый чакта, бозга очлы тимер белән китереп бер төрткән шикелле, бер сүз дә җитүчән була. Егетләр җанланып ук киттеләр һәм, көлешә-көлешә, баскыч төбенә чыктылар да аннан тагын бер кеше җитәкләп алып керделәр.

— Менә, Муса абзый, — диде Кормаш, мөмкин хәтле рәсми булырга тырышып. — Безнең тагын бер «сәнгатьче» җырчыбыз бар әле. Монысы инде чып-чын артист. «Урман кызын» бик шәп җырлый.

Муса аның исемен һәм каян икәнлеген сорады. Теге кеше җавап бирергә ашыкмады. Аңа Баттал булышты:

— Әйт, Борис, курыкма, үзебезнең абзый ул!.. — Шуннан соң гына җырчы иелә төшеп, пышылдап телгә килде: — Борис Соломонович Махачкалинский... Шунда туып үскән, шундагы музтеатрда хор солисты булып хезмәт иттем, берәр ел гына, әлбәттә...

— Алай икә-ән, — дип уйланыбрак калды Муса. Шпигельнең үзен чишендергән чаклары исенә төште. Ничек соң әле моны бу көнгә хәтле «фаш» итмәделәр икән?.. Борисның йөзенә карады. Аның калын кара кашлары, җәенкерәк маңгай һәм битләре, шактый зур булса да туры борыны, аз гына кысынкырак күренгән караңгы күзләре яһүдлеген берхәтле яшереп торган шикелле иде. Бәлки, аны шушы тышкы сыйфатлары моңарчы «СС» күзеннән сакларга мөмкинлек биргәндер; ә «Урман кызы»н җырлавы бөтенләй «тартарен» итеп җибәргәндер... Әйдә, моннан соң да «Урман кызы»н оста итеп җырлый бирсен...

— Ярар,— диде Муса егетләргә елмаеп.— Бари Сөләйман улы Махачкалин, лирик тенор дип языгыз. Капелланың җырчысы булыр... Ризамы?

Борис кул суzды.

— Рәхмәт сезгә, тырышырмын, — диде.

Ишектән блок башлыгы килеп керде. Мусадан башкалары бар да аягүрә басты. Башлыкның, шактый ук төшереп йоклаган кешенеке шикелле, битләре һәм күз кабаклары шешенкерәп тора иде.

— Ничек бара соң эшләр? — дигән булды ул, Муса янына килеп.

— Менә шушы кешеләрне сайлап алдым, әфәндем. Болай әз-мәз һөнәрләре бар кебек...

— Гу-ут, — диде башлык, егетләр өстенә карап, һәм бик тәмле генә сузып искәп куйды. — Үзләрен тотулары буенча шелтәләре юк микән, карарбыз... — Тагын искәп куйды. — Цурюк!.. — диде ул аннары, егетләр ягына кулып селтәп. Бу аның: «Урыннарыгызга таралыгыз!» дигән йомшак сүзе иде. Егетләр чыгып киттеләр.

— Әлбәттә, тикшерегез, әфәндем, — диде Муса, бик җитди төстә. — Мин дә Берлиндагы башлыкларыма доложить итәрмен. Һәм югарыдан рөхсәт алгач, сез инде аларны легионга озатырсыз, майн һерр.

— Йа, йа! — диде немец, һәм алар бик дусларча кул бирешеп аерылыштылар.

Баскыч төбендә аны Гайнан көтеп тора иде. Блок капкасына атлый-атлый, кыска гына сөйләшеп алдылар.

— Муса абый, сез кем соң, Тукыранмы? — дип сорады Гайнан.

— Йомыран түгел... Мин — Казандагы Муса. Ә син үзең?

— Мин дә Йомыран түгел!.. Ярсу күңел юл эзли... Гайнанның сул кулы каты йомарланып, буын башлары агарган иде.

— Чын дусларыңны оештыр. Бик олы эшләр тора. Үлемнән курыкмый торган егетләр кирәк. Озакламый көрешербез... Хуш.

— Хуш, Муса абый. Табармын андыйларны!..

Муса чәнечкеле койманың тыш ягына һич тоткарсыз чыгып китте.

— Аһ, ирек! — дип, кайнар пышылдап калды Гайнан.

## АЛТЫНЧЫ БАШЛАМ

### I

Җепшек бураннары белән февраль узып, март кояшы күренә башлагач, безнең союзникларга да җан керде шикелле: һава тревогасы немецларны татлы йокыдан уятып, төн аралаш диярлек, бомбадан качу базларына йөгертергә тотынды.

— Әһә, безнең дуслар да тере икән әле! — дип көлә иде Фоат, Алиш белән бергә базга чапканда. — Арт аякларына кояш төшкәч, уяндылар.

— Корыч кала хикмәте бу!.. — дип, мәгънәле генә җавап бирә Алиш. — Тегеннән шундый гарасат килә, оятларыннан да уяныргa тиешләр.

Берлин урамнарында җимерек йортлар күзгә күренерлек күбәя башлады. Кайбер кварталлардагы янгыннар тәүлек буе диярлек дәвам итә инде. Берлин һавасын ниндидер рәшә сыман сары сөрем саручан булып китте. Немец газеталарының һәр битендә диярлек күпләп күренә башлаган кара дүрткелле исемнәр дә шул ук фаҗиганең шомлы хәбәре кебек тоела иде.

Шәфи комитетындагы һәм газетасындагы хәрби әсирләрнең квартирда торучыларына Берлин читендә булган ачык лагерь-баракларга күчү турында боерык бирелде. Аларның байтагысы инде күчкәләп тә өлгерде. Шыпырт Фәтхи дә үзенә әйбәт кенә урын тапты. Аны редакция тирәсендә күләгә шикелле тып-тын гына йөрү һәм Муса белән Алиш янында бөтенләй чит кешедәй аралаша алмый яшәү тәмам туйдырды булса кирәк. Шуның өстенә гел бомба явып торуы да опера музыкасы булмаганлыктан, баш саклау мәсьәләсе мөһим проблемага әйләнеп бара иде. Шул көннәрдә Фон Зикендорф әфәнденең Шәфи Алмазга үтенеч хаты

килгән икән. Дус дусны онытмый, бәйрәм ашы — кара каршы, минем хуҗалыкка бер 10—15 солдат җибәрүгә ризалык бирсәңче һәм шуларга башлык итеп, үз тирәңнән бер ышанычлы шәхес беркетсәңче, дигән мәгънәдәрәк язган иде ул. Шәфи, әлбәттә, ризалык бирде. Зикендорф әфәндене̦ң Радомга йөртеп, аккош Магдалина белән таныштыру изгелекләрен онытып буламы соң? Уйланып утыра торгач, ышанычлы кешесен дә тапты. Шыпырт Фәтхи иң яхшы унтер булачак иде.

— Барасыңмы? — диде Шәфи, аны чакыртып. — Монда йөреп үзеңнән рәт тә чыкмый, бик куркак та күренәсең; ничә ай Муса белән Алиш янында торып, бармакка чолгарлык мәгълүмат бирә алмадың... Әйдә, бар, ычкын, башың исән калыр!

Гаянов бу сүзләр өчен бер дә гарьләнмәде. Киресенчә, аның йөзенә сөенү билгесе чыкты. Чынлап та, Зикендорф дуңгызлары өстенә бомба төшмәячәк бит.

— Баш өсте! — диде ул Шәфигә җавабында һәм иртәгесен үк Зикендорфның Дзерден тирәсендәге фермасына китеп тә барды. Һәм үз уенча бик яхшы итте. Ул бит сугышка кадәр әйбәт кенә урыннарда эшләгән, үзе боергалаган кеше. Ә редакциядә аны ни өчендер санга сугучы булмады, коры тәрҗемәче итеп тик йөрттеләр. Зикендорфта, ичмаса, унбиш кенә кешегә баш булсаң да — барыбер баш булу. Буйсыну түгел! Самостоятельный объект!.. Аның максаты әнә шул иде...

Нәзир Һадиевка да бәхет үзенең җылы кулын сузды. Берлин өстендә бомбалар сызгыра башлагач, ул һәркөнне диярлек Шәфигә кереп ялына иде. Шул керүләрнең берендә, Алмаз, борынын сузып, искәнеп торды да:

— Фу-у... сез нәрсә, доцент әфәнде!.. Дизентерия мәллә? — дип оялтты аны һәм шуннан соң озакламый яңа урын табып бирде. Познань фабриканты Яушев «камисар» сораткан иде. Теге мөселман егетләре яхшы полицай булу урнына үзләре шалтай-балтай килебрәк йөриләр икән, аларны акылга утырту кирәк. Менә шунда Шәфи үзенең «камисары» итеп Һадиевны җибәрде. Ул да бу эшне сөенеп кабул итте, чөнки Польшаның гадәти бер шәһәре Познань, башың исән калу ягыннан караганда, әлбәттә, Берлин түгел бит инде...

Шәфи Алмаз Алишларның фрау Вальдеста торуларын да хуп күрмәде, шәһәр читенәрәк күчәргә тәкъдим итте.

— Минем йорт страхаулы, фрау Вальдеслар да шулай ук. Әгәр бомба төшсә, без акча алабыз, — диде ул. — Ә менә сез страхауланмаган, алай-болай була калсагыз, мин түләргә тиеш булам сезнең өчен. Юк, артык акчам юк, кучегез тизрәк...

Муса кайтканда Алиш инде үзләренең юклы-барлы әйбер-сәйберләрен төйнәштереп куйган иде. Шул көнне үк алар Берлинның бер читендәрәк булган Албайнплацка күчеп киттеләр. Сирәк яшь агачлык арасына сибелгән лагерь-бараклар иде монда. Сәндерәләре, салам түшәк, салам мендәрләре һәм кандалалары белән атаклы иде бу сакчысыз бараклар. Шулай да Мусага монда иркенрәк булыр сыман тоелды. Агачлык аралары тып-тын. Чыккалап йөрсәң дә, Берлин урамындагы шикелле, билгесез колак, астыртын күз сине сагаласы түгел, һавасы да сафрак, кар торса, чаңгыда әйләнгәләргә дә мөмкин буласы.

Муса кайткач оешманы җыярга, утырып сөйләшергә кирәк иде. Иптәшләре аны сагынып көтеп торганнар. Әмма андый утырыш ясап сөйләшү заманнары ерак хатирә генә булып калганлыктан, аларга аягүрә генә сөйләшергә туры килде. Бу баракларда төрле милләт кешеләре яши, күбрәк өлеше шул ук комитетларда эшләп йөри иде. Һаман күзен очлайтып торучы немец булмаса да, Карип Ишбулдин һәм аның башка милләтләрдән булган ишләре дә шушында яши бит әле. Шуңар күрә Муса белән Алиш, бер көнне комитет эшеннән кайткач, урман юлына чыгып киттеләр. Алар артыннан Булатов белән Симаев та килеп кушылды. Урынлык усак корыгы сөйрәгән Шабаев урман эченнән алар-

ның каршыларына килеп чыкты. Караңгы төшеп өлгермәгән иде әле. Сирәк-мирәк агачлар арасыннан әйләнеп узган юл өстендә йомрыланып каткан ат тизәкләре күрде Алиш.

— Шәп нәрсә таптым, егетләр! — дип куйды ул. — Әйдәгез, тырай тибәбез! — Һәм бер йомры кисәкне тибеп тә җибәрде.

Башкалар тырай артыннан йөгерделәр. Шулай туп тибеп уйнаучы малайлар шикелле шаяра-шаяра бараклардан шактый читкә китеп, агачлыктагы бер инеш бозы өстенә килеп төштеләр алар.

— Яхшы урын икән бу, — диде Муса. — Алайса, комитетның тырай тибүле утырышын башлыйбыз. Каршылар юкмы?

— Башлыйбыз! — диде калганнары, уен куанычына бирелгән тавыш белән. — Тип, әйдә!

Фоат тырайны тибеп җибәрде, башкалар аның артыннан йөгерде. Әллә ничә аяк берьюлы чәчкәләшеп, тырайны үзенә таба алып китәргә тырышты. Муса чокыр саклый иде. Шуннан файдаланып, легиондагы эшләрнең торышын аңлатып бирде. Тырай чокырга якын килә башласа, тиз генә читкә тибеп, тагын дәвам итте. Шәфи лекцияләрен, төнге «Катюша»ны һәм «Сталинград матәме»н сөйләгәндә, бу сүзгә әллә нихәтле көлүләр катышты. Уен хәрәкәтләрен туктатмаган егетләр эсселәп китте. Бүрекләрне салып ташларлык дәрәҗәдә көн җылы булып тоелды.

— Туктагыз әле, егетләр,— дип кулын күтәрде Алиш.— Карагыз әле як-ягыгызга!

Егетләр, сискәнгәндәй кыяфәт белән күзләрен төбәп, тирә-юньнәрен күзәтеп алдылар.

— Беркем дә юкмы?.. — дип сорады Алиш, тагын да мәгънәлерәк сыман итеп.

— Юк бит... — диештеләр аңа, аптыраган тавыш белән.

— Юк шул! Соң шулай булгач, кемнән бу хәтле качынабыз?

— Чынлап та! — дип, бот чапты Фоат. Һәм алар берьюлы көлешеп җибәрделәр. Аннары, яр буена килеп утырдылар да, бүрекләрен колак өстенә генә кырынайтып, башларын җиллэтергә куйдылар.

— Урманда пышылдап сөйләшкән малайлар шикелле без, — дип өстәде Алиш. — Хәтерлисез микән: бәләкәй чакта урманга баргач, шулай ярым пышылдап сөйләшә торган идек, өстерилек ишетеп килер дә тотып алыр, янәсе.

Муса үз хәбәрләрен дәвам итте.

— Батальоннарда оешма дүртлек тәртибендә төзелде, — диде ул.— Әң югары җитәкчелек — батальон командиры кулында. Беренче батальонга бик әйбәт кеше туры килде. Элекке подполковник Онисим Гуриевич Актабанов, Казанда хәрби лагерь башлыгы иде. Олы яшьләрдәге кеше. Иманы камиль, энергиясе бар. Сез ничек карыйсыз, батальон командирлыгына шуны расласак, ялгышмабызмы?

— Ул да әләкканмени? — дип сорады Алиш. — Минем дә күргәләгәнем булды аны. Ләкин мин лагерь башлыкларын да сугышка җибәрәләр дип уйламаган идем. Гаҗәп...

Егетләр уйланышып утырдылар. Өлкән офицерның әсиргә эләгү сәбәпләрен беләселәре килде. Муса аның хакында үзе белгәннәрне сөйләп бирде. Качып тотыла торгач, Бухенвальдка эләгүен, аннан үзе теләп легионга килүен әйтте. Хәзер культвзвод командиры, диде.

— Безнең хәл әлеге кызныкы төсле инде, — дип көлде Шабаев. — Кияүнең нинди икәнлеген үз күзебез белән күрә алмыйбыз, шәригать кушмый. Әмма димчебез — диңгез кичкән кеше дигәндәй, безнең өчен дә күзләгәндер, тикшергәндер инде. Һәрхәлдә кияү кылыймы, чулакмы, тинтәк-фәләнме булса, безгә тәкъдим итмәс иде!

Башкалар каршы килмәде. Икенче батальон командиры итеп билгеләнгән Харис Уразаевны да шулай раcладылар.

— Өченче батальон төзелеп кенә ята. Анда безнең беркемебез дә юк әле, — диде Муса. — Шулай да анда Демблиннән берничә кеше җибәрелде. Оешманың беренче күзәнәге шулардан яралып китәр. Шушы уңай белән миндә бер тәкъдим бар,— дип дәвам итте ул.— Булатовка «Идел-Урал»ның экскурсия эшләре тапшырылган бит, менә ул шушы мәдәни һәм сәяси көчләр өчен Берлинга экскурсия оештырсын иде. Сез дә алар белән яхшылап танышыр идегез, бер киңәшмә дә уздырып алыр идек. Моның өчен Булатовның хәзер үк батальоннарга китүе һәм кешеләрне үзе сайлап алуы кирәк булачак. Аңа ияреп Алиш та барса, газета өчен үзебезгә яраклырак хәбәрчеләр сайласа һәм аларны шулай ук бергә экскурсиягә алып килсә, тагын да шәбрәк булыр иде...

Бу тәкъдимне егетләр бик хуп күрделәр. Гарифның да андагы хәлләр белән танышып кайтасы килде.

— Сиңа да йомыш табарбыз, — диде Муса, бераздан соң. — Шәфи Алмазның шәхси вәкиле булып Демблингә барырсың. Анда кешеләр ачтан һәм тифтән чебен урнына кырыла... — Мусаның аркасына суык кырмыска үрмәли башлаган иде, ул аягүрә басты, башкалар да калкынып, селкенгәли башладылар. Муса кар өстендә яткан трайны чөеп җибәрде. Калганнары аның артыннан йөгерде — җылынасы килә иде аларның. Нәкъ малайларча дәрт белән бер-берен төрткәли һәм көлешәкөлешә, трайны чокырга таба алып килделәр.

— Шуларны ничек коткарырга? — диде Муса. — Безнең кешеләр әрәм була ич!..

Егетләр тукталышып калдылар. Берсе дә тиз генә җавап бирмәде. Әйе, беләләр. Чөнки алар булган лагерьларда да шундый ук хәл иде. Чынлап та, ничек коткарырга соң аларны?..

— Дөрес, халык кырыла, Муса, — диде Гариф, авыр гына сулап. — Ченстохово лагерена утыз мең казак әсире тупланган булган. Шуларның егерме сигез меңе инде тифтән кырылып беткән... Син әле, бәлки, ишетмәгәнсеңдер: Мостафа Чокай әфәндене дә шунда бет ашап үтергән, нинди мәһабәт хайван иде, мәрхүм... Әмма шунысы кызганыч: коткару — безнең кулдан килми торган эш.

— Ә минемчә, коткарып булыр кебек, — диде Муса. — Һәм бу — синең эш булса кирәк, Шабай!

Бар да аптырап Мусага карадылар. Ничек инде ул? Шабай нишли ала? Ул түгел, хәтта Шәфи дә коткара алыр иде микән әле?..

Муса дәвам итте:

— Андагы кешеләрне тиз арада легион солдаты итү кирәк һәм аны без эшләргә тиешбез!

Егетләр аптырап калды: нәрсә сөйли бу, саташкан мәллә? Ләкин Муса шул ук сүзне яңадан ныклабрак кабатлагач, йөзләренә ризасызлык билгесе йөгерде. «Юк, дөрес түгел бу сүзең!» дигән шикелле, баш чайкады кайсылары. Ә Симай тырайны җан ачуы белән тибеп әллә кайларга очырып җибәрде. Әйтерсең, бөтен гаеп шул ат тизәгендә иде. Аннары утлы күзләрен Мусага күтәрде дә:

— Фашист эшли алмаганны без эшләргә тиешме?.. Бер сынык эрзац әпәй өчен меңләгән кешеләргә җан саттырыйкмы? Аш кыйбатмы, баш кыйбатмы? — дип ыжылдады ул. — Җинаять булачак бу!..

Башкалар эндәшмәделәр. Тынлык шактыйга сузылды. Тик шуннан соң гына Муса салкын тавыш белән салмак кына җавап кайтарды:

— Әйе, без эшләргә тиеш. Демблин, Седельце һәм башка шундый урыннар барыбер «легионга хәзерлек лагере» санала ич. Анда дошман үз вәгазен алып бара. «Риза булып язылу» уены уйнаткан була. Ә риза булмаганнар әнә шул ачлык һәм эпидемияләрдән кырыла тора. Болай караганда хәтәр сыман күренсә дә, коткарыйк халыкны, иптәшләр. Алар безнең таянычыбыз булыр.

Егетләр тагын тын калдылар. Бу юлы инде Муса сүзләрендә хаклык бар шикелле тоелды. Чынлап та, ул кешеләрне ничек кенә булса да чәнечкеле читлектән чыгармыйча, тамакларына биреп хәл кертмичә торып, нишләргә мөмкин? Аннары алар үз юлларын үзләре дә карарлар.

— Мин бу хакта Шәфигә үзем сөйләрмен, — дип дәвам итте Муса. — Гади солдат аңламый, аларны легионга көчләп һәм тиз арада күчерергә кирәк, юкса, үлеп бетәләр, без солдатсыз калабыз, Чокай хәленә төшмик, диярмен. Син дә шунда булырсың, Гариф. Мин сине шул лагерьларга йөртеп кайтарырга тәкъдим итәрмен. Ә Шәфи — ач күз. Строевой батальонга нихәтле күбрәк солдат куйса, шул хәтле күбрәк каера бит ул немецтан... Кирәкле мәгълүматлар алып кайтырсың. Шәфи шуның белән Розенбергка керер һәм фашистларның көчләү машинасын хутка җибәртер. Ә һәрбер көчләү — нәфрәт һәм каршы хәрәкәт тудыра. Бу инде безнең файдага...

Шуннан соң Муса музыка һәм җыр капелласына, мәдәни эшләргә нинди егетләр тупланганын сөйләп бирде. Аларның матур җырлавына һәм гомумән сәләтле булуларына сокланды.

Әле генә Муса тәкъдиме белән килешәсе килмичә бер кабынып алган Әхмәт Симаев тагын ризасызлык күрсәтергә ашыкты.

— Все это слишком мирно и безобидно, — дип куйды ул, русчалатып кына. — Музыка да капелла, җыр да бию, мәдәни агарту да культурный тазарту, кемнәрнедер тифтән коткарып немец солдаты итү, үгетләү дә вәгазьләү, онытканда бер листовка чыгарган булу... Юк, вак эшләр болар һәммәсе дә... культпросвет! Шулмы безнең эш?!

Бар да гаҗәпләнеп аңа карадылар, елмайган килеш аның нәрсә теләвен аңларга тырыштылар. Симай әле егерме алты яше дә тулып җитмәгән кызу табигатьле егет иде. Бәлки, шуңа күрәдер, аның күңеле зуррак һәм шәбрәк эшләр, десантта йөргәндәге шикелле кыю һәм тәвәккәл хәрәкәтләр таләп итә иде. «Ничектер башкача әйләндерергә кирәк дөньясын!» дип баш вата иде ул.

— Ә син нәрсә тәкъдим итәсең соң? — дип сорадылар аңардан.

— Бар минем тәкъдимем! — диде ул, шактый горур тавыш белән. — Аны тормышка ашырганда — всему конец!

— О-о! — диеште егетләр. — Йә, йә, сөйләп бир әле.

— Ә сез көлмәгез. Аны булдырып була.

— Йә, нәрсә соң ул?

— Менә нәрсә: хәзерге көндә боларның тәгәрмәче артка тәгәри. Корыч кала дәһшәте йөрәкләрен алды. Менә шушы вакытта, чөй өстенә тукмак ясап, теге тинтәк җәфрәйтерне юк итәргә кирәк!.. — Егетләрнең күзләре шар булды, тагын да гаҗәпләнебрәк Симайга текәлделәр. — Ә сез шаккатмагыз, — дип дәвам итте ул. — Бу көннәрдә аның янына Рим каласыннан «Мөрсәлини» киләчәк. Аны каршылау өчен Шарлоттенбург вокзалына җәфрәйтер үзе барырга тиеш. Менә шунда инде алдан вокзалда уңайлы урынга качып каласың да тегеләр очрашкач кына кисәк чыгып өч порция «лимон» тондырасың һәм — вәссәләм, эшең бетте, кодагый! Берьюлы ике куян — шалт! Иртәгесен үк сугыш та тыначак!..

Егетләр кычкырып көлеп җибәрделәр.

— Көлмәгез, пажалыста! — диде Әхмәт, җәберсенеп. — Бер дә көлкесе юк!

— Юк, — диде Фоат, — тәкъдимеңнән түгел, бик образлы әйттең...

— Менә шул, — диде Әхмәт әле һаман ялкынланып. — Бу, әлбәттә, кыен эш. Һәм аны башкарган кешенең һәлак булуы да бик ихтимал, ләкин эшләп була! Әгәр безнең «Дүртенче...» бу планны кабул итсә, тормышка ашыруны үз өстемә алам һәм намус белән үләрмен!

— Менә шул шул: үләрсең! — дип кабатлады Муса.

— Нигә, үлем куркынычмыни ул? Мин аның күзенә караганым бар.
— Ансы һәммәбез дә таныш ул җанвар белән, — диде Алиш. — Мактанма.
— Нигә мактаныйм, — дип карышты Симай. — Алайса, шул ук эшнең икенче варианты да бар. Монысын хуп күрмәсәгез, бәлки анысы ярар?..
— Анысы ничек тагы? — дип сорады Муса, көлемсерәвен сиздермәскә тырышып.
— Анысы болай, — диде Әхмәт. — Воляви бакчасына яшеренеп, җәфрәйтернең тал каерысы белән буяган йорттан чыгуын бик яхшылап күзәтергә һәм иң җайлы минутта гына шулай ук өчле «лимон» ашатырга... Монысын да үз өстемә алам!
— Фантазия! — дип куйды моңарчы тын торган Гариф Шабаев. — Син, дускай, әкиятләр дөньясына кереп чумгансың.
— Әхмәт, — дип эндәште Муса, йомшак кына. — «Халыкчы»ларны беләсеңдер инде син. Степан Халтуринны да, Александр Ульяновны да һәм башкаларны да... Аерым бер патшага «лимон» ашатып кына җәмгыять тәгәрмәчен борып булмауны аңлатып тору кирәкме?.. Андый эшне без алманнарның үзләренә калдырыйк инде. Ә үзебез җәфрәйтергә солдат бирмәс өчен эшлик!
Әхмәт Симаев барыбер килешергә теләмәде. Дөрес, террористик җилкенүе үзенә дә көлке сыманрак тоела иде хәзер. Ләкин монда да әллә ни кызыктырырлык нәрсә юк ич. Дошман тылындагы хәтәр шартларда андый сыек хәрәкәтләр генә җитми, колач кирәк!.. Аңа ни өчендер эссе булып китте. Маңгай һәм муеннарын кулъяулыгы белән сөртеп куйды, тәмәке кабызды һәм, әле һаман да җиңеләсе килмәгән кебек:
— Сүз белән генә революция ясап булмый, — дип куйды.
— Була! — диде Муса, шундый ук бәхәс дәрте белән. — Сүз — беренче уяткыч, аң кертә, оештыра, нәфрәт ялкыны дөрләтә... Ә син беләсеңме, беренче батальон озакламый сугышка җибәрүләрен көтә. Менә шул батальонны тулысы белән үзебезнең якка алып чыгу мәсьәләсе көн тәртибенә куелды. Андагы егетләр шул юнәлештә эшли хәзер. Монысы уңышлы чыкса инде, калганнарына да юл табылыр!..
Егетләр сүзсез генә Әхмәткә карадылар. «Ничек, энем?» дигән сорау иде аларның күзләрендә. Хәзер инде Әхмәт шаккатты.
— Шулай укмени-и?.. — дип куйды ул, байтак тын торганнан ары.— Ник аны баштан ук әйтмисез? Алай булгач, үз планнарымнан кайтып торырга туры килә инде... Эх, бик шәп иде ләкин!..
Иптәшләре тагын көлештеләр. Фоат, гадәтенчә шаян сүз кыстырырга теләп, әйтә куйды:
— Тик мондый зур эш өчен «төкерткеч», «сиптергеч» шикелле һәртөрле уенчыклар кирәк булачак, шуны да истән чыгармыйк, егетләр.
— Анысын фриц агай үзе бирер әле, — диде Гариф. — Сугышка җибәрә бит, таяк тоттырмас.
— Ну, баш синдә, малай, — диде Фоат, — Тубалың бер якта торсын!..
Тырай яңадан сикерә башлады. Оешма утырышы инде тәмам булды.

## II

Муса өйдә югында да Көнчыгыш эшчеләре арасына «кызлар хаты» илтү өзелмәде. Әхмәт Симаев Сталинградта җиңү хәбәрләрен аеруча бер комарлык белән кабул итеп тора иде. Алиш белән Фоат аны русча да басып, кызлар арасына ташыдылар. Фая бик әйбәт кыз булып чыкты. Иптәшләре ярдәме белән ул хатларны бик оста рәвештә генә тиешле кешеләренә тарата барды. Кыш булуга карамастан, алар һаман Аккүл буенда очрашалар иде. Шундый күрешүләрнең берсендә алар янына

озын буйлы бер яшьрәк кеше килеп туктады. Алиш иң элек аның солы саламы төслерәк кашлары белән балта борынлырак булуына игътибар итте. Күзләре якты соры идеме, әллә сыек зәңгәрме — ачык билгеле алмады. Аның Фая белән исәнләшкәндәге акцентына караганда, белорус кешесе булуы аңлашыла иде.

— Утыр, Андрей, безнең белән, — диде Фая, гади генә итеп. — Таныш булыгыз: бу — Абдулла Алишев, можно сказать, мой кавалер...— Алиш гаҗәпләнергә һәм каршы килергә дә өлгермәде, Фая елмаеп дәвам итте: — А это — Андрей Шилов, тоже, можно сказать, мой кавалер...

Хәзер инде егетләр икесе дә сәерсенеп калган иде. Көлешә-көлешә кул бирештеләр дә Фаяга бәйләнделәр.

— Хәтәр сөйләшәсең, Фая, — диде Шилов. — Син безне сугыштыруың мөмкин!

— Һич шиксез! — дип кызган булды Алиш. — Мин хәзер үк дуэль таләп итәм. Атышырга!

— Бик күңелле булыр! — диде Фая көлеп. — Атышыгыз, әйдә... Берлин, Аккүл буе, карт тирәкләр... Бөтен табигый обстановка бар. Бик оперный чыгачак. Хәзерләнә торыгыз, ә мин сезгә секундантлар эзләп килим. — Бу аның ике егетне иркенләп сөйләштерер өчен юри китеп баруы иде.

— Ваши «Девичьи письма» право замечательны! — дип сүз башлады Шилов, чынлап та белорусчарак акцент белән. — Алар бик күп кешеләрнең күзен ачып, башларын турайтып җибәрде. Бик рәхмәт сезгә. Минем инде күптән үк сезнең белән танышасым килә иде. Безгә ныграк бәйләнышып эшләү яхшы булмас микән, дим.

— Әлбәттә, — диде Алиш. — Бергә-бергә яхшырак инде ул. Миңа да Фая сезнең хакта әйткән иде. Ниһаять, бүген менә очраштык.

Ә шул хатларның полякчасын да эшләп булмыймы? — дип сорады Андрей. — Чөнки безнең арада поляклар да күп бит.

— Без полякча белмибез шул, Андрей, — диде Алиш. — Андый кешебез юк.

Андый кешене Шилов үзе табып бирергә булды. Болеслав исемле бер поляк дустының русчаны яхшы белүен һәм ышанычлы булуын әйтте.

— Ярар, — диде Алиш. — Без моны сөйләшербез. Бер иптәш командировкада әле безнең. Ул үзе дә сезнең белән күптән үк танышасы килә иде...

Бүген Мусаны шунда алып китте Алиш. Аларга Фоат та иярде. Яз иде, мартның унбишләре генә булса да, бездәге апрель урталары диярлек, кояшлы җылы көн иде. Агач бөреләре тәмам бүртеп, кып-кызыл ялтыравык нәфис тырнаклары ачылып китәргә җыена иде. Аккүл буендагы тирәкләрдә сыерчыкларның шулчаклы дәрт белән ярсынып һәм өзеп-өзеп сайраулары күңелләрне әллә кайларга, язның шул беренче җырчыларына оя ясап йөргән малай чакларга алып китә иде. Әмма шунын белән бергә, аларның монда, немец җирендә, сайравы барыннан да гаҗәбрәк һәм сәеррәк тоела иде. Чөнки сыерчыклар фәкать безнең илдә генә, безнең өй артында гына сайрый торган үз кош булып, сабый яшьтән үк күңелгә сеңеп калган кадерле бер төшенчә иде. Шулай да аларның дәртсенеп сайравы чит-ят җирләрдә дә барыбер матур, барыбер сокландыргыч булганлыктан, күл буена килгән егетләр байтак вакыт аларны тыңлап, сагыну хисләрендә онытылып утырдылар.

— Туктатыгызсана, зинһар, шул сыерчыкларны! — диде кинәт кенә Фоат, чын һәм шаянлык катыш ялвару белән. — Тыныч кына тыңлый алмыйм шуларны. Әллә пленга төшкәннән бирле кош тавышы колагыма кермәгәнгә, әллә алар вәгъдә итә торган күңел куанычларының барын да җуеп бетергәнгә, үзем дә белмим нәрсәгәдер, шуларны ишеттем исә, йөрәгем ургыла башлый, әллә кайларга ашкына, әллә нинди еракларга

алып китә һәм моннан йөз ел элек беренче мәхәббәт уянган чакларны искә төшерә...

— Ай-яй красивый әйттең! — дип елмайды Алиш. — Нәкъ өстенә бастың. Сыерчыкларны тыңласам, миңа да шулай тоела. Казанның бөтен сыерчыклары Тельман урамына җыелган һәм шунда гына сайрыйлар кебек иде, чөнки ул урамда Өркыя тора иде...

— Юк, агайне, ялгышасың, — дип бүлдерде аны Фоат. — Казанның бөтен сыерчыклары тугызынчы мәктәп ишек алдындагы яшь өрәнгеләрдә сайрый иде. Чөнки анда Сәгадәт укый да мин укый идем!

— Күрәсең, Тельман урамына сыймаганнары булгандыр инде, — дип куйды Алиш, исе китми генә.

Муса аларның бу сәер бәхәсләренә катнашмыйча, күзләрен шул кошларга беркетеп, тын гына көлемсерәгән килеш утыра бирде. Аның да күңеле еракларда иде, күрәсең. Тик ул үз хисләрен сүзгә әйләндермәде. Әйе, сыерчыклар яки башка сайрар кошлар һәркемнең мәхәббәтенә килеп керә инде ул. Мусаның да үз кошы бар иде бит. Әминәләр йорты тирәсендәге агачлыкта сайрый торган сандугач иде ул. Әлеге сигезенче март бәйрәмендә танышканнан соң, куанычлы елның май айлары житте. Муса Әминәләр өенә йөри башлады. Менә шунда аны һәрвакыт бер сандугач сайрап каршылый иде. Кайдадыр бик якында, әнә шул каршыдагы шомырт куелыгында гына сайраган төсле. Муса аны, күреп булмасмы, дип эзләп китә, песидәй генә посып, һич кыштырдаусыз атлап, яфрак араларын күзәтә, ә сандугач әз генә тынып тора да бөтенләй икенче якта, икенче бер билгесез агачта сайрый башлый. Муса анда юнәлә, ә кош тагын юкка чыга... Әминәгә охшаган дип көлә иде Муса ул чакта. Чөнки Әминә дә шулай катоктамы, өйләрендәме, кинәт кенә юкка чыга иде ич... Шулай да Әминә дигән кошны барыбер тотты ул, тик сандугачны гына тота алмады... Ә хәзер инде... Хәер, хәзергесен уйлавы да куркыныч. Ургылып кайнап торган ут тавы аша сикерәсе бар. Тик шунда гына күрсә күрер ул үзенең ике былбылын. Ә сикереп чыгарга көч җитмәсә...

Муса, күзләрен сыерчыклардан аерып, күл өстенә карады. Аның тыныч яткан кара-яшькелт суы үз карнына бик күп шомнар яшергән төпсез упкын кебек тоелды. Сикереп чыга алмаса, бу упкын аны да йотар төсле күренде... Ул күзләрен читкә борды. Күл әйләнәсендә байтак кына кешеләр, көз көнендәге шикелле үк, әлеге хәсрәт базарында гизмәктәләр иде. Ниһаять, алар каршына ике кеше килеп туктады. Алиш кузгалып аларның берсе белән күреште дә, «Танышыгыз, Шилов» дип, иптәшләренә тәкъдим итте. Шилов исә, үз чираты җиткәч, «Болеслав» дип, иптәше белән таныштырды. Алар сөйләшеп киттеләр. «Кызлар хаты»н полякча да булдыру иде сүз. Русча текстны Алиштан Фая алып кайтырга һәм Болеслав полякчага әйләндергәч, илтеп бирергә тиешле булды. Бу бик мәшәкатьле күренсә дә, башка юл юк иде. Болеславның редакция тирәсенә үзе барып йөрүе, әлбәттә, мөмкин түгел иде.

Аннары Шилов белән Муса, икенче эскәмиягә күчеп, үзләре генә сөйләштеләр. Муса Болеслав турында кабат сорады. Андрей аның ышанычлы егет булуын әйтте. Бу мәсьәләне бетергәч, ВКП(б) Берлин комитеты төзелә башлавын хәбәр итте.

— Чынлапмы? — дип сорады Муса, куанычлы гаҗәпләнү белән. — Менә монысы шәп булыр иде! Безнең хәлләргә дә әллә нихәтле ачыклык керер!

Шилов салкын кан белән генә сөйләде. Шушы максатлар белән «Ялкын» җитәкчесе «Бакшей бабай» Берлинга киләчәген аңлатты. Ул килү белән үк Мусаны аның белән очраштыру турында сүз куештылар. Йомышлары беткәч тә Андрей белән Болеслав китеп барды. Мусалар

да кайтырга җыеналар иде инде. Тик Алиш кына муенын төрле якка боргалый башлады.

— Җәллим муеныңны, — диде Фоат, — каерыла торгач, сынып китмәсә генә ярар иде...

Өчесе дә көлешеп алдылар. Гыйшык-мыйшыклары булмаса да, Алиш белән Фая чын иптәшләрчә дуслашып өлгергән иделәр. Һәм аның күзләре юкка эзләнмәгән икән, эскәмия яныннан китүләре генә булды, Фая үзенең бер көтү иптәш кызлары белән алар каршына килеп басты. Шаулашып күрешү китте. Әле генә Алиш муеныннан көлгән Фоатка да җан керде. Аның теге вакытта күз төшергән Фәридәсе дә бар иде анда. Шул күрешү арасында бөтенләй көтелмәгән бер хәл булып алды. Кызларның бер боек кына чырайлы, мескен генә булып читтә торучы «ак тәтән» чәчлесе Мусага карап-карап торды да ачы һәм куркынган сыман тавыш белән кинәт кычкырып җибәрде:

— Ай! Бу кем?! — Һәм куллары белән ике битен каплап, артка чигенде. — Әллә саташам инде, ходаем?! — дип өстәде ул, хәлсез генә.

Муса да бер секундка аңа текәлеп карады һәм бөтен гәүдәсе белән аңа тартылган килеш:

— Әлбидә! — дип кычкырды.

— Муса абый! Бу чынлап та синме? Әллә күләгәң генәме?..

Кыз газап, хәсрәт тулы хәрәкәтләр белән аңа таба омтылды һәм үзенең фәкыйрь киемнәре, ямаулы җиңнәре белән пөхтә костюмлы, яшел эшләпәле Мусаның муенына сарылып, әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан кайнар итеп үбә башлады. Аның күзләреннән өзлексез коелган яшьләр Мусаның битләрен, яңакларын яндырып алгандай тоела иде.

Бу хәлгә тәмам хәйран калып, һични аңлый алмыйча торган егетләр белән кызлар уңайсызлыктан читкә борылдылар. Кешеләрнең мондый изге минутларында шаһит булу әдәпсезлек кебек тоела иде...

— Да-а, җитди булып чыкты әле монда эшләр! — дип куйды Фоат, көрсенеп. — Әйдәгез, әйләнеп килик, булмаса...

...Бер-берен үлде дип һәм коткара алмавына гаепле санап йөргән ике кешенең кинәт кенә яңадан очрашып куюы фәкать сугыш җирләрендә генә була торган гаять катлаулы, искиткеч куанычлы һәм тетрәткеч бер хәл иде. Әлбидә, әле һаман ышанып җитмәгән кебек, Мусаның кул беләзекләреннән, иңбашларыннан тотып карады, яңак һәм кашларын, маңгай өсләрен сыйпап чыкты. Кайбер урыннарга үзенең кытыршы бармак битләре белән озаграк тукталып, андагы җыерчыкларны язарга теләгәндәй итте. Гүяки, әле генә булган нинди дер һәлакәттә бердәнбер баласының исән калуына һаман ышанып бетмәгән мәрхәмәтле ана калтыранган куллары белән үз газизен шулай барлый, шулай капшана иде. Муса да Әлбидәдән бик озак күзен ала алмады. Моннан берничә ай гына элек яшьлек, шаянлык аңкып торган бу кызның матур йөзе нинди дер агулы сөрем эчендә саргаеп сулган чәчәкне хәтерләтә, бөтен төсеннән һәм килеш-килбәтеннән өмет яктысы калмаган боеклык, кайгы-хәсрәт тулы моңсулык күренеп тора иде. Ак һәм сөйкемле маңгаена пәрәвез җепләредәй нечкә һәм вак кына җыерчык челтәре сарылган. Сул яктарак, чәч төбеннән башын гына сузган селәүчән төсле, кызгылт җөй бүртеп тора. Шул җөй өстеннән нәзек кенә булып ак чәч бөртекләре үсеп чыккан да җил чуалткан сыек тәтән төсле борыла-сырыла бөтен башына таралып киткән. Кайчандыр уйнаклап, шаян дулкынланып торган коңгырт-кара ефәк чәчләр, үзләреннән бөтен купшылыгын җуеп, кызның үзе шикелле үк басынкыланып, боегып калганнар. Әйтерсең, аның маңгай өстеннән күтәрелгән нәзек сыек тәтән чал бөртекләре түгел, ә бәлки бу гүзәл хәсрәтченең эченнән бөркелеп чыккан аһ-зар сөреме иде. Аның өстендәге иске жакеты белән шактый тузган күлмәкләре, тапталган башмаклары белән ямаулы тупас оеклары да кызның хәле ни дәрәҗәдә аяныч икәнен ачык сөйлиләр иде.

— Син ничек исән калдың соң, Муса абый? — дип сорады Әлбидә, күпме караса да, һаман күреп туймас төсле гашыйк күзләре белән. — Мин бит сине үлде дип йөрдем. Алга аерылып китеп сине саклый алмавым өчен үземне гаепле санап, күпме яшьләр түктем, күпме үкендем, гомергә үземне кичермәс кешегә әйләнә яздым...

— Мин-мин инде ул, мине «капут команда» солдатлары теге дөньядан алып кайтканнар, — дип көлемсерәде Муса. — Менә син нинди могҗиза белән исән калдың, әле дә аңымны җыя алмыйм: синең өскә бомба яуды бит, су һәм саз таулары күтәрелеп капланды. Киресенчә, монда мин гаепле: мин сине ялгыз калдырмаска яки андый хәтәр җиргә алып кермәскә тиеш идем. Сине югалтканнан бирле мин үземне җинаятьче санап йөрдем. Күргән җәзаларымның һәммәсен дә синең өчен дип уйладым эчемнән. Кеше шундыйга да әйләнә ич монда...

— Ә син минем «Муса абый! Муса абый!» дип кычкырганымны да ишетмәдеңме?

— Кая ул, җанкисәгем, ишетү-ү!..

— Ә миңа башта берни дә булмады. Шунда сине күздән югалткач, кычкыра-кычкыра кире чыга башладым. Теге каһәрләр яңадан килеп бомба койдылар. Шул чакта маңгаемны кечкенә бер кыйпылчык ертып киткән, ярый әле тирәнгәрәк эләкмәгән, беткән булыр идем... Хәер, калуымнан нинди куаныч булды соң? — һәм ул үзенең фаҗигале хикәясен сөйләп китте.

Аны иптәшләре көн урталарында гына эзләп тапканнар. Түмгәккә капланып, аңсыз яткан хәлендә күтәреп алганнар да «Чәчәкләр яланы»на чыгарганнар. Анда, бит-күзләрен юып, каннарыннан арчып, бәйләп яткыргач, кичкә таба аңына килгән. Сугышчылар аңа, үзләренә юкны табып, авызларыннан актык сохарыйларын өзеп биргәннәр. Әлбидә аякка басып, йөри башлаган...

— Ләкин «Чәчәкләр яланы» коткару китермәде, — диде Әлбидә, үкенечле тавыш белән, — ә менә монда китерде... һәм без монда икенче бәлагә килеп тарыдык. Без җинаять эшлибез: үз кешеләребезне үтерер өчен снарядлар ясыйбыз...

— Әйе-е, — диде Муса, уйга калып, — без барыбыз да монда теге яки бу рәвештә җинаять эшлибез. Кайчан да булса аларның һәммәсе өчен дә җавап бирәсе булыр... Кыен, бик кыен...

— Мин дә шулай уйлыйм бу хакта, — дип көрсенде кыз. — Сез дә бик үзгәргәнсез. Бу кыяфәтегез белән элекке Муса абыйга бер дә охшамыйсыз... Хәрби әсир һәм сәяси эшче буларак, лагерьларда черергә тиеш идегез... Ә сезнең өстә менә диген цивильный кием һәм үзегез Берлин урамнарында рәхәтләнеп ирektә йөрисез икән... Моны ничек аңларга?..

Муса кыенсынып калды. Тиз генә җавап бирү һәм ышандыру өчен сүзләр көчсез булыр иде. Бар булганнарны бөтен бәйнәсе белән сөйләп бирү дә мөмкин түгел..., Ул аңа, дуслык күзләре белән көлемсерәп, озак карап утырды. Кыскача гына аңлатып та маташты, ләкин, чынлап та, сүзләрнең көче җитмәде, ахры, Әлбидә ышанмады.

— Шулай әйтелә инде ул... — дип, тирән сулап куйды. — Без, ичмаса, куып китерелгән коллар: урам себертсәләр дә, металл кырдырсалар да — чарабыз юк. Ә сез?.. Егетләрчә үлә дә белмәдегезме?.. — Ул хәтта Муса яныннан чигенебрәк утырды. Гүяки, «Йогышы тимәсен бу әдәмнең!» дия иде.

Муса маңгай тирләрен сөртеп куйды. Суык иде ул тирләр. Бит инкелләрендә ниндидер күгәренке тимгелләр төерләнеп уйнады. Башкаларның шикләнүе әле бер хәл иде, ә менә үзенә карата изге хисләр саклап йөргән бу михнәтче кыз да шулай уйлагач, нишләргә соң инде, аның күңелен ничек яктыртырга? Форманың эчтәлекне билгели алмавы

белән генә инандырып булырмы аны? Ант итәргә тотынсаң да бик көлке килеп чыгачак...

— Син бик рәхимсез һөҗүм итәсең бит әле, — диде ул, һәмишә көлемсерәп. — Әйе, егет үлеме егетчә булырга тиеш. Әмма егеткә кайчакта фәкать бет белән сугышып кына үләргә дә туры килә. Андый очракта нишләргә соң?.. Хәтерлисеңме, Әлбидә, безнең Волхов разведчикларының бик матур маскхалаты була торган иде. Нәкъ табигатьнең үзе төсле! Аны киеп хәтта карнавал кичләрендә дә йөрергә мөмкин. Ә шундый ук маскхалат мондагы карнавал өчен дә кирәк булса?..

Әлбидә аңа үзенең моңлы күзләре белән бик ягымлы карап куйды. Юк, күңеле аның бу ямьсез шикләрне куарга куша иде.

— Менә күптән шулай кирәк ләбаса! Яратам шушы карашыңны! — дип елмайды Муса. — Безнең әле, сайрар кошым, синең белән бик матур итеп көрәшкән чаклар күп булыр, куанычлы эшләр дә табылыр!..

Әлбидәнең зур коңгырт күзләре тагын гаҗәпләнү белән тулган иде. Бу минутта аның тагын әллә кай җире генә, — шул матур күзләренең моңсу каравымы яки саран гына елмаюымы, — Әминәне хәтерләтә иде. Мусаның аны үз газизе итеп күкрәгенә кысасы килде.

— Муса абый, җаным! — дип, Әлбидә аның иңбашына үзе сыенды. — Сез бик катлаулы кеше: кыен да, рәхәт тә сезнең белән. Димәк, зур эшләр бар алайса?..

Муса туп-туры гына җавап бирмәде.

— Исән-сау килеш керсез намус белән туган җирләребезгә кайтсак, без нинди бәхетле булачакбыз!.. Бергә кайтырбыз, яме, Әлбидәкәй, — диде ул. Аның сүзләре ничектер үтә йомшак һәм ягымлы булып, җан рәхәте биргәндәй булып ишетелде.

— Җә, — дип көлде Әлбидә, сабыйларча. — Бик кызык әйттегез, бала чаклар искә төшеп куйды. Әйтерсең, бәләкәй малай белән бәләкәй кыз сөйләшә...

Кайтырга вакыт иде. Иптәшләре әйләнеп килде.

— Иә, айныштыгызмы инде? — дип көлә башлады Фоат. — Ай-яй сезнең гыйшыклар каты икән! Бер-берен күргәч, чүт кенә аяктан егылмадылар.

— Ләйлә вә Мәҗнүн! — дип кычкырды Сания.

Алиш аңа бармак янады.

— Кара, кызый, кем кәҗәсе кычкырса да кычкырсын, синең кәҗәң тик торсын! — диде ул. — Син бит үзең Ләйлә. Ә Мәҗнүнеңне юри алып килмәдек бүген.

— Ул үзе дә юлны яхшы белә! — дип көлде Сания. — Зарыктырмый алай.

Алар, һәрбере шулай үз өлешенә тигән уртак хәсрәтне эчкә йотып, бөтенләй шат күңелле яшьләрчә уен-көлке сөйләшкән булып, тагын килергә вәгъдәләр биреп аерылыштылар. Юлда Фоат Мусаны һаман үтмәс пычкы белән кисә кайтты.

— Ай-яй, дустым, астыртын кеше икән син, ә! Шундый кыз хакында ләм-мим әйткәнең юк безгә.

Муса яшь егетләрчә ык-мык килде, кызарынды, нәрсәсен әйтәсең аның, фронт танышы гына ич, дип карады. Шулай да аны тыңдырмадылар. Алиш та бәйләнде. Һәм Муса үзенең Волхов хикәясен сөйләп бирергә мәҗбүр булды.

### III

Яраткан кешең сиңа нинди генә якын һәм кадерле булса да, әгәр син аның инде дөньяда юклыгын, аның белән күрешү мөмкин түгеллеген яхшы белсәң, ул синең хәтер күгеңнән әкренләп кенә ерагая бара һәм, таң алдындагы йолдыз шикелле, офыкның иң аргы читләренә

китеп, сизелми генә сүнеп тә кала. Әлбиданең күңел күгендәге Муса да шулай сиздерми генә сүрелеп бара иде. Башта ул, аны саклый алмавы өчен үзен әрләп, агач араларында елап йөрде. Аннары немец самолетлары килми башлагач һәм сазлыкның теге ягыннан атулар туктагач, билдән югары пычрак су — тимер тутыгы һәм кан төереләре төсле кызгылт күбекле болганчык сыекча — ерып, Мусаның үле гәүдәсен эзләде; әллә нинди кул кисәкләре, сыйрак ватыклары, гәүдә калдыклары туры килде, әмма Муса мәете яки аныкын хәтерләткән пилотка гына булса да очрамады. Шуннан соң аның үксеп, әрнеп елаулары тагын да көчәеп китте. «Ник саклый алмадым? Ник алга киттем? Янәшә генә барган булсам, ичмаса бергә үләр идек!» — дип үкенде ул. Елый торгач, яшьләре дә кипте, тик коры сулкылдау гына, сынык күңел генә калды, күзләре әчетә башлады. Кешеләрдән читкәрәк агач арасына китеп, сәгатьләр буе моңаеп утырды, боек тавышы белән әкрен генә «Сагыну»ны җырлау һәм теге зур авыл күле буендагы беренче очрашуны ничектер якты, матур итеп искә алулар бердәнбер юаныч булып китте. Атауга чыккач та ул аның партбилетын кояшта киптереп, үзенең комсомол билеты белән бергә пергаментка төрде һәм күкрәк кесәсендә йөртә башлады. Ә Муса биргән дәфтәрнең шәмәхә карандаш белән язылган һәр битендәге шигырь, су белән җәелеп, бөтенләй танымаслык хәлгә килгән иде. Никадәр генә тырышып киптерсә дә Әлбидә ул шигырьләрне укый алмады. Дәфтәрне ташлаудан башка чара калмаган иде. Ялгыз моңаеп утырган чакларда шул дәфтәрне актаргалый да, ул һични сөйләмәгәч, партбилетны кулына ала һәм андагы бәләкәй генә рәсемгә озак-озак карап онтыла иде. Документ өчен формаль рәвештә генә төшерелгән бу рәсем кисәге бик җансыз һәм хәтта бер почмагына су табы җәелгән булса да, Әлбидәгә көлемсерәп карый, үзенең иң изге серләрен сөйли кебек тоела иде. Юк, кечкенә генә партбилет эчендә дә, кара туш белән кемдер тарафыннан язылган җансыз сүзләр түгел, Мусаның үз сүзләре: туган елын да, партиягә кергән вакытын да, бу билетны кайсы райкомнан алганын да, ай саен күпме взнос түләгәннәрен дә үзе әйтеп бирә, һәм шул гади генә сүзләрдән дә рәхәт булып китә. Өмет үз учагының сүнеп барган күмерләрен яңадан тергезә башлый. Муса каядыр киткән генә яки икенче бер атауда бүленеп кенә калган, менә озакламый, шул кыяк һәм камышлар, таллар арасыннан кайтып та килер төсле тоела...

Әмма алай булып чыкмады. Көннән-көн көчәя барган гомуми бәла, гомуми гаҗизлек һәм михнәтләр Әлбидәне дә үз эченә бөтереп алды. Күпме генә омтылып карасалар да, сазламык һәм күлләрне ерып үзебезнең якка чыгу юлы табылмады. Байтак вак төркемнәр, хәтта кире дә борылып кайта алмыйча, батып үлделәр. Рация-фәлән аша тыл белән бәйләнеш, азык-төлек ташлату хыялы да барып чыкмады. Эфирдәге ниндидер өметле тавышларны тота башлагач кына, актык рациянең актык батареяләре бетеп, эштән туктады, төркем башлыгы ачуыннан аны күлгә үк ыргытып бәрде... Яшел үсемлекләрнең ашардае ашалып, күн итек куныччларына хәтле чәйнәлеп беткәч, коточкыч ачлык, тиф һәм дизентерия башланды. Көн саен дистәләрчә кешегә медицина ярдәме кирәк, ә даруларның иң гадиләре дә юк. Әлбидә шул кешеләрне үлем авызыннан тартып алмакчы булып, көн буе чабудан туктамый, тик караңгы төшкәч кенә үз нараты төбенә килеп, ылыс түшәге өстенә ава. Ярый әле бердәнбер плащпалаткасы бар. Шул — яңгырдан да, төнге салкыннан да, озынборыннан да — һәммәсеннән дә саклый бирә.

Ниһаять, бу фаҗигый көннәрнең актык сәгатьләре дә килеп житте. Немецлар алар өстенә ут ача башлады. «Чәчәкләр яланы» — «үлем яланы»на әйләнде. Мусаның да әнә шул камышлар артыннан гына килеп чыгу ихтималы юклыгы ачык иде инде. Әлбидә үзе дә шушында һәлак булачак. Яралыларга һәм үлүчеләргә ярдәм күрсәтеп йөргәндә,

очраклы бер тинтәк пуля яки мина кыйпылчыгы бәреп егуын көтеп йөрде ул. Кыен мәсьәләнең иң ансат чишелеше шунда булыр кебек тоелды. Әмма ни өчендер андый пуля очрамады. Ә инде үз-үзенә касд кылу шикелле куркыныч эшкә Әлбидәнең куллары, әлбәттә, бармаячак, чөнки аның табигате бөтенләй башкача яратылган. Бу утрауда нинди дә булса ярдәмгә мохтаҗ бер генә кеше калганда да, ни җаны белән Әлбидә аны ташлап китсен?..

Шуңа күрә алдагы билгесез язмышка буйсынып, аның нинди булачагын артык уйламастан, кызлар табигатенчә үз генә тәкъдир-фәләнгә дә ышанып: «Күрәсеңне күрмичә, кара гүргә кермисең», дибрәк яши бирде ул. Тик бер мөһим нәрсәне генә онытмады: моңарчы кесәсендә йөрткән ике билетны инде хәзер каядыр куярга кирәк иде. Ул үзе ни күрсә дә күрсен, әмма бу изге нәрсәләргә һичбер төрле пычрак куллар кагылмаска тиеш. Берсе бигрәк тә: Муса амәнәте... Хәер, үз билеты да шулай ук кадерле. Ул аның беренче чәчәктәй яшьлегенең истәлеге. Техникумда ул аны алган көнне үзен буйга җиткән санап, дөньяга сыймастай куанып йөргән иде. Һәм шул кызыл тышлы билетын кер тидерми йөрткән кебек, яшьлек намусын да саф көенә саклап йөртте ул. Юк, очраклы хисләргә бирелмәде: малайларның матурлары да, кыюлары да, телгә осталары да туры килгәләде, әмма берсен дә үз итеп сайлый алмады. «Ах, бу минеке!» дип әйтмәде йөрәге. Яшьлекнең беренче зәңгәр ялкыннары хәтта шулай сүрелә башлагандай тоелды. Ә менә монда, Волхов буендагы кара урман эчендә, сугыш дулаган бөтенләй урынсыз чакта — нәрсә булды соң аңа? Нигә болай кинәт кенә, көтелмәгәндә генә кабынып китте аның йөрәге? Һәм тиле түгел диген: шул мөлаем көләч йөзле, бәләкәй генә буйлы шагыйрьне, Әлбидәнең үзеннән күп олы яшьтәге кешене, сөйде дә куйды бит! Нигә кирәк иде? Ул — тигезсез сөю, бәхет, рәхәт китерми торган, кавышу мөмкин булмаган мәхәббәт иде бит. Һәм бу татлы газап шунда ук киселеп тә калды. Ай күрде, кояш алды Мусаны. Юк инде ул... Кул төпләреннән эзләп тә тапмады...

Әлбидә үз наратының җәптәш тамырлары арасындагы чокыр урынны хәлсез бармаклары белән казып утырды. Ком катыш дымлы соргылт балчык һаман өскә өелә бара иде. Чокыр шактый тирәнәйде. Якында гына беркем дә юк, шуңа күрә аны һичкем тарыктырмады, ул иркенләп хәрәкәт итте. Күкрәк кесәсендәге билетларны чыгарды да, рәсемле битләрен ачып, озак кына карап торды. Соңгы карау, соңгы саубуллашу иде бу. Аннары аларны пергаментка төреп, уртадан резин бау белән буды. Каяндыр ылыс астыннан даруы беткән пыяла банка тартып алды да төргән билетларны колашаландырыбрак шуның эченә төшерде. Башына калай капкач киертте, аның өстенә тагын пергамент бөркәп, резин бау белән кысты. Шуннан соң банканы чокыр төбенә утыртты да күмә башлады. Бармаклары белән пыяла банка читләренә балчык өя барган саен уйлары тагын да куерып китте: партбилет күмә... Комсомол билеты күмә... Бу үзе генә дә нинди коточкыч хәл! Күмәр өчен бирелгәнмени алар? Ник аларны гомер буе үз янында йөртергә мөмкин түгел? Әлбидә аның партбилетын монда күмеп калдыра, ә ул аны кайчан килеп алыр? Юк шул, килә алмас инде ул... Күрәсең, Әлбидә монда Мусаның партбилетын гына түгел, аның үзен күмеп калдыра... Йөрәге кинәт ялкынланып сөйгән шагыйрь абыйсын һәм аның белән бергә үзенең шундый үзәк өзгеч үкенечле мәхәббәтен күмеп калдыра. Нинди авыр. Күз яшьләрең булсын иде, ела идең бер! Ләкин алар, ком чүлендәге су тамчылары шикелле, әллә кайчан кибеп очканнар... Әйдә, булгач булсын инде, комсомол билеты белән бергә тамчы гөлдәй яшьлеге дә шул мәхәббәт янында күмелеп калсын. Кыска гомерендә бер генә тапкыр сөеп, бер генә тапкыр канатланган яшьлек — үз сөюе өстендә гөл бәйләме булып ятсын. Юк, бу нечкәләнү, төчеләнү түгел. Үз тирә-

ягында бер генә таяныч та, бер генә өмет тә калмаган кешенең үз күңелендәге иң газиз хисләре белән актык мәртәбә бәхилләшүе генә...

Әлбидә чокырны күмеп бетерде. Өскә калкып тормасын өчен йодрыгы белән төйгечләп чыкты, аннары читтәге кыяк төпләреннән чирәм кисәкләре кубарып алып, «кабер» өстенә түшәде. Сизелеп тормасын дип эшләде ул аны. Әмма моның белән генә эш бетмәгән, нәрсәдер җитмәгән кебек тоелды. Шуннан соң аргы баштагы ташландык кораллар яткан урыннан бер кәкре шомпол алып килде. Чыбык-чабык җыеп ут тергезде дә, шомполның сырлы башын утта кыздырып, нарат кәүсәсенә «Б» хәрефе басты. Ул аны бик тирән итеп, наратның сөягенә кадәр яндырырга тырышты. Монысы нигә иде соң? Башта ул аны үзе дә аңламады. Күп хәрәкәтләрен, айнык акыл кушудан бигрәк, ниндидер аңсыз инстинкт кушуы белән механик төстә генә ясады. Хәреф, каерыдан сагыз исләре чыгара-чыгара, карт нарат тәнендә мәңге бетмәс билгедәй ыржаеп калгач кына, Әлбидә төшенеп алды: кара әле, ул бит монда кайчан да бер килергә җыена икән ләбаса! Үзе дә сизмәстән, яшәргә тели!.. Әйе, Мусаның коммунист булып үлүен бары тик Әлбидә генә күрде бит. Ул аны нинди генә хәлләрдә дә актык сулышынча якларга тиеш! Бу аның намус бурычы...

Шуннан соң Әлбидәнең күңеленә җиңел булып китте. Ниндидер тынычлык тагын да тирәнрәк урнашкан кебек тоелды. Һәм шуның белән бергә Муса образы да каядыр югары күтәрелепме, әллә күңел түренә сеңепме, ничектер ата-баба кабере сыман, кадерле һәм изге ераклыктан гына күренә башлады...

«Чәчәкләр яланы»ннан бер каршылык та күрсәтелми башлагач, немецлар ажгырып басып керделәр. Дистәләп кенә калган хәлсезләрне сөреп алып киттеләр. Волхов буйларыннан Берлингача җәяү атлап, мең михнәтләр кичереп килгәндә дә Әлбидәнең Муса өчен өзгәләнүләре тагын да кими төшкәндәй булды, ул һаман еракта кала барды... Әсирлек газаплары, ачка интегүләр һәм әйтеп бетергесез бөтен мәрхүмлекләр аның йөрәк-бәгырен яндырып күмер иттеләр, тышкы чыраена картлык чалымнары сыздылар, кайчандыр дулкын-дулкын кабарып торган чәчләренә сөек төтен сиптеләр, кайчандыр балкып торган матур йөзле яшь Әлбидәне танымаслык хәлгә китерделәр.

Ул инде хәзер немец таләп иткәнне эшләп бирә торган җансыз һәм телсез машинага әйләнеп бара иде. Ул инде хәзер көлү, елмаю, куанычларны гына түгел, кайчан да булса туган илгә кайту кебек иң гади өметләрне дә, Волхов буендагы «Чәчәкләр яланы»нда калган изге наратны да, аның төбенә күмелгән мөкатдәс хисләрне дә бөтенләй диярлек оныту дәрәҗәсенә килгән бер җан иясе иде. Муса сурәте айлар буена аның күңеленә дә килми хәзер. Кайчагында, әллә ничек, очраклы гына хәтеренә килгәндә дә: «Үлгән — беткән. Үземә дә үләр көннәр җиткән» дип кенә куя, һәм бу кирәксез уйларны тизрәк күңеленнән куып чыгара башлый иде ул.

Шулай тәмам сүнеп беткәч инде, бары тик кешеләргә ияреп, инерция белән генә Аккүл буенда йөргәндә кинәт Мусаны очрату — аның өчен бер могҗиза булып, әллә кайчан үлгән кешенең кабердән кубарылып кайтуы, яки, кинәт кенә зәңгәр күк түбәсе ачылып, оҗмах чәчәкләре җиргә коелуы шикелле, гайре табигый бер хәл булып тоелды. Бөтен кеше алдында «Ай!» дип кычкырып куюы, күкрәк сөякләрен җимердәй хәлдә йөрәге сикерүдән һәм саташу дәрәҗәсенә барып җитүдән иде. Аның башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте, шунда ук тагын яктырды, вак кисәкләргә чәчелгән яшен утлары төсле күбәләкләр очкан сыман, шул күлдә аккошлар тавыш биргән сыман һәм Муса шушы секундта ук яңадан югалыр сыман тоелды. Һәм ул һичнигә, һичкемгә карамастан, исәпләшмәстән, Муса күкрәгенә капланды. Юк, йө-

рәк үлеп бетмәгән икән лә! «Әһ» дигән бер сулыш эчендә терелеп ел-герде һәм үз газизен яңадан югалтудан курка да башлады...

Шул минуттан алып, ул көнне көн буе һәм төн буе Әлбидә ниндидер сихри төш һәм татлы саташу эчендә уздырды. Иптәшләреннән беркемгә дә рәтләп җавап бирә алмады. Аңа карап, гаҗәпләнү белән көлемсерә-деләр. Ләкин ул: «И, зиһеннәрем бик таралган шул...» дип кенә куйды. Ә төнлә белән йокы дигән нәрсәне бөтенләй онытып ятты-ятты да, март салкынында эчке күлмәктән генә тышка чыгып, баскыч төбендә-ге эскәмиягә утырды һәм кычкырып җырлый башлады:

«Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Юлларыңа тезәм мин.
Бик сагындым, бәгырем,
Бик саргайдым инде,
Әле дә ничек түзәм мин!..»

Җырны ул тагын үз хәленә яраштырып җырлады. Үзенең, чынлап та, ут куырган гөл кебек, тоткында саргаюын, чиксез михнәтләр күрүен әйтергә, Мусага ишеттерергә теләде ул. Аның тавышы баштан калтыра-ныбрак, беркадәр карлыгыбрак чыкты, аннары көчәйде, тирәнгә һәм киңлеккә китте. Аның күптән җырлаганы юк иде, чөнки ул җырлап юану хәленнән дә узган иде инде.

Бәлки ул шунда таң аттырган да булыр иде, тик иптәшләре мөмкин-лек бирмәделәр. Сания чыгып алды аны. «И, диванакаем, әйдә керик, суык тиеп үләсең бит!» дип, урынына кертеп яткырды.

Шуннан башлап һәр көнне Әлбидә яшь кызлар түземсезлеге белән Мусаны көтте. Аңа әйтәсе сүзләрен, үзе кичергән озын-озын хикәяләрен көн буе үзенә сөйләп йөрде. Күңелендә көннән-көн кыю уйлар туа бар-ды. Саф мәхәббәтнең юлын кисеп торучы гаилә киртәләрен җимереп ташлардай тәвәккәл һәм татлы хыяллар белән мавыга иде ул. Чынлап та, инде үлде дип, күпме үкенечле яшьләр түгеп, язмышның ниндидер бәхетле бер очрагы белән яңадан күрешкәч, Әлбидәнең соң Муса абый-сын ачыктан-ачык рәхәтләнеп сөяргә һәм мәңгегә үзенеке итәргә хакы юкмыни?.. Барын бар, әлбәттә... Ләкин әнә нинди бит әле ул... Әллә кем сыманрак күренә, элекке шикелле, чишмә суыдай тонык түгел... Нәрсә-ләрдер әйтеп бетерми... Юк, ничек кенә булмасын, Мусаны сөяргә, үзе сөелергә барыбер хакы бар Әлбидәнең! Шушы каһәр төшкән җирләрдә, ичмаса, мәхәббәт җылысы белән яшәрләр, бер-берен бәхетле итәргә тырышырлар. Теләсә ни булсын, теләсә ни күрсен, ул инде ут эчендә тапкан сөеклесен һичкемгә бирмәс!.. Ләкин... Ләкин...

Әлбидәгә берәү дә каршы килмәде. Чөнки ул бер ялгызы уйлана иде. Әмма шулай да, аның фикерләренә кемдер каршы төшәр, аларның ялгыш икәнен фаш итәр, «Син үз бәхетең өчен икенче берәүләрне ела-тырга, гаилә җимерергә уйлыйсың!» дип әрләр кебек тоела. «Юк, ди Әлбидә, алай түгел, алай гына аңлау — артык сай!..» Һәм ул тагын бәхәскә кереп китә. Озак кына тартышканнан соң тынып кала. Тынып калгач, кинәт әллә каян төптән, бөтенләй яңа бер тавыш килә: «Һай, Әлбидә, нинди ямьсез уйлар белән пыскыйсың син!..» Кызның якты чырае дәррәү сүрелә, бизгәк тоткандагы шикелле туңып, тәннәре чымыр-дап китә. Бу нинди газап соң бу?..

Әлбидә шундый авыр хәлдә ай буена диярлек Мусаны көтте. Аның тиз килмәвенә үпкәләмәде ул. Юк, нигә үпкәләсен, эше күптер. Алай тар холыклы булу — акыллы кеше гадәте түгел. Исән генә булсын — килер!..

Ә Муса, чынлап та, тиз килә алмады шул. Бердән, Әлбидәнең шулай зарыгып көткәнен белмәде һәм шундый катлаулы уйлар белән алҗуын башына да китермәде ул. Әгәр белгән булса, һичшиксез, барып юаткач булыр иде. Икенчедән, Муса күңелендә андый кайнар утлар янмый, Әлбидәне борчыган проблемалар аның өчен бөтенләй яшәмиләр иде.

Ул аны һаман да бары тик һәйбәт, акыллы кыз итеп, якташ һәм михнәттәш дус итеп, кай җирендер Әминәгә охшатса да, сеңелесеседәй якын туган итеп кенә ярата иде. Шунлыктан Әлбидә белән күрешергә йөрү мәсьәләсе дә Мусаның күңеленә һәм вөҗданына кагыла торган мөһим нәрсә булмады. Менә бер бушаганда иптәшләре белән барып, хәлен белеп кайтыр әле... Һәм ул, Әлбидә белән саубуллашмаган да килеш, яңадан Польша җирләренә чыгып китте.

Бу хәбәрне ишеткәч, Әлбидә олы һәм тирән кайгыга төште. Күңеле нәрсәдер сизеп алды. Нәрсәдер түгел, салкынлык сизеп алды аның күңеле. Чөнки йөрәк һәрвакыт үз ялкынына каршы икенче бер якты ялкынның дөрләп кабынуын көтте. Әгәр шул ялкын булмаса, ул күкрәк читлеген тарсына, борсалана башлый. Бөтен дөнья суык булып күренә. Әлбидәнең йөрәге дә шул ук хәлне кичерде. Кызга дөнья йөзе моңсу һәм куанычсыз булып күренде. Яратмый микәнни соң?.. Эх, бу йөрәк! Ник соң шул тынган килеш мәңгегә үлеп калмады, ник яңадан кабынып, яңа утлар эченә салды ул аны!..

Аннары ул үз-үзен тынычландырырга тырышты: мин бит инде олы кеше хәзер... Тукта, өзгәләнмим, сабыр итим. Сабыр төбе — сары алтын... Кайтыр, күрешербез, сөйләшербез...

## IV

Шәфи Алмаз үз кабинетына Карип Ишбулдинны чакырып алды да туйганчы мыскыл итте:

— Ишәк син! — дип башлады ул, аеруча бер зәһәр ләззәтләнү тавышы белән. — Ишәк бине Ишәк Әл-Ишәки! Һаман сиңа күшәргә булсын да, әфиүнче хәлфәләр кебек сәрхушланырга булсын. Ә сәрхушлангач инде «кабарэ»дагы өч тиенлек «тәтәй»ләр булсын! Башкача син һични күрмисең, ишетмисең, белмисең! Алла сиңа кургаш күз биргән, чүбек колак, туң маңгай. Берсенең бер тиенгә ярарлыгы юк! Хәер, ходай сиңа эт теледәй салынып төшкән озын тел биргән тагын. Табак ялап гомер итәр өчен кирәк булыр дигәндер инде...— Шундый «тәмле» сүзләр тагын озак дәвам итте.

Ишбулдин бер агарды, бер күгәрде. Бу хурлауның нинди гөнаһ өчен булуын аңламады. Уенга алып, үзе дә көлгән булды. Алай да барып чыкмагач — кызарды, бүртенде дә:

— Я инде, Гаптрахман абый, нәрсәдә соң минем шундый зур гаебем? Кичер инде,— дип ялына-ялвара башлады.

— Нәрсәдә, имеш! — дип кычкырды Шәфи. — Кара әле, кемәй, эңкәш, син чынлап та шундый аңгыра бәрәнме, әллә юрамалый белмәмешкә салына торган хәйләкәр шайтанмы? Астыртын гына большевикләр табагын да ялыйсыңмы?!

— Гаптрахман абый! Җаным! Сез бигрәк хәкыйрь итәсез инде, бигрәк усал әйтәсез...

— Әйтәм икән — хакым бар! Мин сиңа Вермахт жалуниясеннән тыш өстәмә жалуния түлим. Һәм гел бушка түлим. Чөнки эше нәрсә бит? Уен! Ә син шул бәйрәм уенын уйнарга да иренәсең, Хөрәсән ялкавы!

Карип Ишбулдин бигрәк тә аптырап калды. Нидер әйтергә теләп тә сүзләре чыкмаганлыктан, бөкеле мылтык тавышы белән авызы гына шапылдап куйгалый иде. Шактый азапланганнан соң гына сүз куәсе таба алды:

— Гаптрахман абый, дим, алла хакы өчен кичерегез! Әйтегез, ни кушасыз? Валлаһи хәзер үк эшлим!

— Нигә яңаны кушу? Иске кушканны эшләгәнең юк бит әле.

— Һич төшенмим... — дип аптырады Карип.

— Ах, тинтәк, тинтәк! Сиңа бит әллә кайчан ук инде Алиш белән дус булырга кушылган. Нинди изге һәм нинди ансат эш: кеше белән дус булу! Моның нинди кыенлыгы бар? Ә син, ахмак, оныткансың да шуны!

Ишбулдинның чырае тагын да караңгыланды. Алиш белән дус булу... Әйтүе генә җиңел! Бер дә онытмаган, көн-төн чаба Карип аның артыннан. Тик бөтен фаҗига шунда ки, Алиш шома балык шикелле: дуслык җәтмәсенә эләктереп, инде саңагыннан алам дигәндә генә кулыңнан шуып чыга да суга чума! Хәер, алай гынамы соң әле: ул үзе Карипкә аяк чала. Ул үзе аны керпе бияләй белән кысмакчы була!..

— Бер дә онытмадым, Гаптрахман абый җаным! — дип өтәләнде Ишбулдин, җәберсенгән кыяфәт белән. — Мин инде, сайрар кош булып, аның авызына керердәй торам, аны сыйлар өчен күпме маркалар исраф иттем, ә ул һаман ышанмый да ышанмый...

— Менә шул шул: ышанмый! — дип, тагын зәһәрләнде Шәфи. — Ышандыра алмыйсың! Сине дус санаса — бер үзе командировкага китәр идеме ул? Син әгәр йоклаган җасус булмасаң, Алишның күләгәседәй йөрер идең артыннан! Булат белән Шабай да китеп барды. Рәсми яктан караганда — йомышлары мөһим, ничек җибәрмәсен ОКВ? Ә кем күз-колак була аларга?..

— Ә сез, Гаптрахман абый, үзегез дә миңа таяныч бирмисез... — дип теш күрсәтергә теләде Карип, — Алиш мине кыса. Минем язганнарны гәзиткә һәм әдәби журналга кертми калдыру ягын карый. Ул моның өчен әллә нинди оста һәм хәйләле җаваплар таба сезнең каршыда. Икәү генә калганда мине эт итеп сүгә: туган ил каршында оятың бармы синең әз генә, ди. Теңкәгә тия... Сез дә аны күп вакыт яклыйсыз...

— Яклыйсыз, имеш! — дип үчекләде Шәфи аны. — Бар да синең үз җебегәнлегеңнән! Син аягүрә Сәвит сүгеп, камунис сүгеп кенә дан чыгармакчы буласың. Рәтлерәк талант бар икән — остарак кылан. Баллырак итеп имезлек каптыр легион солдатларына! Ә син күсәк белән орасың алар башына. Алишка менә шул ошамый торгандыр. Чөнки ул акыллы егет, төпле итеп сөйләшә белә, ышандыра белә!..

Карип әйтер сүз тапмады. Шәфи дә дулавыннан тукталып калды. Карип өзми-төтми тәмәке суырды, йөткергәләп куйды. Шәфи, ниндидер кәгазьләр укып, кул куйганнан соң аларны өстәл астына тыкты да аягүрә басты. Карипкә карады, шуннан коры гына әйтеп салды:

— Һич булганчы, кич булсын, дигәннәр... Шулай да син, байгыш, иртәгә иртүк легионга кит. Очрат аларны, бергә бул. Ә калган ягын моннан соң үзең бел!

— Бик яхшы, Гаптрахман абый, бик яхшы! — дип дәртләнеп китте Ишбулдин. — Була ул, бирдерегез самолет — бүген үк китәм!

— Самолетка мәкинә төямиләр, энкәш... Ярар, поезд белән китсәң дә...

Иртәгесен Карип Польшага китеп барды. Бу аның өчен үзе бер яңалык булды бит әле. Тукта, шушы тәти формаларын кигән килеш, элек үзе яткан Седельце лагерена да кагылып чыксын әле ул. Күрсеннәр анда калганнар Карип абзалары ничегрәк хәзер! Алишларның да күрер ул нишләп йөргәннәрен!

Карип Ишбулдинның хыяллары шулай матур иде матурлыгын, тик ул аларның ләззәтен генә татый алмады, чөнки ул киткәч, бер тәүлектән соң Алишлар Берлинга кайтып төштеләр. Алар кайтып киткән булгач, ничек анда озаклап йөрмәк кирәк?.. Тагын Гаптрахман абзасы үтмәс пычак белән тунар инде...

Ә егетләр, чынлап та, күп эш башкарып кайткан булып чыктылар. Моны алар иң элек Мусага сөйләделәр. Ул әйткән кешеләрнең һәммәсе белән күрешү, яшерен эшләрне һаман көчәйтү чаралары өстенә, әллә ни хәтле яңа кешеләр тапканнар. Алиш ышанычлы егетләрдән унбишләп хәбәрче сайлап алып, алар белән кыска бер семинар да уздырган. Шуларның иң кыю һәм иң таянырдай унлабын яшерен оешмага да тарткан.

Фоат Булатов исә беренче нәүбәттә Берлинга экскурсиягә киләсе төркемнәрнең исемлеген әзерләп, тегендәге командование белән хәл итеп кайткан, иң элек үзебезнең патриот хисле егетләр күздә тотылган. Алар белән монда, экскурсияне сылтау итеп, күп кенә эш алып барырга кирәк булачак... Муса боларны бик рәхәтләнеп тыңлап утырды.

— Менә бу шәп булган егетләр! Бер баруда ук дөньясын әйләндереп җибәргәнсез, — дип көлде ул. — Икенче тапкыр барсагыз, легионда бөтенләй революция ясап ташлавыгыз мөмкин! Болай булгач, агачлар яфрак яру белән батальоннарны алып, изге сәфәребезгә юнәлергә дә мөмкинлек туачак!..

Тик Мусаның кордашы Гариф Шабаевның гына күңеле сүрән иде. Һәм менә хәзер ул ашыгып сөйләргә тотынды:

— Китүен китәрбез, әмма Демблин белән Седельцедагы ач, авыру солдатларны нишләтербез? — диде ул, пошынып. — Ә алар безнең кешеләрнең чәчәге икән лабаса. Мин аларның бик күбесе белән сөйләштем: хәтта ачлыктан үләргә дә риза булып ятулары легиончы булырга теләмәүдән икән.

— Нәкъ теге вакытта без уйлаганча! — дип куйды Булатов. — Кыен шул андый адым намуслы кешегә, әгәр күңелендә бер максат тумаса.

— Әмма боларның күңелендә индивидуаль бер өмет бар: янәсе, менә ул әзрәк рәтләнә дә җәй килеп җиту белән кача! Ә үзе көннән-көн үлем чокырына тәгәри барганын сизми.

— Ничек соң, чеметкәләп карамадыңмы үзләрен? — дип сорады Муса, борчылып.

— Авыз ачкалаган идем, сөяк тукмаклар ява язды ипи шүрлегемә, — диде Гариф. — Күзләре акая. «Безне сатып алырга килдеңме, сволочь немец койрыгы!?» — дип ысылдыйлар. Курыкмыйлар да! Шундыйларның берсен, үземне лагерь башлыгына озата барырга кушып, читкә алып киттем. Күзләренә текәлдем, күзләрендә әллә нинди шомлы ут яна: әллә мине сугып үтерергә тели тагы — аңламассың. Үзе кыртыш сөяк булып кипкән, олы гәүдәле, чигәләре ак, әллә нинди тимер сакалмыек баскан, ике кулын да йомарлаган... Ул миңа акыллырак сыман тоелган иде башта талашканда. Күзләренә кадалып тордым-тордым да әйттем: «Син коммунистмы, әйт, анаңны сатыйм!» — дидем. Моның ач яңакларындагы сеңгер төерләре күгәреп чыгып, вак шайтаннардай биеп алды, йодрыклары калтыранырга тотынды. «Анда синең ни эшең бар? Ник өрәсең эт шикелле!» — диде бу. «Юк, мин әйтәм, эт кенәме соң, бүре булып улар хәлгә җиттем мин хәзер! Син яшерсәң, мин яшермим: коммунист мин! Һәм мин мондагы хәлләрегезгә тәкатьсез калдым!» — дидем. «Кых-кых! — дип көлде бу. — Яңа әкият, диде: сарык тиресе ябынган бүре түгел, бүре тиресе ябынган сарык!.. Фу, валлаһи! Ай-яй шәп шпиговать иткәннәр сезне!..»

Ләкин мин һаман һөҗүм иттем: «Телгә оста син, дус кеше, — дидем,— тик күзең генә чагыр икән: үз борыныңнан арырак һични күрмисең. Ник уйламыйсың бу меңләгән җаннарның язмышы турында?..»

Каклап киптергән бу кеше, ниһаять, йомшара төште, йөзенә ниндидер башка төс чыкты, сыңар күз төбендә сыңар тамчы гына яшь бөртеге елтырагандай булды. «Бәгырьгә кададың...» — диде бу, сынык тавыш белән. Һәм без аңлаштык. Урал кешесе булып чыкты. Карабаш колчедан шахталарында тау техникы һәм, чынлап та, коммунист икән. Оешкан төстә үзебезнең якка качу максаты барлыгын, шуңа хәзерлек барганын аңлаттым, үзенә ышанычлы иптәшләр табарга куштым. Һәм үлсә дә иптәшләрен бирмәскә ант иттердем. Менә шул, — диде Гариф, озын сүзеннән тынып.

— Син кызык икәнсең: кешене сөзеп егу методы белән эченә керәсең икән, — дип көлеште иптәшләре.

— Ярар, — диде Муса, — болай булгач, ул лагерьлардагы кешеләрне коткару җиңеләя төшәр. Ә хәзер Шәфи патшага барыйк. Аны да котыртыйк. Сайлаган егетләрегезне аның теләгенчә күрсәтеп, мактап сөйләгез. Тиешле җирләргә чапсын, безгә кирәк эшне эшләсен.

Шәфинең кабинет тирәсендәге тәртипләр, үзенә калса, президентча куелган иде. Ишекнең ике кырыенда ике сәркатип утыра, килгән кеше иң элек алар иләгеннән үтәргә тиеш, шуннан соң гына, әгәр йомышы бик мөһим булса, Алмаз әфәнде кабул итә. Бүген алай булмады. Гариф Шабаев, үзе Шәфинең «шәхси сәркатибе» булганлыктан, туп-туры кабинет ишеген ачты да, ярыктан борынын гына күрсәтеп: «Мөмкинме?» дип кычкырды һәм эчкә узды. Аның артыннан Алиш, Муса һәм Фоат килеп керделәр. Үз кабинетында кинәт бу егетләрне күргән Шәфи аптырабрак калды:

— Һаэ, — дип куйды ул, очкылык тоткан кешедәй. — Менә сиңа пәрәмә-әч! Кайттыгыз дамыни әле сез, тишекле бер тиеннәр?

— Күрәсез, әфәндем, — диде Гариф, — тәгәрәп килеп алдыгызда ятабыз.

Шәфи Алмаз, хәленнән килгәнчә, көлдереп сөйләшергә тырыша иде. Гарифның шаян сүзенә ул да шундыйрак җавап кайтарды:

— Ярар алайса, ятмагыз идәнгә, утырыгыз мендәргә, җә ярыкка төшеп югалырсыз...

Алиш белән Фоат Зикендорф әфәндедән Шәфигә сәлам тапшырдылар һәм кунакка чакыруын әйттеләр. Аннары легион бүлекчәләрендәге эшләрне ал да гөл итеп сөйләп бирделәр, ике батальон солдатның бүген үк фронтка китәргә һәм бик гайрәт белән кызылларга каршы сугышка әзер торуларын әйттеләр.

— Кәефләре бик шәп егетләрнең! — диде Алиш. — Мин шулар арасыннан унбишләп егетне хәбәрче итеп хәзерләдем. Алар безгә фронттан да язып торачаклар. Монда каласы бүлекләрдән дә ун кешене билгеләдем. Барысы белән дә семинар уздырдым, — дип мактанды ул.

— Ә мин, — дип сүз башлады Булатов, — хәрби өйрәнүләрдә һәм дисциплинада, милли агарту эшләрендә иң яхшы яктан танылган утызлап егетне Берлинга экскурсиягә сайлап алдым. Андый һәйбәт егетләргә башкаланың тарихи урыннарын, сәнгать музейларын, бакчаларын, үзебезнең комитет, газит эшләрен күрсәтергә кирәк, минемчә. Алар арасында җырчы һәм музыкант булганнары да байтак. Берлинда бер татарча концерт уздыру да начар булмас иде...

— Аннары тагын бер мәсьәлә бар, Габдрахман агай, — дип бүлдерде Алиш Фоатны. — Әнә шул һәйбәт егетләрнең үзләрен һәм эшләрен без газетабызда фото ярдәме белән күрсәтә алганыбыз юк. Бу безнең минус. Димәк, безгә бер фотокорреспондент кирәк.

Шәфи икеләнебрәк калды. Бу егетләргә ул моңарчы гел шик белән карый, кичәге коммунистлар дип уйлый, шуңар күрә тыштан ышанган булып күренсә дә, эчтән көлә, артларыннан үзенчә гел күзәтеп кенә тора иде. Карипне алар эзеннән җибәрүе дә шуның өчен булды бит. Тик гамьсезлек ясады ул, шайтан алгыры: теге тинтәк кичә анда китсә, болары бүген монда кайтып төшкән: төп башына утырттылар Шәфине! Ә менә хәзер аларның сүзләрен тыңлагач, ул тагын да ныграк аптырашта калды: чөнки Шәфи алар турында шулай начар уйласа да, Алиш белән Фоат әнә нинди кирәкле эшләр башкарып кайтканнар. Чын күңелдән «Идел-Урал» мәнфәгате өчен сөйлиләр, тегесен-монысын кайгыртканг булалар. Ышанырга соң боларга? Утыртмаслармы болар?.. Хәер, ышанмаслык урын да юк, тәкъдим иткән нәрсәләре дөрес бит. Бакчи син аларны: мөселманлык хисе бетмәгән үзләрендә!.. Ярый, тагын берсен тыңлап карарга кирәк: анысы бигрәк тә кул астындагы кеше ләбаса.

— Ә син ниләр күрдең, Гариф әнкәш? — дип Шабаевка мөрәҗәгать итте ул.

Гариф Шабаев үзенең Седельце һәм Демблин лагерьларында күргәннәрен тагын да дәһшәтлерәк итеп сөйләп бирде.

— Бер Демблин лагеренда гына, ачылган көненнән алып, 95 мең солдат үлгән! — диде ул, имән бармагын югары күтәреп. — Бу бит үзе бер армия дигән сүз. Ә Седельце да нихәтле!.. Әгәр без резервларны шулай үтереп бетерсәк, киләчәктә солдат каян алырбыз? Бу бер ягы. Икенче ягы... — дип, тагын күтәрде ул имән бармагын, — шушы туксан биш меңнең ачтан үлүе аркасында безнең комитет күпме табышын югалткан? Безгә тиешле күпме сәрмәя җилгә очкан?.. — Ул Шәфи алдына цифрлы кәгазь китереп салды. Моны андагы штаб конторында кече писер булып эшләүче татар егете машинкада сугып биргән иде. Шәфи андагы айлыклап күрсәтелгән саннарга кат-кат күз йөртеп чыкты һәм үзен әрләргә тотынды: нишләде соң әле ул? Кая китте бөтен дөньяга җитешә торган коммерсант Габдрахман? Әллә бу сәяси хадим булып кылану, президент куыгы белән кабару кешенең күзен, аңын томалый микән? Туксан биш мең кеше! Шул хәтле күп кырылуларын ул белми дә калган. Аларны исән-сау вермахтка тапшырганда, юк дигәндә ярты миллион марка үз кесәсендә калган булыр иде бит!

— Немецлар миннән яшергән моны, — диде Шәфи, үкенүле тавыш белән. — Белсәм, юл куймас идем!.. Ничек төзәтеп була соң? Тәкъдимегез ничек?..

— Тәкъдимемне мин сезгә теге вакытта ук әйткән идем, президент әфәнде, — дип сүзгә кереште Муса. Менә хәзер конкрет мәгълүматлар үз кулыгызда инде. Сөйләшегез, зинһар: туену нормасын арттырсыннар! Бүген үк легионга керми дип, әсирне ачка үтерүдән ни файда? Кешене тиз генә боруы кыен. Бүген кермәсә, иртәгә керә ул. Менә бит, мисалы күз алдыгызда: безне дә Вустрау лагеренда шулай ачтан интектергән идегез, ә хәзер ничек? Күрегез: кичәге киреләр бүген сезнең итагатьле хадимнәрегез! Седельце белән Демблиндаге әсирләр дә озакламый сезнең солдат булачаклар: тик аларны юньлерәк туйдырырга һәм медицина ярдәме күрсәтергә кирәк. Легионга тизрәк керү өчен, ачлык белән түгел, башка чаралар белән бераз кыса төшәргә дә ярый. Менә без дә ярдәм итәрбез, фюрер командованиесенең дә андый чаралары табылыр...

— Башка юл юк, Гаптрахман абзый, — диде Гариф. — Мин дә нәкъ Муса Гумеров тәкъдиме төсле үк фикерләр белән кайткан идем. Инде калган табышны гына булса да югалтмаска кирәк. Мин финанс эшчесе, чут сала беләм: саклап калсак, озакламый өстәмә батальоннар оештырып, комитет кесәсенә шактый гына сумма кертәчәкбез! — Аның имән бармагы тагын югары күтәрелде.

— Хәерле булсын, — диде Шәфи, — тырышып карарбыз. Бүген үк Унгляубе белән сөйләшим. Аны күндерсәм, бергәләп Розенберг әфәндегә керербез. Эшлибез аны! — Ул дәртләнеп өстәл сугып куйды. — Тау тишү түгел.

— Ә фотокор мәсьәләсе? — дип, Алиш яңадан үз тәкъдимен кабатлады.

— Фотомөхбир дисәңче, ичмаса. Гел урысча сукалау ягын карыйсыз! Ярар, анысы да кирәк. Аппаратлар алырбыз. Кемне куябыз соң?

— Бездә ул эш белән Рәфикъ Гыйльфанов яхшы таныш бугай. Ул Казанда чакта ук бик яхшы төшерә иде.

— Ярар, — диде Шәфи, — сөйләшермен үзе белән. — Ул, сәгатенә карап, урыныннан кузгала башлады. — Эшегезне хуплыйм. Рәхмәт. Милләт өчен шулай хезмәт итәргә кирәк. Тик йөрмәгәнсез, — диде ул, өзек-өзек җөмләләр белән. — Хушыгыз.

— Үзегезгә рәхмәт, президент әфәнде! — диде Фоат, үкчәләрен солдатларча куш бәреп. — Милләтебез өчен сез, президент әфәнде...

— Әй, әй! — дип башын селкеде Шәфи. — Катык! Тумаган тай, алтын ияр — билен сындыра башладың, әнкәш! Хуш, хуш!..

## V

Муса икенче тапкыр Польшага баруында фәкать беренче батальонда гына булып, Актабанов белән киңәште. Андагы хәлләр белән танышкач, үзенең рәсми хезмәте арасына кертеп, оешма эшләрен җәйде, подполковник билгеләгән кешеләрне барлап өйрәнеп йөрде. Батальонның озакламый фронтка җибәреләчәге солдат телённән төшми башлаган иде инде. Шулай да Муса монда озак тора алмады, озак торуның кирәге дә юк иде. Һаман немец күз алдында тулганып, шик тудыру гына мөмкин. Шуңар күрә ул, батальон юлга чыкканчы янадан килмәкче булып, Берлинга кайтып китте. Теге вакытта Шилов белән танышканнан соң, әлеге «бабай» тиз генә килмәгәнлектән, икенче рәт күрешә алмадылар, шунда ашыгырга кирәк иде. Гомумән, яз житү белән эш күбәеп китте, барысына да чабарга, өлгерергә кирәк. Борын төбендә җәй тора һәм шул җәйдә һәммәсе дә хәл кылынырга тиеш.

Берлинга кайту белән Шиловны күрергә ашыкты ул. Бу эштә аларга Алиш белән Фая булышты. Андрей аны караңгы кичтә трамвай тукталышында каршыларга тиеш иде. Фая Мусаны соңгы тукталышкача алып килде дә, хушлашып, үз юлына югалды. Болай очрашу хәвефсезрәк булыр сыман тоелды, чөнки трамвайга утырырга килә бит кеше. Шулай булгач, берәүнең дә шикләнүе мөмкин түгел.

Шилов озак көттермәде. Берлин күптән караңгылыкка чумган иде инде. Транспорт тукталышы шикелле кайбер мөһим урыннарда гына киң металл калпаклар астында янган сыек зәңгәр утлардан бик әз генә яктылык төшә һәм кешенең йөзен мәетнеке төсле җансыз, суык итеп күрсәтә иде. Шулай да Муса бик тиз танып алды. Шилов та туры аның янына юнәлеп, күптәнге танышларча гади генә сәлам бирде. Тукталышта биш-алты кеше җыелган һәм аларның немецмы, башка милләтме икәнен караңгыда ачык белү мөмкин түгел иде. Шыңкырап трамвай килде. Һәркем кабаланып эчкә керергә ашыкты. Кешеләр шул кабаланган арада Шилов Мусаны читкә алып китте.

— Хәтта тукталыштан кире борылганны да сизмәүләре яхшы,— диде Шилов пышылдап. — Сезгә күрсәтәсе кунак берничә көн монда инде...

Алар язгы кара җир белән тыгыз тоташкан һәм күзгә сыланырдай куе карангылык эченә кереп югалдылар. Әйләнә-борыла торгач, әллә ничә урамны узып, тар гына кирпеч тыкрыклар аша, әллә ниткән шомлы иске ярым җимерек биналар яныннан уздылар. Бу тирәләрдә йөрүчеләр дә бөтенләй юк иде шикелле. Аннары килеп гел шәрә стеналар, алардагы ыржайган тәрәзә тишекләре, өскә авардай булып кыйшаеп торган ватык колонналар, завод торбасыдай биек күренгән котельни морҗалары арасына барып керделәр. Хәзер инде аяк асты тулы кирпеч ватыклары өстеннән атлыйсы һәм нинди дә булса сукмак билгесен эзләп тә маташасы юк иде. Муса иптәше артыннан ук атлый бирде. Бу хәрабәләр арасы аеруча авыр үле тынлык һәм шомлы сер белән тулган кебек тоела иде аңа. Кинәт каршыда ниндидер зур гына карачкы барлыгы һәм аның кәкре-бөкре аерым тармаклары, җил белән шыкырдый-шыкырдый, куркыныч тирбәлеп торганы күренде. Муса моның нәрсә икәнен абайларга өлгермәде, ике-өч адым гына алдан барган Андрей югалып та куйды. Кая китте соң әле ул? Муса, күзләре белән карангыны капшап, аны эзли башлады. Шунда ук пышылдау ишетелде:

— Калма. Калайлар астына кер!..

Ә-ә, бу карачкы — түбә калайлары икән! Утта янып шулай бөгәрләнеп, калҗаеп беткәннәр, күрәсең. Кайсыдыр шәп кыйраткан монда! Бөтен бер квартал бит. Бәлки, әле безнең лачыннар булгандыр алар!

Муса өем астына керде, анда да һичбер сукмак эзе күренми иде. Киемнәрен әле бер калай тырнагына, әле икенчесенә эләктереп алга үрмәли торгач, чокыр пәйда булды. Шиловның күләгәсе шунда күмелде. Муса да аска төшә башлады һәм кирпеч ватыклары арасыннан түбән сузыла торган таш баскыч барлыгы беленде. Шилов тагын шактый вакыт карманып аска төшә-төшә уңга борылды, тагын бераз барды һәм дүрт тапкыр ниндидер юка тимергә чиртте, ул шыңгырабрак тавыш бирде. Эчтән тамак кырган тавыш ишетелде. Шуннан соң гына бу карaңгы базда сүрән генә ут сызыгы күренде. Күрәсең, Шилов аз гына ишекне ачты булса кирәк, шул ярыктан төшкән ут тасмасы Мусаның калган юлын чак кына яктыртып җибәрде. Муса иптәше артыннан бер адым да калмаска тырышты, караңгыда кабалана торгач, кулларын сыдырып, тезләрен орып, тубыкларын суеп бетерде. Шулай да бу мавыктыргыч иде. Малай чакта йотылып укыган маҗаралы китаплары, Урал суының Оренбургтагы текә ярларыннан тау тишеге эзләп йөргәннәре исенә төште. Ул чакларда табылмаган серле мәгарәләрнең берсендә менә хәзер йөри кебек тоелды аңа. Алда ниләр буласын ул әле белми иде. Ниһаять, Шилов сак кына ишекне ачты да, Муса аның янына килеп җитү белән, бөкрәеп эчкә керделәр. Рәшәткә баганасы рәвешлерәк дүрткел кирпеч укмашкасы өстенә куелган калай савытта артык төтәмичә генә ак парафин яна иде. Аның дерелдәвек сүрән яктысы, әллә нинди серләр яшергән сыман, бу куышның бөтен почмакларына төшеп тә өлгерми. Түрдәрәк ятак сыман тигез бер урынга иске көрән одеал җәелгән, бер башында урталай бөкләп салынган кыска тун ята. Уң якка камуфляжлы немец палаткасы корылган.

Алар монда кергәч күз ияләнер вакыт узуга палатка артыннан бер карт килеп чыкты. Муса тиз генә аңа борылып карады. Бу кешенең иң элек күзгә ташланган нәрсәсе: юл-юл ак су йөгергәндәй дулкынсырланып торган кара-коңгырт көрәк сакалы, калын чал чәчләре, шулай ук калын һәм чуалчык кашлары белән алар астыннан караган кечерәк җете күзләре иде. Шушы берничә чалымы белән ничектер Толстойны хәтерләтә иде ул.

Йөзе ябык һәм карт сыман тоелса да, гәүдәсе ыктымат һәм җиңел хәрәкәтле күренде. Шилов җәһәт кенә аңа таба атлады да:

— Залилов Муса, таныш булыгыз, иптәш полковник, — диде.

— Очень приятно, — дип кул сузды карт, җитди генә итеп. — Петр Бакшанов. Мин инде сезнең белән күптән таныш. Теге вакытта ук миңа бу егет һәммәсен дә әйткән иде. Яхшы, утырыгыз. Сөйләшик. — Бу сүзләрне әйткән арада Муса аның авызында фәкать ике алгы теше генә барлыгын күреп алды. Бу хәл аны, чынлап та, алтмыш-алтмыш биш яшьләрдәге карт итеп күрсәтә иде.

— Мин тартып керер идем, рөхсәт булса, — диде Андрей. — Күзәткәләрмен дә шунда...

Полковник аңа кулы белән генә ишарәләп рөхсәт бирде. Муса кирпечләр өстенә утырды, Бакшанов аның каршына, әлеге тапчан сымак нәрсәгә урнашты.

— Сезнең теге вакытта Шилов аркылы әйткән үтенечне яртылаш үтәдек дияргә була, — дип сүз башлады Бакшанов, әкрен тавыш белән. — Мәскәүгә кеше җибәрдек. Бу мәсьәлә, әлбәттә, безнең өчен дә бик мөһим. Чөнки үзебезнең дә элемтә юк. Ләкин юллар бик әйләнгеч...

— Аның барып җитүенә ышаныч бармы соң? — дип сорады Муса.

— Ышаныч бар барын. Әмма мондый катлаулы сугыш барганда һич көтелмәгән мең төрле очраклылык килеп чыгуы мөмкин бит, —

диде карт. Аннары ул Муса оешмасының хәзерге эшләре белән кызыксынды.

Муса кыска гына итеп үз хәлләрен сөйләп бирде. Үзебезнең як белән элемтә булмау эшне бик нык тоткарлавын әйтте.

— Ичмаса, җитди һәм зуррак бер хәрби оешма белән берләшсәк тә, яхшырак булыр иде төсле күренә. Эшләү дә уңайлырак булыр иде,— дип тәгәлләде ул сүзен.

Полковник Бакшанов беравык Мусага карап торды. Аның чуалчык кашлары астыннан нәни прожектордай туры юнәлгән очлы күзләре, Мусаның эченәрәк үтеп керергә теләгән кебек, сынаучан карыйлар иде: сәеррәк фикер йөртә бу шагыйрь. Тәҗрибәсе җитеп бетми, ахры. Каян аласың андый зуррак оешманы? Каян аласың җитәкче үзәкне? Берлин бу, дошман тылы...

— Действуйте самостоятельно! — диде ул өзеп кенә.— Әзербәйҗан һәм әрмәннәргә дә шуны әйттек. Легионнар алдында ике бурыч: туган илгә атмау һәм оешкан төстә үзебезнең якка чыгу. Оешма эзләмәгез. Вак оешмалар да бик тирән яшеренгән... Мондый шартларда зур оешма белән эшләү мөмкин дә түгел. Аннары инде һәр оешманың үз бурычы бар һәм үзе өчен бик мөһим.

— Ансы шулай...

— Шулай булганга әйтәм дә. Сезнең бурыч кечкенәме? Әгәр шул батальоннарның берсен генә булса да, немец ягыннан сугыштырмыйча, үзебезгә чыгарып җибәрә аласыз икән — сезнең исемегез дә, Денис Давыдовныкы шикелле, онытылмас булачак, шагыйрь!

— О, сез бигрәк инде! — дип көлемсерәде Муса. — Анысы турында уйларга вакыт юк, иптәш полковник...

— Ул да дөрес, — диде карт. — Дан турында баш ватканчы, алга килеп баскан проблеманы чишәргә туры килә. Менә мондагы лабораторный цехта «Фау» дигән яңа корал ясый башлаячаклар. Ул ракета-снарядлар 89 километр югарыга күтәрелеп, 250—290 километр ераклыкка очачак, имеш. Җимерү көче искиткеч зур. Безгә шул гына билгеле. Әмма шунысы да җитәрлек. Моңарчы әле мондый коралның булганы юк...

Муса, гаҗәпкә калып, уйланып утырды. Чынлап та, мондый нәрсәнең ишетелгәне юк ич. Димәкки, 250 чакрымнан ата торган авыр артиллерия! Аның позициясе кайда икәнен ничек белеп, ничек бастырырга кирәк? Димәкки, немецлар өйләреннән торып, бу ракета белән Англия шәһәрләрен, кирәк булса Варшава, Париж, Брюссельне бомбалап ятачаклар. Безнең калалар өстенә дә барып җитүләре мөмкин... Әйе, сугыш нәрсә генә тудырмый! Менә кайда Исрафилевне кертәсе иде! Эзләп карарга микән әллә үзен?..

Бакшанов дәвам итте:

— Безнең «меценат»ның бу уенчыклары өстенә көл сибәсе иде! Кыен мәсьәлә шунда хәзер. Ярый ла, һава кошлары вакытында килеп җитеп, бу эшне башкарып китсәләр. Ә килеп җитмәсәләр?.. Менә шуның өчен бу кыен операцияне башкаруга без иң ышанычлы, иң куркусыз биш кешене билгеләп торабыз. Исемнәрен дә әйтим: Тинакова Фая, Арбузов Виталий, Васильев Иван, Билялетдинова Аля, Самигуллина Сания. Барысы да комсомолецлар һәм алтын җанлы яшь лачыннар. Эш бик җитди һәм бик куркыныч. Миңа аларны анда җибәрү гадәттән тыш авыр, йөрәк итемне кисеп биргән шикелле!.. Сез ничек карыйсыз? Анда сезнең милләттән дә ике кыз бар...

Муса инде, Әлбидә белән Сания һәм Фая исемнәрен ишеткәч тә, тәннәрен энә белән чәнчегәндәй утыра иде.. «Ничек карыйсыз?..» имеш. Кяшки моңа ансат кына җавап биреп булсачы! Моңа кадәр ул бик күп егетләрне көрәш сафына туплады. Ләкин әле берәүне дә үлемгә җибәргәне юк аның. Моны ничек эшләргә соң? Җитмәсә, яшь кенә кызлар

бит. Кызларны ничек үлемгә җибәрәсең? Мескеннәр, болай да икеләтә-өчләтә авыр ич аларга... Эх, Мусаның үзенә генә мөмкин булса иде! Бу күгәрченнәрне яшәү һәм сөю бәхетеннән мәхрүм иткәнче, бик рәхәтләнеп үзе барыр иде дә, ул куркыныч һәм кирәкле эшне үзе генә башкарыр иде!..

Муса, күзләрен түбән төбәп, шулай озак утырганнан соң, башын калкытты да Бакшановка карады:

— «...Сезнең милләттән дә...» — дисез... Бергә яшәүче халыклар каршына яшәү яки үлем мәсьәләсе килеп басканда, әйтерсең лә, «милли ризалык» сорап торып була?.. — диде Муса, кыза төшкәндәйрәк итеп. — Эш андамы соң? Эш аларның яшь кенә кызлар булуында һәм йөрәкләре тулы гыйшык җыры, үзләре дә тыя алмаган язгы мәхәббәт өермәсе булуында! Шундый чакларында шундый яшь күгәрченнәрне ничек без үлемгә юллыйк? Бәлки, ул эшне ир-егетләргә тапшыру кирәктер?..

— Мин дә уйлаштырдым бу хакта... — диде полковник, шулай ук түбән карап. — Бик кыен... Бик кызганыч миңа ул балалар. Барысы да умырзая чәчәкләре шикелле! Һич кенә дә җибәрмәс идем, ләкин... гади хакыйкать: көрәш корбансыз булмый. Ә бу лабораториягә идән себерүче сыйфатында бары тик кыз балаларны гына кертү мөмкин.

— Ә шулай да бу кызлар үзләре теләп барсалар гына җибәрергә кирәк. По доброй воле и по своей инициативе, — дип өстәде Муса.

— Әлбәттә, шулай,— диде карт, Муса белән килешеп. — Без әле, гомумән, бик ашыкмаска да уйлыйбыз. «Фау» әле лабораториядә. Тәмам сыналып бетеп, цехларга куелмаган. Ә аңа хәтле авиация дә йокламас әле, бәлки, ә? Ике якның берсеннән килеп җитәргә тиеш. Тик менә алар озак килми торсалар гына инде... Ләкин ул очракта да без иң элек егетләрне урнаштырырга тырышачакбыз анда. Тик ул план барып чыкмаса гына, башка чара калмый... Ә кызлар өчесе дә үзләре сорап ул эшкә баралар...

Муса Исрафилев турында яңадан уйлап алды. Һәм шул уен сүз белән әйтә куйды:

— Без сезгә бер егет тәкъдим итсәк, ничек карыйсыз? Төгәл приборлар инженеры. Бу эшкә бик кулай булыр иде... Тик бу әле өзеп әйтү түгел, үзе белән сөйләшергә кирәк...

— Бик шәп! — диде карт. — Давайте! Бәлки, ул корбансыз башкару юлын табар.

— Гомумән безгә тыгыз бәйләнештә булу яхшы, — диде Муса. — Киңәшләшеп эшләү һәрвакыт файдалы. Ә Үзәк белән элемтәгә керүдә сезнең булышлык бигрәк тә кирәк безгә. Сезнең аңа мөмкинлек зуррак бит!

— Аңлыйм һәм хуплыйм! — дип елмайды Бакшанов, Мусага кул сузып. — Союз!

Шуның белән аларның сүзе тәмамланды. Карт, моны аңлатырга теләгәндәй, әлеге көрәк сакалын җилфердәтеп, җиңел хәрәкәтләр белән урыныннан кузгалды. Шул ук вакытта Шилов та ишектә күренде. Кыш суыгы әле һаман сакланган тирән подвалда күшегеп беткән иде ул. Почмактагы чуен мич өстенә тизрәк кулларын сузып, «әх-әх!» дия-дия, җылынып алды. Бакшанов Муса белән хушлашты да чуар палатка артына кереп югалды. Шилов белән Муса әлеге сихри юллардан үрмәләп, кире әйләнеп чыга башладылар. Ниһаять, калайлар чормагыннан котылып, җир өстенә баскач, Муса иркен сулап куйды. Шилов әлеге «җир асты алласы» турында сөйләп китте. Күпне күргән кеше икән. Кайсыдыр укчы дивизиянең артиллерия начальнигы булган. Камалышта озак вакытлар сугышып, актык патроннары да калмагач, урманнарда качып йөргәннәр. Ниһаять, тиф аяктан еккан һәм пленга эләктергән. Лагерьдан качу — аның өчен бакча киртәсеннән сикерү кебек

кенә тоелган. Шуңар күрә авызында алгы ике теше генә калган. Һаман тотыла торгач, Майданекка килеп эләккән. Полковникны аннан поляклар үзләре белән качырып алып чыкканнар һәм кулына ниндидер поляк картының чын документын биргәннәр. Шуннан бирле инде тотылмыйча, Одердагы Франкфуртта эшли икән. Польшадан эш эзләп килгән атлы крестьян, имеш. Рәсми фамилиясе Штефан Тадешка...

— Аның Берлин хәтле Берлинга нинди юллардан килеп йөрүен үзеннән башка һичкем белми, — диде Шилов, серле пышылдау белән. — Оешманы да ул алып бара һәм, әйтергә кирәк, белеп йөртә эшне. Хәзергә бер провал да булганы юк... — Алар бераз тын бардылар. Төн шактый җылы иде. Урамга кергәч, Шилов тагын өстәп куйды: — Бу куышны да үзе эзләп тапкан. Әз-мәз рәтләдек тә, шунда гына очрашабыз... Картның бер йомшак ягы бар: Толстойны бик ярата. Каяндыр табып алган «Война и мир»ны кирпечләр астында саклый...

Тукталышка трамвай килеп җитте. Мусага, тиз-тиз генә Шилов белән саубуллашып, трамвайга йөгерергә туры килде.

— До скорого!.. — дип кычкырды ул. — Берегите детей!..

Трамвай сыкрый-шыңкырый китеп барды.

## VI

Муса батальоннарга җибәрү һәм үзе белән алып китү өчен берничә төр яңа «кызлар хаты» хәзерләде. Әхмәт Симаев аларны үз егетләре белән тиз арада синтетик матрицага төшереп бирде. Төннәрен хәзер еш кына һава һөҗүмнәре булганлыктан, редакциядәге язу машиналары һәм башка шундый әсбаплар төнгелеккә Ферлагның тирән подвалына төшерелә иде. Фоат Булатовның да «аяк машинасы» шунда куелган хәзер. Алишның газета чыгарган кизү төне һәм Фоатның нәүбәттәге журнал битләрен тизрәк басып бетерү өчен «төнгә калып эшләве» бергә туры китерелде. Шул ике эш арасына өченче бер эш кереп китте. Булатов матрицаны валикка беркетеп, буяулап алды да аяк машинасын әйләндерә башлады. Алиш кәгазьләр салып һәм басылган хатларны уртага бөкләп, чүп кәрзиненә тутыра торды. Гариф Шабаев подвал баскычында сакта иде. Алай-болай Гарифтан сигнал ишетелә калса, Фоат шунда ук матрицаны кубарып кәрзингә ташларга, ә инде Алиш шуларның барысын бергә стена почмагындагы зур гына һава юллыгына олактырырга тиеш...

Немецлар «бомбадан качкыч» ясаган бина подвалларында көчле һава агымы йөри торган вентиляция челтәре үткәргәннәр иде. Моннан файдалану мөмкинлеген иң элек Алиш уйлап тапты. Шушы базда газета чыгарган төннәрдә аның радикулетлы биленә һаман суык өреп йөдәтә иде. Эзләргә тотынды. Моторлары әллә кайда гүләгән юан һава торбасыннан ыжгырып җил бәрә икән. Икенче почмактагы шундый ук торба янына барды. Әле монысы да өсти икән тагы! Абдулла анда да кулын сузып карады. Юк, монысы өрми, кулыңны суырып алырдай көчле итеп, эчкә тарта. Вәт әкәмәт! Ә-ә, берсе тыштан һава куа, икенчесе эшләнгән һаваны суырып ала. Хәйләле! Шуннан соң Алиш бу упкынга бер кәгазь йомарлап атты. Аны шунда ук һава очырып алып китте.

— Әйбәт икән бу! — дип куйды Алиш, үз алдына көлемсерәп. Анннары ул үзенең бу «ачышын» Фоат белән Гарифка күрсәтте. Фоат егермеләп кисәк буш кәгазьне берьюлы атып карады, көчле агым аларны да тәгәрәтеп алып китте.

Егетләрнең авыз ерылды.

— Була бу, — диде Фоат. — Вентиляция юлыннан кереп алып чыга алмаслар, шито-крыто!

Бүген дә алар башта һава юллыгы янында репетиция ясап карадылар. Суыру яхшы иде, тик шуннан соң гына басарга тотындылар. Ул-

бу булмады. Илле минут эчендә бөтен эшләре тәмамланып та өлгерде. Буялган кәгазь чүп-чарларын яндырып, көлен һава юллыгына очырдылар.

Шабайның кайчандыр өйрәнгән тегүчелек эшенә осталыгы бар иде. Ул үзенең куртка эчлеген арка ягыннан кубарып, ике калак сөяге турына яшерен кесәләр ясады. Бу кесәләрнең асты һәм өсте мамык белән капланганлыктан, анда «кызлар хаты» йөртү бик уңайлы, күпме капшап карасаң да кәгазь шыштырдавы ишетелми иде. Шундый ук кесәне Фоат белән Алишка да ясап бирде ул. Фоат белән Алиш хатларның бер өлешен шул кесәләренә урнаштырдылар да баскычтагы Гарифка хәбәр бирделәр: «эш бетте», янәсе. Гариф, алар янына төшеп, үз өлешен аркасына тыкты да курткасын каеш белән бәйләп, чыгып та китте.

— Сау булыгыз, егетләр.

Алиш белән Фоат, кыйнап кушкандай мәҗбүрилек белән, үзләренең «кәҗүнни» эшләренә керештеләр...

Шулай итеп, «кызлар хаты» да әзер булды. Хәзер инде батальоннарга китү өчен мөһим сәбәп кирәк. Чөнки Муса ул яклардан күптән түгел генә кайтты, аңардан элек Алишлар да шунда йөреп килделәр. Болай еш йөрүдән Шәфи ни дә булса сизенмәгәе...

Муса көн буе баш ватып йөрде. Уйлап чыгарган сәбәпләре бар да ясалма кебек тоелды. Кичке уңайда комитеттагы бүлмәсендә иягенә таянып утырды. Икенче кулы белән өстәлдәге кәгазь кисәгенә эт башлары, фил борыннары, кәҗә мөгезләре ясады. Боларның нәрсәгә кирәге бардыр, ул үзе дә белми иде. Шул чакта бүлмәгә ике егет килеп керде. Берсе, җәһәт кенә килеп, «Исәнме, Муса абый!» дип күреште. Муса аны танып алды. Кайчандыр Каунас лагеренда бергә бәрәңге чүпләп яткан һәм соңыннан Вустрауда очрашкан Гани Сәләхов иде ул. Димәкки, бу егетләр Познань шәһәреннән килгәннәр. Чөнки Сәләхов теге төркем белән шунда киткән иде бит. Өсләрендәге ярым хәрби, ярым полицай киеме дә шуны күрсәтә. Икенчесе кем икән, Муса аны хәтерләми.

— Нихәл, Гани дус! — дип, кул бирде беренчесенә Муса.— Познаньнән килдегезме? Ниләр бар анда сезнең?

— Бер көйгә генә... — диде Гани, салмак тавыш белән. — Безне анда бөтенләй оныттылар. Һичкем күренми... Хәтта гәзитләр дә җибәрмиләр. Менә шуңа дип килгән идек әле...

Муса ишек төбендә калган икенче солдатка карады. Ул егет, гел карадан буялган шикелле, куе кара кашлы, кара күзле, сөйкемле генә карасу йөзле, тыгыз гәүдәле, урта буйлы иде. Авыз почмагында ниндидер хәйләкәрлек чалымы барлыгы да сизелә үзенең.

— Карагыз әле, дус егет, нигә анда оялып калдыгыз, кунак кызы шикелле? — дип көлде Муса. — Килегез бире, утырыгыз! — Шуннан соң Муса тиз генә Сәләховка карап алды: «Кем бу?» янәсе.

— Кил, Кәлим, болай таба, таныш, — диде Гани, Мусаның сораулы карашына җавап бирергә теләп. — Юк, кунак кызы түгел ул, бик кыю, бик хәйләкәр егет. Искәндәр агайны да төп башына утырткалый. Поляклар белән дә тел таба...

— Шулаймыни-и? — дип, ул егеткә елмайды Муса. — Яхшы алайса, сөйләгез, тыңлыйм.

— Мулланур Гәрәевнең сезгә кичкенә генә хаты бар иде, без аны тапшырырга дип кенә сугылдык, — диде Гани, кесәсеннән бәләкәй конверт кисәге чыгарып. — Сөйләр сүзебез әллә ни күп түгел...

Муса шунда ук хатны ачып укыды.

«Хөрмәтле Муса абый! — дип башланган иде ул хат. — Без әкрен генә үз йомышларыбызны укмаштырып яткан булабыз. Әмма эшләрнең берничә төркемгә бүленеп, узаеры бару хәлләре дә бар. Моңарчы сез-

нең тарафтан бер хәбәр дә булмады. Кыңәшкә мохтаҗлык зур, мәдәни агарту эшләрен юлга саласы иде. Үзегез килеп чыга алмассыз микән?..»

Муса уйга калды. Әйе шул, Познаньдагылар онытылыбрак киткән, күп кеше булмагангадыр инде. Әмма анда да эш барырга тиеш һәм бөтенләй башка юнәлештә...

— «Идел-Урал» комитетыннан анда Һадиев җибәрелгән иде бит, ничек, булышмыймыни соң ул? — дип сорады Муса.

— Әй, аның ише! — дип кенә куйды егетләр һәм кул селтәделәр.

Муса аның хакында артыгын сораштырмады. Шул кул селтәү дә кирәген аңлата иде. Ул, үз кулындагы хатны әйләндергәләп, тагын байтак тын утырды. Аның башында бер фикер йөри, шуны эшләп караса, ничек булыр икән? Бу бер уен сымак кына уй, зарарсыз шаяру гына. Ә шулай да сынап караса?..

— Сез икегез дә бер сүздә була аласызмы? — дип сорады Муса егетләрдән.

— Без гел бер сүздә! — диде, моңарчы оялчан күренгән Кәлим. — Без — ахирәтләр.

Муса көлемсерәп куйды. Тагын бу егет әллә кайсы төше белән генә оялчан һәм шаян күңелле бер кызны хәтерләтте. Әллә хәйләле елмаючан юка иреннәре белән, әллә инде шул соңгы сүзләре белән...

— Ә кайсыгыз сезнең гарәпчә яза белә?

— Ансы безгә эләкмәде...

— Алай булгач латинча?

— Икебез дә, — диде Сәләхов.

— Алайса, яз, — диде Муса, өстәл астыннан бер бит кәгазь чыгарып. — Мин әйтеп торам:

«Мөхтәрәм Габдрахман Шәфи Алмаз әфәндегә.

Без, сезнең тарафтан Яушев әфәнде заводына полицай итеп җибәрелгән егетләр, ни сәбәбдиндер, шушы көннәргә кадәр үзебезнең «Идел-Урал» газетын укый алмыйбыз. Мәдәни агарту һәм милли тәрбия эшләре дә алып барылмый. Бу хәл күңелсез нәтиҗәләргә китерә. Һадиев әфәндинең үз эшләре күптер, ахры, безгә игътибар бирә алмый. Сезнең андагы комитетта мәдәни эшләр җитәкчесе Муса Гумеров әфәнде бар дип ишетәбез. Ул әфәндене безгә җибәреп, лекцияләр укытсагыз, тәрбия эшләрен юлга салдырсагыз, бик зур рәхмәт укыр идек.

Яушев заводындагы егетләр исеменнән унтерәфисәр:

Мулланур Гәрәев».

— Имзаңны чормавыклабрак куй, — диде Муса. — Формасы килә төшсен. Я, ничек? Шулай ярыймы?

— Ышанса, ярар.

— Ышаныр, — диде Муса. — Менә конверт. Эченә тыгып ябыштырыгыз. Тышына «Президент Габдрахман Шәфи Алмаз әфәндегә» дип язгыз. Булдымы? Ә хәзер хатны аның кабинетына кертеп бирегез. Үзе кабул итмәсә, секретарена калдырыгыз. Гариф Шабаев дигән кеше булыр шунда. Ә Мулланурга, үзегез кайткач та, әйтегез: Шәфи әфәндегә язган хатыңны исән-сау тапшырдык, диегез.

Егетләр көлешеп чыгып киттеләр.

— Хуш, Муса абый! Тиздән үзегезне көтәбез!

— Була ул! — дип калды Муса.

Иртәгесен беренче һәм өченче батальоннардан да газета алырга килделәр. Алар арасында Мусаның күптәнге дусы Арыслан белән Демблинда танышкан яшь егет Фәритов та бар иде. Алар Муса бүлмәсенә аерым-аерым җай табып керделәр. Чөнки алар үзләренең бер үк яшерен оешмада эшләгәннәрен белмиләр һәм бер-беренә белдермәскә тырышалар иде. Алдан килеп кергән Арыслан, бүлмәдә Мусаның үзе генә булуын күргәч, «Һәнди һох!» дип кычкырып җибәргән булды.

— Күрмисеңмени, бәләкәчем, фриц килә каршыңа, чистый фриц! — дип сөйләп китте ул аннары. Өстендәге яңа немец формасының төрле урыннарына шап-шоп суккалап куйды. — Тик менә әллә нишләп тәнне чәнчә, эченә арпа кылчыгы тутырылган шикелле, каһәре!

— Булыр, булыр, — диде Муса, аның белән кочаклашып. — Сагынып беттем үзеңне!.. Байның туны төлке, ярлы кисә — көлке, диләр түгелме соң?

— Көлгән әдәм көләдер, үз ямаулым — хөлләдер, дип тә әйтәләр бездә...

— Шәп! — диде Муса. — Я, үзегездә ни хәлләр бар?

— Хәбәрнең иң яңасы шул: безне озакламый фронтка озатачаклар. — Арыслан тавышын әкренәйтә төште. — Актабанов иптәш шуны әйтергә кушты. Өйрәнү сәгатьләрен кыскарттылар, юлга җыена башлыйбыз, диде. Үзе килеп китүе бик кирәк, диде.

Муса тураеп куйды, йөзендәге шаян елмаю урынына җитди төс чыкты.

— Шулай укмыни? — дип куйды ул. — Мин әле бу хакта бер ни дә ишетмәгән идем; күрәсең, мыштым гына озатырга телиләр. — Бармакларын өстәлдә биетеп алды. — Ашыгырга кирәк, алайса.

— Кирәк, бәләкәчем, без киткәнче ничек тә шунда бул инде син!..

Алар сөйләшеп бетермәгән иде, ишек шакыдылар.

— Мөмкин! — дип кычкырды Муса.

Ишектә яшь кенә, сөйкемле генә бер егет күренде. Аның иң элек кара янып торган күзләре һәм авыз почмагына ниндидер сынма сызыклар чыгарып нык кысылган иреннәре күзгә ташлана иде. Шул ике билгесе аның бөтен карасу йөзенә аеруча җитдилек биреп тора. Теге чакта Демблин крепостенда Гайнан Кормаш таныштырган иде аларны. Сәмәркандта вуз бетергән, математик диде бугай. Һәм охшаган. Математикларны шулай җитди була диләр иң. Сугыш башланганда Шепетовка тирәсендәге дотта булган. Бүленеп калгач та сугышканнар. Бөтен бит-күзләрен ут ялмап китеп, сукыр кала язган. Ай ярым лазаретта ятканнан соң гына дөнья яктысын күрә башлаган. Терелгәч, качмакчы булган өчен эткә талатканнар. Ул үзе бер дә теләмәсә дә, моны Мусага Габдулла Баттал күрсәтте... «Мна ведь, ти, Фәритовның ертык чалбарыннан шул урынны күрсәтеп. — Бер пешерерлек сум итен алып киткән алла суккан овчарка. Әл дә чокыр булып тора...»

Башкалар көлгән булса да, Фәритов ул чагында да көлмәде. Ул үзенең әсирлек бәхетсезлеген һәм мыскыл итүләрне бик авыр кичерә, эчтән көйрәп йөри иде. Мусаның легионга күчәргә димләве өчен ачулы һәм нәфрәтле күзләре белән ашардай булып карады ул аңа. Муса киткәндә дә ул әле соңгы сүзен әйтеп бетермәгән иде. Ә хәзер менә Берлинга килгән. Күрәсең, Кормаш аңлаткан һәм, ниһаять, күндергән үз дусын...

— Әйдүк, Солтанай, — диде Муса аңа елмаеп. — Болай уз, утыр, сөйләп җибәр.

Егет, кыюсыз адымнар белән генә өстәл янына килеп, Алыпкуловка каршы утырды һәм авыз ачканчы аңа карады.

— Сез таныш түгелдер әле, — диде Муса. — Бу абзыең беренче батальоннан килгән. Шул сезнеке төсле йомышлар белән. Ә үзе — минем җан дусым. Волхов сазлыгында мине үлем авызыннан тартып алган. Ул минем бишенче туганым, ә мин аның сигезенче браты.

Фәритов бу сүзләрнең мәгънәсен бөтенләй үк аңлап бетермәсә дә, Мусаның фронт дусы икәнен белгәч, ачылыбрак китте. Арысланга кул биреп, үзенең фамилиясен әйтте.

— Я, Солтанай, сездә ниләр бар? — дип сорады Муса.

— Без дә шул инде, Демблиннан чыгып, Едлинога килдек. — Фәритов тагын җитди төскә керде. — Шул үзегез әйткән кешеләр...

— Ярый, — диде Муса, — дөрес иткәнсез. Тагын?

— Тагын шул: Гайнан пьеса язды. Артистлар труппасы аны сәхнәгә куярга җыена. Рушатовны культвзвод командиры итеп куйдылар, Гайнан — режиссер. Алар икесе дә сезгә сәлам әйттеләр, үзегезне көтәләр. Пьесаны алдан карап чыгасы һәм цензурадан уздырасы бар, диләр.

— Ала-ай, — дип куйды Муса, тагын бармакларын өстәлдә биетеп. — Што-то бик кирәкле кишер яфрагы булып китте әле бу Муса дигәннәре. Тегеннән дә сорыйлар, моннан да. Барысы да телдән генә. Ә ни өчен минем түрәләргә язмыйлар?

Егетләр, әлбәттә, җавап бирә алмадылар. Алар бит кечкенә кешеләр, белмиләр шул.

— Алайса, болай итеп карыйк инде, — диде Муса һәм өстәл астыннан кәгазь чыгарды. — Кайсыгыз гарәпчә яхшы яза белә?

— Мин аны шытырдатып язам язуын да, — дип җавап бирде Арыслан, — ну, минем грамыт ягы фәләнчәрәк, бик үк дөрес язмавым бар...

— Ә нәрсәгә соң ул? — дип сорады Фәритов. — Сәмәрканд вузында чакта мин дә өйрәнгән идем аны, Олугбек кулъязмаларын укырга кирәк булгач...

— Әһә, алайса син язып кара. Имля әйтүче хәлфәң мин булырмын, — диде Муса. — Тик икеле ала күрмә... Хуш, мелля кем, әзерләндеңме? Яза башла:

«Мөхтәрәм Габдрахман әфәнде.

Сезгә чук сәламләребезне күндерүдин соңра мәгълүм идәмез: Безнең өченче батальондагы артистлар труппасы беренче мәртәбә үз милли телемездә театр куярга хәзерләнә. Сәхнә әсәрен яшь әдип улачак егет Гайнан Кормашев язды. Әммә аны хөрмәтле немес әфәнделәргә аңлатып, синзурадан үткәрү мәсьәләләре җәһәдендин Сезгә үтенеч вә ихтыяҗымыз гаять зур. Рәхим итеп үзеңез килә алсагыз, бик хуп улыр иде.

Ихтирам илә: музыкаль капелла җитәкчесе Хисмәт Рушатов».

— Яздыңмы? — дип сорады Муса, егетләрнең икесенә дә күз кысып. — Менә конверт, печатьлә дә өстенә яз: «Президент Г. Шәфи Алмаз әфәндегә». Булдымы? Ә хәзер инде, шушы җитдилегеңне җуймыйча, үз кабинетына кертеп бир, Фәритов. Кабул итмәсә — секретарена калдыр, анда Гариф Шабаев булыр, шуңа бир.

— Кызык була икән бу, — диде Арыслан. — Белмәс микән карт төлке?

— Төлке, карт булса да, мондый эшләрдә әллә ни зирәклеге сизелми, — дип көлде Муса. — Менә инде тавык ите, каз боты мәсьәләләрендә — һич утырта алмассың!

Егетләр урыннарыннан кузгалдылар, үзләренең бүген үк кайтып китәчәкләрен әйтеп, хушлаша башладылар.

— Дөрес, — диде Муса. — Бигрәк тә сиңа, Фәритов, ашыгырга кирәк. Чөнки Рушатов үзенең хаты Шәфигә тапшырылганын тизрәк белеп торсын. Кайту белән үк сөйләп бир... Ярый, хушыгыз, хәерле юл сезгә. Алишны күрдегезме соң? Тиешле амәнәтләрне алдыгызмы? Яхшы, сак йөрегез. Дошманның күз каравыннан үк ниятен белергә өйрәнегез.

— Үзегез тиз әйләнерсезме соң? — дип сорады Арыслан, ишектән чыкканда.

— Бик тиз, — диде Муса. — Менә шул хатларның ашыгыч нәтиҗәсе булыр дип уйлыйм. Озакламый очрашырбыз.

Егетләр чыгып киткәч, Муса үзалдына көлеп утырды. Ул бүген ни өчендер шундый уйнак кәефле иде. Яз галәмәтеме, мондагы туң тормыштан алҗуымы — аны шулай ярсыта һәм, шук бала шикелле, тыел-

ган нәрсәләр белән шаярырга, ниндидер берәр әйберне ватып ташларга күңелен кымырҗыта иде...

Кичкырын, эш бетәр алдыннан, Шәфи аны үз кабинетына чакыртты. Муса килеп кергәндә, ул үзенең алтын көянтәле пенснэсен тәрәзә яктысында елтыратып, ияк очында гына калдырылган «керпе»сен сыпыргалап утыра иде. Ниндидер уй-фикерләр белән мәшгуль иде, күрәсең.

— Әйдүк, — диде ул, Мусага карап. — Менә монда сезгә кагылышлы хатлар бар. Шул эшләрне үтәп кайту кирәк. Мин үзем тиз генә чыга алмыйм, мөһим эшләр күп. Маһия апагызның да кәефе юк: кипкән тигәнәк шикелле гел күзгә кергән чагы...

Муса чак кына көлеп җибәрмәде. Аңа шундый җавап кына кирәк тә иде. Димәкки, ул иркенләп йөри алачак!... Шул куанычтан бик итагатьле хадимчә, һич сүз озайтмастан, тынып калды. Әлеге үзе яздырган хатларны бик дикъкать белән укып чыкты. Кирәкле урыннарының асларына сызгалаганда да көлмәде.

— Яхшы! — дип куйды ул аннары. — Эшләү — безнең бурыч. Кушканнарыгыз һәммәсе дә үтәлер, хөрмәтле әфәндем!..

## VII

Апрель ахырлары җитеп килә иде. Язгы гөрләвекләрдән соң сулар ташып, туктаусыз яңгырлар явып узгач, Балтикның озакка сузылган чи томаннары күтәрелгәч, яңадан матур җылы көннәр урнашты. Кошлар тавышы тагын да күбрәк һәм дәртлерәк булып ишетелә башлады. Табигать кешеләрне үз кочагына чакырды. Аның өндәвен йөрәкләре белән ишеткән егетләр, ял көне җитү белән үк, Албайнплац тирәсендәге елга һәм күл буйларына балыкка киттеләр. Ә Симай белән Алиш Вайсензее [1] буена ашыкты. Мусаны да бик кыстап, шаян күз кысулар белән: «Сагынгандыр бит...» дигәләп карасалар да, урыныннан кузгата алмадылар. Ул өйдә калды. Аның ни өчендер күңеле салпы иде. Алиш хәтта борчылып та алды: «Нәрсә, әллә берәр күңелсезлек бармы?» — дип сорады ул. Юк иде, бер күңелсезлек тә юк иде. Моның нәрсәдән икәнен Муса үзе дә белмәде. Бүген-иртәгә дигәндәй юлга чыгасы һәм анда тагын шул кыен да, җаваплы да, куркыныч та эшләргә чумасы булгангамы, әллә күңелләрне яз нечкәртеп, Чулпанын, Әминәсен сагындыргангамы, — моны ул ачык кына аңлый алмый иде.

Бүлмәдә ялгыз калган Муса тәрәзә каршында уйланып утырды. Кайчагында җәйге көн шулай тынып кала бит. Әле генә чәчәкләрне тибрәтеп, хуш исләрен урап йөргән шаян җил әллә кая гына китеп югала. Әле генә сине пешергән кайнар кояшка зур гына иске мамык юрган бөркәлгән була. Тып-тын калган дөньяны талгын һәм рәхәт бер моңсулык баса. Арка юлларыңнан җылымса салкын йөгерә һәм, аның рәхәтен тоеп бетерә дә алмыйсың, әкрен генә шыбырдап, бик тәмле, бер һәйбәт яңгыр явып китә. Әлеге моңсулык каядыр югалып, күңелләргә тагын куаныч тула. Әмма мондый хәл бер табигатьтә генә түгел, яшьрәк чакларында Мусаның үзе белән дә еш кына булгалый иде. Уен-көлке сүздән, кояшлы көлүдән туймаган яшь егет ялгыз юлда йөргән вакытларда яки редакциядә утырганда кинәт кенә тынып кала. Күңеле, җил өрсә өзелердәй сыңар бөртек ефәк җеп шикелле, чиксез нечкәреп китә, нәрсәдер җитмәгән, нәрсәдер кызганыч төсле һәм ниндидер бик бәхетле бер минут кителгән төсле булып, бөтен дөньяны җиңел бер моңсулык каплый һәм Муса, күзләренә тулган сабыйларча мөлдерәмә яшьләрен тыя алмыйча, шундый татлы итеп, рәхәт итеп елап җибәрә, ә шуннан соң аның бөтен җаны-тәне җиңеләеп, эченә бер ярсу шатлык тулып кала иде.

[1] Аккүл.

Бүген дә ул үзендә шуңа охшашлырак хәл тойды. Күз төпләрендә яшь тамчысы хәзергә күренмәсә дә, күңеле артык дәрәҗәдә нечкәргән иде. Аның язасы килде. Инде әллә кайчаннан бирле кулына каләм тотканы юк бит. Күп вакытлардан бирле кесәсендә йөрүдән тышлары шомарып беткән, почмаклары ашала башлаган куен дәфтәрен чыгарып, өстәлгә салды. Дәфтәрнең язылмаган битләрен ачып куюга, аны темалар, уйлар, истәлекләр чорнап алды. Язасы килгән нәрсәләр шундый күп, ләкин аларның барысын да кәгазьгә төшерү мөмкин түгел. Иң кирәкләрен генә язасы иде. Менә ул иртәгә-берсекөнгә тагын батальоннарга китәргә тиеш. Яңа шигырьләр алып барасы иде бит. Кешеләргә күңелле шаян сүз, җылы юмор да бик тәэсир итә. Шундыйларны булдырырга кирәк. Дөрес, шигырьләрнең берсендә дә дошманга каршы фикерне турыдан-туры әйтү мөмкин түгел, әмма үзебезнең илдәге тормыштан язылган әсәр үзе генә дә кешеләрне туган җирләренә бәйли, үзләрен шул тормышта итеп хис кылырга өйрәтә түгелме? Димәкки, бу инде барыбер дошманга каршы була...

Уйлар артыннан уйлар йөгерде. Язасы әйберне һәрвакыт берәр вакыйга, хис һәм истәлек тудыра. Ә инде шуны кәгазьгә төшерим дип утырсаң, ул синең күз алдыңа килеп баса. Бу юлы да шулай булды: Муса әле дәфтәр битенә бер генә сүз дә язмаган килеш ерак һәм татлы хатирәләренә кереп югалды. Кеше күңеле һәрвакыт иң кадерлесен сайлый. Муса да Волхов камалышында һәм әсирлектә узган көннәрен, карыйсы килмәгән ямьсез бер картина шикелле, читтән әйләнеп узды да Казанга кайтып төште. Казан! Күпме матур чаклар анда, күпме онытылмас хатирәләр! Менә солдат шинеле генә кигән Муса, кыш уртасы суыгында ярым җәяүләп дигәндәй, Минзәләдән Казанга кайтып керә. Хәсрәтле, ябык чырайлы Әминәсе, аның каршына килеп, басынкы гына үбә дә башындагы ап-ак колакчынын салдырып, карларын кага, аркасындагы яшел капчыгын ычкындыра һәм шыгырдавык бил каешын чишә башлый.

— Чулпан кая соң? — ди Муса, күзләре белән бүлмәне гизеп. — Нигә күрмим?

— Теге бүлмәдә ул, — ди Әминә, әкрен тавыш белән. — Авырып тора. Температурасы 39. Әллә нигә бер дә төшми. Дарулар да бирдем инде, югыйсә...

Муса тиз генә шинелен салып ташлый да тәрәзә астындагы батареяларга кул җылытырга килә. Аларда җылы бик аз, ә бүлмә шактый ук салкынча. Рәтләп якмыйлар да икән шул. Ул, кулларын уа-уа җылытып һәм гәүдәсендәге суыкны җилпеп төшерергә теләгәндәй кочагын ачып селкенгәли дә күрше бүлмәгә юнәлә. Юрганнарга төрелгән Чулпан караватта ята.

— Чулпаным, йолдызым! Исәнме, балакаем? Авырыйсыңмыни, бәгырем, хәлләрең ничек? Әтеки кайтты бит, таныйсыңмы солдат әтине?.. — ди Муса.

Чулпан аны таныды. Елмаерга теләгән кебек тә булды, ләкин елмая алмады, аның төсләре киткән, чырае сары, битләре утә күренердәй юка, ябык иде. Муса аның шул битләреннән һәм чәчләреннән, «суыгым кагылмасын» дигәндәй, сак кына үбеп чыкты. Аннары кулын Чулпанның маңгаена куйды. Маңгае уттай кайнар һәм дымсу иде. Муса, бөтен дөньясын онытып, аның янында калды. Бер кулын Чулпанның маңгаена куйса, икенче кулы белән караватның салкын никеленә тотынып, уч төбе тәмам суынып җиткәч, аны тагын баласының маңгаена каплады, ә тегесен суытырга куйды. Үзе һаман кызын иркәләде, аны көлдерергә, күңелен ачарга тырышты. Шулай итә торгач, ике сәгать узуга, Чулпанның температурасы 37 гә төште, аңа җан керде, әтисе белән сөйләшә, шаяра башлап, урыныннан ук торды да Мусаның муенына сарылды...

Бу искиткеч хәл ул чакта Мусаны бөтенләй тетрәтеп җибәргән иде. Карачы, ата белән баланың бер-берен тирән ярату, сөю көче нинди кодрәткә ия икән! Мәхәббәт хастаны түшәктән торгыза! Гаҗәеп бер ачыш иде бу шагыйрь өчен. Һәм бу, мәңге онытылмас көчле бер вакыйга шикелле, Мусаның күңел түрендә утырып калды. Чулпанның шулай терелеп китүенә ул чакта бик куанган иде Муса. Иң бәхетле кеше булган икән ул! Хәзер менә, бөтенесеннән мәхрүм ителгәч кенә, моның шулай булганы бик ачык күз алдына килә һәм кайтару мөмкин булмаган еракларда калуы йөрәген талап тора...

Ниндидер эчтән килгән кайнар дулкын аның күңел түрләренә, кан тамырларына тулды, иң нечкә кылларын һәм кайдадыр яшеренгән шигъри рухын тибрәндереп җибәрде. Балага иң саф мәхәббәт һәм рух көченең шундый могҗиза тудырып, авыруны җиңгән бу изге минутларын, ничектер әле сүз дә булып җитмәгән уйлар белән авыз эченнән генә пышылдый башлады ул. Ниһаять, өстәлдә яткан нәни дәфтәр битенә яңа гына туып килгән шигырьнең кайнар юллары агыла башлады:

Кыз авырды, тәне ут шикелле,
Сулыгып-сулыгып тибә йөрәге.
Гаҗиз калды доктор, авыру кызга
Бер дару да файда бирмәде...

Яткан чакта авыру түшәгендә
Авыр төшләр белән саташып,
Ачылды да ишек, юл киеменнән
Кайтып керде аның атасы.

Маңгаенда батыр яра эзе
Һәм билендә поход каешы.
Еллар буе кызны ялыктырды
Шул атаның йөрәк сагышы...

Таныш йөзне күреп кыз елмайды,
«Әти!» диеп аңа үрелде.
Шул төнне үк йөздән тире чыкты.
Кызу кайтты, тәне сүрелде.

Гаҗәпләнмә, доктор, күреп кызның
Дару эчми кинәт савыгуын.
Белмәденме: җирдә «сөю» дигән
Иң куәтле дәва барлыгын!

Әйе, сөю! Һәм ата һәм бала күңелендә, гомумән, кеше йөрәгендә булган тирән һәм көчле мәхәббәт бөтен дарулардан өстен, бөтен газапларны, бөтен кыенлыкларны җиңеп чыга ала, кешеләргә тау-таш кичерерлек кодрәт бирә! Һәм шуңа ышану — үзе бер бөек ләззәт, юаныч!

Монда салынган хисләр легиондагы әсир күңеленә барып җитсә, аны да уятачаклар. Ул да үзенең еракларда калган мескен баласын сагыныр һәм шунда омтылыр. Әгәр шушыңа ирешсә — шагыйрь бәхетле булачак...

Яңгырдан соң иркенәеп киткән һава төсле, Мусаның да күңеле бушанып калды. Кузгалып яңадан тәрәзә каршына килде. Кояшлы җирдәге үләннәр яшәреп маташалар, агач бөреләре, кызыл кабыкларын ачып, яшел күзләре белән дөньяга карарга тырышалар. Каяндыр адашып килгән ялгыз күгәрчен ишек алды такырыннан җим эзләп йөргән була...

Шуларга сокланып торганнан соң Муса яңадан кәгазь өстенә беректе һәм, сәгатьләргә сузылган иҗат газабы кичереп, «Бүреләр» шигырен язды. Ул бөтенләй икенче бер агылышта килеп туды. Аның аерым бер эпик пафос һәм көчле басымнар белән укылуны таләп итүе тыңлаучы күңеленә тагын да тирәнрәк йогынты ясарга тиеш иде. Моны инде үзара тар төркемнәр эчендә укыттыру кирәк булыр.

«Кешеләр егетнең тәненә
Кыздырып шомполлар бастылар.
Туйганчы җәфалап,
соңыннан
Ялгыз аккаенга астылар»—

дигән юллар аеруча тетрәтерлек итеп укылырга тиеш иде, моны Муса, әлбәттә, укучы егетләргә үзе аңлатып бирер.

Һәр иҗат кешесе, зурмы-кечкенәме бер эш башкарып чыкса, иң элек үзе куана, үзе канәгать була. Күптәннән бирле җыелып килгән эч пошулары таралып, рәхәтләнеп китә. Муса да, кулларын баш артына күтәреп, бармакларын аралаштырды да бер киерелеп куйды. Җиңел булып китте аңа.

— Яхшы булды бит әле бу! — диде ул, кем беләндер сөйләшкәндәй кычкырып. — Көн матурлыгы бик кызыктырса да, күл буена чыкмауның бер файдасы тиде!

Шул чагында сак кына ишек кактылар.

— Рәхим итегез! — дип кычкырды Муса, һични уйламастан.

Ишек кыюсыз гына ачылды һәм шулай ук кыюсыз гына атлап керүче Әлбидә күренде. Муса, аны күрүгә, гаҗәпсенүле шатлык белән каршына барды.

— Әйдүк, Әлбидәкәй, рәхим ит! — Кызны җитәкләп түргә алып килде, урын бирде. — Я, исәнме, ни хәлләр бар?

— Әйбәт, Муса абый, — диде Әлбидә. — Менә көн озын Аккүл буенда утырдым да, күңелем түзмәде, сезне эзләп үзем килдем. Сезнең бөтен иптәшләрегез анда, сез генә юк... Ә мин сагындым...

— Менә бит... кәгазь буяп утырам, — дип көлде Муса. — Тиздән тагын Польшага җыенам... Солдатның күңелен ачарга кирәк!.. — Бу, әлбәттә, җавап түгел иде. Муса моны бик яхшы белгәнгә, үзенең уңайсыз хәлен көлү белән капларга тырышты.

— Шулай инде... — дип куйды Әлбидә, үпкә катыш тавыш беләнрәк, Мусага карап. — Солдат күңеле... — Ул шушы минутта тагын бик күп, бик күп нәрсәләр әйтергә теләде. Күл буенда табышканнан соң яңадан кабынып киткән кайнар хисләрен, фәкать аның белән генә юанып яшәвен, ә Мусаның әйтмичә дә китеп баруын, үпкәләрен аңлатасы килде. Ләкин шуларның һәммәсе урынына: — Ичмаса бер шигырь дә укыганыгыз юк... — дип кенә куйды.

— Шигырьме? — диде Муса, шул ук беркатлы елмаю белән. — Һи-и, әгәр эш шунда гына икән, шигырьне укыйбыз аны! — Һәм ул үзенең иң яраткан шигырьләрен Әлбидәгә укый башлады.

Әлбидәнең йөрәгендә үзе дә белмәгән шагыйрь ята иде. Ихтимал, шуның өчендер, ул чын шигырь матурлыгын бөтен нечкәлеге белән тоя һәм аңлый белә иде. Аның өчен шигырь юлларында мәгънә генә түгел, ә бәлки әйтеп бетергесез ниндидер музыка да яңгырый иде кебек. Муса әсирлек лагерьларында язган шигырен укыды. Ул юллар, шагыйрь тавышы белән бергә кушылып, Әлбидә өчен үзәк өзгеч тирән сагышлар, әрнеткеч газаплар дөньясыннан яңгыраган, аның үз бәхетсез язмышын да әйтеп биргән авыр җыр булып ишетелде. Ул тетрәнеп Мусага сыенды, битләре буйлап кайнар кургашлар тәгәрәде. «Муса абый, җаным, җитәр, телгәләмә бәгыремне!» — дип пышылдады ул. Муса аның йөзенә күз төшерде. Башка вакытларда акыллы сабырлык күрсәтә белгән Әлбидәнең чыланган зур күзләре еларга яратучан сабый бер кызчыкны хәтерләтә иде бу минутта. Муса карагач, ул үзе дә мондый хәленнән оялып китте, ахры: түбән иелеп, бит-күзләрен тиз-тиз генә сөрткәләп алды, аннары көлемсерәп Мусага карады.

— Гафу ит, Муса абый, — диде ул, яктырыла барып. — Кайчагында җылауның да бер тәме, бер рәхәте бар. Мин хәзер җылый алуым өчен үземне бәхетле саныйм. Ә теге вакытта, синең белән үлем авызында

аерылышканнан соң, бәгырь минә яныт сүнгән кисәү булып каткан иде. Җылый да, көлә дә алмый идем...

Муса аның аксыл-сыек төтен сарган чәчләреннән, иңбашларыннан бик ягымлы итеп, бик туганчыл һәм дус итеп, йомшак кына сыйпап куйды. Аның күңеле ниндидер изге хисләр белән, саф ярату һәм соклану тойгылары белән тулды. Бу минутта аның өчен Әлбидәдән дә кадерле кем генә бар иде икән? Ул аны, җил-яңгыр тидермичә, һич кемнән җәберләтмичә саклап, туган-үскән җирләренә алып кайтасы һәм газиз әнкәсе кулына тапшырасы килде. Ул аны үзенең иң якын һәм иң ышанычлы дусты, сердәше санады, ләкин ул аңа гашыйк була алмады.

Әлбидә үзенең икенче тапкыр монда килүен мәхәббәт теләнчесенең бер сынык сөю эзләп йөрүе дип көлде, үзен түбәләде. Әмма аның бер генә адымында да оятсызлык, йөгәнсезлек сизелмәде. Аның һәрбер хәрәкәте чын матурлык һәм гыйффәт белән тулган, күкләр биегендәге сафлык белән бизәлгән иде.

Шулай да ул бүген аеруча кыю булырга, каушамаска тырышты. Бая гына мәми авызлык күрсәтүе өчен үзен әрләп алды. Әмма туп-туры гына тагын әйтә алмыйча, сүзен әйләнечтән башлады.

— Муса абый, — диде ул, хәзер инде тыныч кына итеп. — Без иртәгә зур эшкә керешәбез... Авиация көтеп эш чыкмады инде...

Мусаның йөзләре агарынып китте. Ул, җәһәт кенә торып, ишекле-түрле йөренә башлады. Менә бит ул: дәһшәтле минут килеп тә җитте. Теге чокырда Бакшанов белән ансат кына сөйләшкән сүз хәзер, ук шикелле, йөрәккә кадала икән! Бер дә соң башка җай таба алмадылар микәнни?... Ичмаса Исрафилов белән дә эш барып чыкмады. Муса эзләп баргач, лазаретта, диделәр, авыр контузия, диделәр...

Әйләнеп килешле бүлмә уртасында туктап, Әлбидәгә карады. Аның йөзе шундый тыныч, хәтта елмаеп утыра. Сиздермәскә тырыша, гөлкәй...

Әлбидә дә аңа күтәрелеп карады һәм Мусаның эчке газапланулары шунда ук укып алды. «Белә икән! Муса абый да белеп тора икән!.. Күрәсең, Бакшанов белән бергә уйлашканнар алар бу эшне. Менә аның теге вакытта әйтеп бетермәгән сүзләре... Легион солдатлары арасында да тиккә генә йөрмидер ул болай булгач!..» Һәм Әлбидә сөенеп куйды:, «Минем өчен хафалана... Димәк, сөя ул мине! Мин нинди бәхетле!»

— Бер дә соң... — диде Муса тотлыгыбрак, — башка мөмкинлек... башка кешеләр табылмадымыни?..

— Юк, Муса абый, мин әйтеп сезне борчырга килмәдем, — диде Әлбидә, аны тынычландырасы килеп. — Монысы аның сүз башы гына. Сез бер дә курыкмагыз... Мин үзем әйтеп, үзем теләп барам, һәм бар да ал да гөл булачак, менә күрерсез!.. — Ул кыен бер тыныш ясап куйды. — Минем әйтәсе сүзем башка иде... Әгәр иң соңгы минутта телеграф, телефон яки радио аша әйтү мөмкин булса, «эш»кә тотыныр алдыннан гына: «Муса абый, мин сезне сөям! Изге теләктә булыгыз!» дип кычкырыр идем дә җәһәннәмнең үзенә ыргылыр идем...

Муса баскан җирендә беравыкка тетрәнеп калды һәм шундук ниндидер кызулык белән килеп, Әлбидәне күкрәгенә кысты. Көмеш төтен сибелгән баш түбәләреннән үпте, куллары белән аркасыннан сөйде. Бу минутның кайчан да булса бер киләсен ул инде күптән сизенеп йөри иде. Бу чакта куркак һәм вак җан булып калмаска, шулай ук кыз баланың ачык, саф гыйшкын фәкать вәхшиләрчә генә аңлап, нәфес колы да булмаска, аны пычратмаска кирәк иде. Олы җанның олы мәхәббәтен ничек кенә рәнҗетмәскә соң? Ничек кенә кырау тиереп куырмаска?..

— Бәгырькәем! Гөлкәем! — диде ул, кабат аны күкрәгенә кысып. — Син минем иң яхшы дустым, йөрәк сердәшем. Бөтен саф хисләрем, изге

теләкләрем синең белән минем! Алар сиңа сакчы булсыннар. Алар синең куркыныч юлыңда ярдәм итсеннәр!

Әлбидә әкрен генә башын күтәрде. Ул, моңарчы күргән газап утларында әле һаман да янып-көеп бетмәгән яшьлегенең бөтен матурлыгы белән балкып, сабыйларча бәхетле елмая иде. Елмая-елмая Мусаның күзләренә карый иде. Шуннан соң ул, күзләрен йома төшеп, башын аның иңсәсенә куйды да көчле тавыш белән җырлап җибәрде:

— Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Юлларыңа тезәм мин...

## ҖИДЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Муса Радомнан Едельняга килү белән беренче батальонга ашыкты. Ул инде элекке килүләрендә үк мондагы немец командирларының кирәклерәкләре белән ныклап танышты, Берлиннан килгән рәсми түрә буларак, үзенең хәрбиләрчә җитди һәм катгый сыйфатларын да күрсәтеп киткән иде. Гомумән, батальоннарга килгәч тә иң элек немец командиры белән якынтын аралашу аның төп кагыйдәсенә әверелде. Чөнки шулай иткәндә генә немецта шик-шөбһә тудырмау, аның ышанычын казану мөмкин.

Бу юлы да шулай башлады ул: туп-туры штабка, батальон командиры бүлмәсенә керде. Немец үзе генә борынын казып утыра иде.

— О, унзере культурфюрер![1] — дип каршылады аны майор Краузе. — Исән килдегезме?

Алар күптәнге танышларча иркенләп сөйләшә башладылар. Муса, батальонның фронтка китәчәге турында әле бернәрсә дә белмәгән кеше булып, үзенең язгы-җәйге сезоннарда солдат арасындагы мәдәни эшләрне яңа формаларга куеп җибәрү өчен килүен әйтте. Хәзер көннәр матурайды инде, солдатлар буш чакта төрле уеннарны — кичке концерт, киноларны ачык һавада оештырып җибәрергә дә мөмкин, дигән булды.

Майор көрсенеп, елмаеп утырды.

— О, цивилишес глюкскинд![2] — диде ул. — Сез әле һаман үз флейтәгезне уйнатасыз. Ә без инде тәгәрмәчләр өстенә мендек. Нах Остен![3].. Анда инде башка төрле музыка булачак, һәм аяк белән түгел, корсак белән биергә туры киләчәк!

— Шулай укмени-и? — дип сузды Муса, иң гаҗәпләнгән тавыш белән. — Карасана, миңа бу хакта Берлинда һични аңлатмадылар.

— Алар нәрсә беләләр? Тыл күселәре бит анда! — диде майор, пафос белән. — Менә алайса ишетегез инде: сезнең культвзводны да таратгык без...

— Культвзводны да?.. — Мусаның кинәт күтәрелеп бәреләсе килде. Нинди кыенлык белән тупланган сәнгать көчләрен! Дуңгыз бу немец!.. Ләкин дуламады ул.

— Болай булгач миңа эш тә калмаган икән монда, — дип кенә куйды, үкенечле кыяфәт белән.

— Ә командиры Актабанофны үземә денщик итеп алдым, — дип дәвам итте Краузе, канәгать елмаеп. — Бик сүз тыңлаучы карт. Итекләрне бик шәп итеп чистарта, зеер культурелл[4]. Кофены да искиткеч пешерә, каян өйрәнгән, сабакә-эй! — (Бу сүзне ул русча әйтте.) — Шунлыктан аны сугышка кертмичә, үз янымда тотмакчы булам.

— Әлбәттә, — диде Муса, — яныңда андый оста да, яхшы да лакиең булу — блиндажда интегеп яткан чакта үзе бер бәхет бит ул.

[1] О, безнең мәдәни житәкче!
[2] О, цивилизациянең бәхетле баласы!
[3] Көнчыгышка!
[4] Бик культуралы.

— Андый лакей бик кирәк, — дип, авыз ерды майор. — Ул андагы руськи фраулардан яйко, млеко, курка табып китерү өчен дә бик шәп булачак!

— Дөрес, бик уңышлы сайлагансыз...

Шул чагында ишектән Актабанов үзе килеп керде. Керү белән шәмдәй туры катып, честь бирде һәм шул хәлендә: «Аш әзер, ау кирәк-яраклары бар да әзер, майн хер!» — диде, немецчаны шактый җимергәләп.

Ул, денщик булгачтыр, ахры, яңадан мыек үстереп җибәргән. Ләкин мыеклар, элеккегә караганда җансызрак булып, шактый салынып төшкән. Яңак һәм иякләре шома итеп кырылган булса да, картаеп киткәнлеге, сызып ябыкканлыгы ачык күренә иде. Мусага күз кырыен гына төшереп, әз генә авызын кыймылдатты, исәнләшүен белдерергә теләде, күрәсең.

— Гут,— диде майор.— Хәзер кайтам бүлмәгә.

Актабанов, солдатча җитез борылып, чыгып китте.

— Ә сез ауга йөрүне яратмыйсызмы, майн һерр? — дип сорады немец Мусадан.— Ә мин бик яратам. Әйдәгез, теләсәгез алып барам. Фронтка чыгып киткәнче берәр тапкыр йөреп кайтыйм дигән идем, анда эләкмәс бит...

Муса ауны яратмыймы соң? Үлеп китә инде ул ауда йөрер өчен! Бигрәк тә, майор Краузе белән. Шундый күңелле компания булачак! Шул гына инде аның бөтен кайгысы, бүтән бер хәсрәте дә юк! Әнә бит, шайтан ялаган нәрсә, нишләгән? Подполковник Актабановны үзенә лакей иткән, культвзводны тараткан! Шулай итеп бөтен эшең чуалып, чыгырыннан чыккан булуы мөмкин. Ау кайгысы гына инде Мусада!..

Муса, чынлап та, аптыраштарак калган иде. Ничек икән соң монда хәлләр? Ләкин Краузега ул бөтенләй икенче төрле җавап бирде.

— Ауда йөрү белән балык тоту өчен хәтта Рубикон кичәргә дә мөмкин! — дип җибәрде Муса. — Мин аккош атар өчен Мәскәүдән Сибирия күлләренә хәтле китә идем. Чөнки аккош аулау искиткеч кызыклы һәм матур шөгыль! Ә инде омоль балыгы өчен хәтта Байкалга барып җиткәнем бар. Фәкать Байкал күлендә генә шундый бер омоль дигән балык яши, эх, аның тәмлелеге! Хәтта бармакларыңны суырып йотарсың! — Ул өч бармак очын авызына китереп, чөңгереп куйды. Немецның моңа бик үк ышанасы килмәсә дә, күзләре уттай елтырап китте:

— Сезнең анда колач җитмәс киңлек инде, әдәм аяк басмаган кыргый почмаклар бар, диләр. Шайтан алгыры, барып җитеп булырмы шунда, юкмы бер!.. — Краузе көрсенеп куйды.

— Әмма хәзер майн һерр, — диде Муса, шулай ук көрсенгән булып, — бик теләсәм дә сезгә юлдаш була алмыйм. Бик үкенеч, әлбәттә, без бит бәйле кешеләр, ихтыяр гел үзебездә генә булмый. Өченче батальонда солдат артистлар театр хәзерли икән. Миңа шул эшнең идейный җитәкчелеге тапшырылган. Сезне, әгәр китеп өлгермәсәгез, милли театр белән сыйларга исәп бар.

— Дас ист интересант! [1] — дигән булды немец. — Гут, гут. Мин бик яратам разный солдат кәмитләрен! Яхшы алайса, хәзергә ауф видерзейн [2].

— Ауф... — диде Муса, кулын эшләпәсенә күтәреп.

Штаб баскычына чыккач, алар икесе ике якка китеп бардылар. «Күрсәтерләр әле алар сиңа кәмитне! — дип атлады Муса ком сибелгән сукмактан. — Әгәр эшләр таркалып китмәгән булса...»

Кояш үзенең җылы нурлары белән аның аркасына кагылды. Әз генә җил исә, агачларның яңа гына күзләрен ачкан сыек-яшел яфраклары

[1] Бу кызыклы булачак.
[2] Хушыгыз.

сабыйларча үзалдына нидер сөйләшкән булалар, язгы дөньяның матурлыгы күзгә кереп тора, әмма шулай да Муса аларга күтәрелеп сокланa алмый, ул һаман пошынып атлый иде. Аның әйтәсе сүзләре тамак төбендә бөялеп калды. Ә ачуны эчкә йоту — таш йотудан да авыр! Ләкин йотмый хәлең юк... Хәтта аның яклы булып кыланасың... Көрәш башланып киткәннән соң, бу кагыйдә буенча эш итәргә тотынгач, Муса шактый зур борылыш ясаган кеше булып күренә башлады. Шәфи дә, Унгляубе белән Розенберг та һәм хәтта телләр корты фон Менде дә: «Безнең большевик шагыйрь уңга таба матур гына борыла бара, кучәрләре яхшы эшли!..» — дип, кулларын уалар иде.

Ә батальоннарда бу кагыйдәнең кирәклеге тагын да ачык күренде. Чөнки немец мондагы әсирләрдән үзе солдат әзерләгән була, ә үзе аларга азиат дип җирәнеп карый, ышанмый, кирәк булса, тиз генә автомат белән кырып ташларга да әзер тора. Менә шундый чакта син аның ул кабахәт автоматын оста гына кире кагып җибәр, шома һәм кыю рәвештә арасына кер дә түр башына менеп утыр һәм үзеңнең ясмык камырыннан ясалмаганыңны күрсәтә бел! Ләкин моңа ансат кына ирешү мөмкин түгел, һәрвакыт бер каршылык килеп чыга, немец килерлегенә килеп төртеләсең... Бөтен эшеңне боза да ташлый...

Муса пошынып атлавында дәвам итте. Тар гына җәяүле сукмак аны урман эченә әйдәде. Муса, үз уйларына да сукмак табарга теләгәндәй, һаман эчкәрәк атлый бирде. Хәзер җепне ничек ялгап җибәрергә соң? Иң начар хәл — билгесезлек... Актабанов та куңелсез, картайган сыман күренде. Аны тагын бу немец ауга алып чыкса, күрә алмыйча да китеп барсаң?.. Ичмаса, ул Арысланны кайдан табасы икән?.. Культвзводны җимереп ташлаган бит, вәхши немец! Шуңа сөенеп утыра!.. Югарыдан килү хокукыннан файдаланып, эт урынына сүгәсе калган ул тинтәкне!..

Аның гәүдәсендә ниндидер талчыгу, авырлык сизелә иде. Ләкин, моңа игътибар итмәстән, ул һаман эчкәрәк атлады. Чуалчык уйларының ничек тә бер очын табарга тели иде ул...

Ә майор Краузеның Муса белән сөйләшүдән кәефе булган иде. Хәтта ул аның хакында яхшы уйларга чумды: укымышлы сөйли, сүзләрендә дошманлык хисе сизелми. Үзе тагын аучы да икән. Омоль өчен Байкалга барган! Шагыйрь диләр бит, андый халык тилемсәрәк була инде ул...

Кайтып табынга утыргач, аш алды ясап, әз генә кәефләнеп тә алганнан соң, тагын нигәдер Муса исенә төште. Ул аны ауга чакырды, әмма өстәленә чакырмады. Дөрес эшләдеме? Фюрер офицеры буларак, дөрес эшләде. Саф арий канлы офицер белән азиат шагыйрь бер табынга сыймый! Ә инде аучы буларак?.. Җитмәсә, ул да аучы... Ауда бит граф та, лакей да бер чирәмгә ятып ашый...

— Әй, Анисмин, — диде Краузе. — Бар, әйт кухнядагыларга, Берлиннан килгән культфюрер Һумерофка аш илтсеннәр!

Актабанов солдатча кул күтәреп, «Есть!» диде дә чыгып китте. Шуннан соң майорның гуманист күңеле тәмам тынычланып калды. Ул, фрау Краузега елмая-елмая, тәмләп ашый башлады.

Онисим Гуриевич кухняда Арысланны күреп, савыт-саба әзерләргә кушты. Арыслан әле, гәрчә Берлинга газеталар өчен баргаласа да, аш блогыннан һаман аерылмаган иде. Аны иптәшләре ничек кенә булса да шул урында сакларга тырышты. Йөгенгәннәрне ныклабрак туйдыру кирәк булган чакта анда үз кешең булу бик мөһим иде.

— Майордан приказ: культфюрер Гумеровка аш илтергә! — диде Актабанов, рәсми төс белән. Блок башлыгы да, өлкән повар да шунда иде. Арыслан шул арада мискеләр тотып килде:

— Рөхсәт булса, үзем илтим, һерр блокфюрер?..

Немец кул гына селкеде. Ул гел сызгырып йөрүче бер җирән Һанс иде. Арысланнан һәм кухняда эшләүче башка егетләрдән татарча сүз-

ләр өйрәнеп ала да шуларны кызык өчен кабатлап йөргән була.

— Ярн, бар, кайт, кит, киль! — диде ул хәзер дә. Әмма күбрәк иҗекле сүзләргә ни өчендер теле әйләнми иде ул сыбызгының.

Арыслан, үзе булдыра алганча, ашның юньлерәген калай мискеләргә салып, җәһәт кенә чыгып китте. Актабанов та аның артыннан чыкты. «Теге ауга алып китмәсә, мин дә кагылырмын...» диде ул, ярым пышылдап, һәм шунда ук үз юлына юнәлде.

Арыслан шулай җәһәт кенә атлап барганда, янәшә сукмакта гестапочы Шпигель күренде.

— Куды пшель? — дип кычкырды ул, һичбер кирәкмәсә дә.

— Әбиең...нән сора, — диде Арыслан татарчалатып.

— Вас ист дас?

Солдат аслы-өсле куйган мискеләрен күрсәтте.

— Берлиннан килгән түрәгә аш илтәм, майор кушты.

— Нинди түрә ул?

— Культурфирур Гумеров.

— Һумероф? У-у, сине, хәйләкәр тартарен! Беләм!..

Шпигель башкача бәйләнер сүз тапмады, тик нәрсәдер авыз эченнән мыгырданып кына калды. «Бу да безнең белән фронтка китәр микән? — дип уйлады Арыслан. — Кети-кети уйнарыек үзе белән әзрәк. Бөтен изгелекләре өчен...»

Баскычтан күтәрелеп уңга борылгач, Мусаның ишеген шакыды ул. Җавап ишетелмәде. Янә какты... Тынлык... Кайтып җитмәде микәнни соң әле һаман... Ак тузлы каен ботагыннан ясалган диванга утырып тәмәке тартты. Арысланның күңеле бу араларда гел күтәренке һәм беркадәр җилкенүле иде. Фронтка җибәрелү хәбәрен ишеткәч тә, «кәнсәкәнис, котылыр көннәр җитә икән!» дип куанды ул. Ә котылу нинди юллар белән килер — анысын уйламады да. Анда киткәч, дүрт як кыйбла булып күренде аңа. Гомуми максат билгеле иде, шуңа күрә иптәшләренә дә, үзенә дә ышанып фикер йөртте ул. Һәм чынлап та, гади солдат буларак, Арыслан кемнәр белән генә сөйләшмәде. Икәүдән-икәү утырып тәмәке тартканда һәркемнең авызында шул бер зар иде: «Бу каһәр чокырыннан ничек котылырга?» Һәм һәркем үзенең котылуын фронтка китүдә күрә иде. Фәкать шундый сөйләшүләрне тәмле итеп алып бару өчен генә, гомердә тәмәке тартмаган кеше тәмәкегә өйрәнде: ничава, тыгыласың-тончыгасың да, суыра торгач, күнегәсең икән!

Тәмәкесе әллә кайчан тартылып беткән, ә ул һаман уйланып утыра, өч көннән үк өенә кайтып керәсе, барлык якыннары белән кочаклашып күрешәсе яшь шәкерттәй, хыялларда йөзә иде. Үзе үк сискәнеп китте. «Әй-й, аш суынып беткәндер инде, тиле-тинтәк!» — дип урыныннан сикереп торды һәм тагын ишек какты. Ә Муса һаман юк иде.

Арыслан, борчылып, кабат шакыды. Шул чакта баскычтан күтәрелеп, Муса аның артына килеп басты.

— Менәтерә вәт! — дип куйды Арыслан. — Ә мин сине йоклыйсың дип торам. Туп аттырсаң да уянмый икән, дип... Менә аш суынып бетте инде...

Алар «Зольдатенхайм»дә Мусага бирелгән бүлмәгә керделәр.

— Нихәл, исәнме? Без әле күрешмәгән дә бит монда килгәч, — диде Муса. — Нинди аш соң бу?

— Аллага шөкер, бәләкәчем, исән килеп җиттеңме? Кая югалып йөрдең болай, серле курай? — дип тезеп китте Арыслан. — Ашны майор әфәнде җибәрттерде.

— Кара син аны! — диде Муса көлемсерәп. — Хәер, аучы дус бит ул минем, кадалып киткере. Актабановны үзенә лакей иткән, хәзер ничек күрәбез инде аны. Ул бит немец каршында биеп торырга тиеш.

— Мин аны күрдем, — диде Арыслан. — Әгәр майор ауга алып китмәсә, озакламый килә дип әйтергә кушты.

— Ә син миңа Берлинда бу хәлләрне әйтмәдең дә...

— Бу хәлләр мин югында булган шул. Кайткач үзем дә аптырап калдым... Ярар, син аша, бәләкәчем. Бөтенләй суынып беткәндер, кырык минутлап көттем ишек төбендә. Мин китим, югалтканнардыр...

— Тукта, хәзер китәрсең, — диде Муса. — Без бәлки кабат күрешмәбез дә. Чөнки мин хәзер теге батальоннарга китәм. Сез кузгалганда күз көеге булмау яхшы... Ничек соң сезнең үз эшләрегез?

— Бар да үз тәртибендә шикелле. Калганын сиңа Уничим Гурич сөйләр... Я алайса, хуш, сау бул. Тукта, бер кочаклыйм әле үзеңне. Хуш, бәләкәчем, үзеңне сакла! Без исән-сау үз туган җиребезгә барып чыгарбыз, биргән булса. Сезне дә шунда көтәбез. Икенче кочаклашу шунда булыр!

Муса аны кысып кочаклап алды. Озак итеп күзләренә карап торды. Күпме вакытлар бергә михнәт чиккән гади дусты белән тиздән аерылышачагына күңеле ышанып та житми иде әле аның. — Уңыш телим, дускаем! Хәерле юл! Акыл белән йөр, абайлап эш кур, — диде ул, киңәш өстенә киңәш биреп.— Гуриевичны ташлама... Адреслар бар. Исән-сау чыгып җиту белән минекеләргә нәни генә хат язып сал. Тиздән күрешерсез, диген.

— Һи, апаем, хат кынамы соң? Анда чыккач, атпускыга кайтам бит мин! Мәскәвен, Казанын калдырмыйча үзем эзләп табарым, барысын бәйнә-бәйнә сөйләп биремен! Күр дә тор!. Җә, алайса, хуш!.. — Арыслан үзенең бетмәс-төкәнмәс шатлыгы белән уң кулын күтәреп, тагын да йөз кат хушлаша-хушлаша, чыгып китте.

Аш, чынлап та, суынып беткән иде. Шулай да аны Муса сыпырып куйды: тәмле тоелды, кәрбән генә салынган ит кисәге дә ачыккан кешегә бик ярады, Арыслан тырыштыргандыр инде. Менә бит, дус белән икенче тапкыр аерылышу көннәре дә килеп житте. Арыслан белән бергә булу һәрвакыт күңелле иде. Гүяки халыкның үз эчендә йөрисең, гүяки аның әйләнәсендә биш миллионлы татар халкы тора! Арысланның әтисе белән әнисе дә шундый булып хәтердә калганнар, исәннәр микән инде ул карткайлар?..

Ишек кактылар. Озын салынкы мыеклы Онисим Гуриевич үзе килеп керде. Ләкин аның артында тагын бер озын буйлы кеше бар иде. Тукта, ансы кем соң?.. Муса ишектән керүчегә карап-карап куйды да урыныннан сикереп торды:

— Габидуллин! — дип кычкырды ул. — Сөбхан алла, күземә күренәсең мәллә? Ничек? Каян?..

— Күренәм, Муса абый, күренәм, — дип көлде Габидуллин, басынкы тавыш белән. — Ә инде «ничек, каян» мәсьәләсе билгеле: сез узган юллардан... Биттә менә аю табаны хәтле генә печәте дә бар. Югалырлык түгел. — Габидуллинның күз почмагыннан авыз почмагына һәм колак читенә хәтле уң бите — яңагы янган иде. Ул урын тире өстеннән эчкәрәк батып, тартылып һәм ямьсез булып көеп тора иде. Сул битенә һәм маңгай өстенә дә ниндидер вак-вак кызыл җөйләр сибелгән. Габидуллинның очучы булганын белгән кешегә артык сорашасы да юк, күренеп тора: самолетында яна башлагач, җиргә сикергән егет һәм немец тылына туры килгән.

— Чорт возьми бу сугышны! — дип куйды Муса. — Кемнәрне генә кая ташламый да ничек кенә китереп очраштырмый! Кайда яттың соң син моңарчы?..

Шулай да алар истәлекләргә бирелми булдыра алмадылар. Габидуллин үзенең Муса белән күрешкәннән соң күп кенә сугышларда булуын, үз хатында Муса язган очеркны тәки укый алмавын әйтеп, үкенеп куйды. Дошман тылына мәтәлгәч, төнлә бер авылга кача-поса үрмәләп килеп, үзенең очучы киемнәрен бер хатын белән иске тун һәм олтанлы киез итекка алмашуларын, анда атна-ун көн буена дәваланып ятуын,

ә инде аннан чыгып киткәч, урман юлында немец засадасына эләгеп, балтырын умырып киткән пулядан егылып калуын һәм шунда алар кулына төшүен сөйләп бирде...

— Шуннан инде, йөртелә торгач, Седельцега килеп эләктем,— диде ул, сирәк тотлыгып сөйли-сөйли.— Сәндерәнең өченче катында, һичкем белән артык аралашмастан, качу юлын да таба алмастан, ачка үлеп ята идем, Гариф Шабаев дигән бер элек күз күргән кеше килеп чыкты. Сүкте үземне. «Ике аягың, ике кулың бармы?!.» диде. Шуннан инде сәндерәдән төштек тә монда килдек. Ул алып килде, һәм менә бу агайга тапшырды... — Габидуллин көлеп куйды. Аның әле уң ягындарак ике теше дә юк икән. Бу хәл көлгәндә бик шыксыз тәэсир калдыра иде. Моны күреп торган Муса Габидуллинны кызганып алды: нинди матур егет иде бит ул!..

— Ә мин аны, төпченебрәк сөйләшә торгачыннан, үземә комиссар иттем. Коммунист, майор, сугышның һәм әсирлекнең майлы буткасын җитәрлек ашаган, минемчә: подходящий, — дип сүзгә кереште Актабанов. — Ничек, Муса иптәш, Дүртенче комитет раслармы?

— Минемчә, раслар, — диде Муса. — Габидуллинны мин дә бераз беләм, яклармын. Иң мөһиме: үзе ничек сизә җаваплылыкны? Һәм фикердәшлегегез ничек?

— Шәп! — диде Онисим Гуриевич җанланып. — Пекер килешә. Инициативасы бар. Эшне йөртә белә.

— Алайса котлыйм! — диде Муса, Габидуллинның кулын кысып. — Кыен эшегездә уңыш телим сезгә, комиссар иптәш!.. Ә хәзер, дусларым, сөйләп бирегез: эшләрегез ничек тора сезнең?

Командир буларак, Актабанов сөйли башлады. Аның сүзенә караганда: батальон солдатларының җаны өчен каты көрәш барган. Фашист коткысына каршы — туган илгә мәхәббәт сүзе көрәшкән. Хәтта рәсми пропагандистлар да, мөмкин булган урында, үз сүзебезне кыстырып җибәргәннәр. Солдат күңеле үз иленә бер генә патрон да атмау ягында. Рота, взвод һәм бүлекчәләрдә немец командиры янына үз кешеләр куелган. Алар элекке офицер һәм сержантлар. Бары да диярлек комсомолец һәм коммунистлар. Бүлекчәнең кече командирлары взвод командирын белә. Взвод командиры рота командирын белә, рота командирлары Актабанов белән комиссарны белә. «Эш» башлану белән алар һәркайсы үз командирларына буйсынырга тиешләр. Санитарлар билгеле, медперсонал арасында да күбесе үз кешеләрдән. Хуҗалык командасының да немецтан башкасы безнең кешеләр икән.

— Яхшы, — диде Муса, ике терсәге белән дә түгәрәк өстәлгә таянган килеш. — Ә соң солдатта ялкын бармы?

— Фронтка җибәрелү көне якынайган саен солдат психологиясе тынгысызлык кичерә, — диде комиссар. — Хәзер аңа икенең берсен сайларга кирәк: туган илгә атамы ул, немецка атамы? Әгәр туган илгә атса — анда кайту юк. Ул мәңгегә шушы чит җирләрдә калып, моңарчы үзенә газиз булган барлык нәрсәләрдән мәхрүм булырга, ятлар илендә туфракка әйләнергә тиеш. Качса яки коралын немецка каршы борса — ничек булыр?.. Тотып, җәзалап, җанын алмасламы?.. Менә шул уйлар белән газаплана ул. Һәрхәлдә, солдат хәзер яр якасына килеп баскан. Аны тартып алырга да, этәреп төшерергә дә була. Шул актык чик тәвәккәллегенә җиткән солдатны без иң кирәкле моментта әйдәп китәргә тиеш булабыз.

— Әнә шул әйтеп китү мәсьәләгез ничегрәк тора? Оператив планыгыз бармы? Ничек башларга уйлыйсыз? — дип төпченде Муса.

— Без бу хакта комиссар белән күп уйлаштык, — дип җавап бирде подполковник. — Планыбыз да бар барын. Әмма ул конкрет түгел әле. Чөнки «эш»не кайчан һәм ничек башлап җибәрү андагы обстановкага бәйләнгән. Мәсәлән, кайсы юнәлешкә илтәрләр? Анда урманмы, дала-

мы? Поездан төшкәч күпме барабыз — җәяүме, автомашиналардамы, көндезме, төнләме? Боларның барысын да шунда барып төшкәч кенә исәпкә алып бетерергә мөмкин. Һәм конкрет план да окончательно шунда өлгерер...

— Батальонда күпме кеше бар? — дип сорады Муса. — Шулардан немец күпме? Коралыгыз нинди?

— Батальон зур. Мең ике йөз штык. Бу үзе — тулы канлы бер полк дигән сүз. Шулар өстенә, барысын бергә җыйганда, йөз туксан алты баш фриц бар,— дип көлемсерәде Актабанов.— Алар, әлбәттә, баштанаяк автомат кораллы. Ә безнең солдатларда рус винтовкасы, рус пулеметы гына. Шуңа күрә «эш» башлау моменты һаман да башны авырттыра әле.

— Сигналыгыз нәрсә?

— Ул да хәзергә ачык түгел, — диде Габидуллин уңайсызланыбрак.— Ракета чөюме, һавага яктырткыч пуля сиптерүме,— кайсы яхшырак булыр, әйтүе кыен...

Мусаның кәефе китә башлады.

— Юнәлеш турында белмисезме? Картагыз да юкмы? — дип сорады ул, тавышын үзгәртеп.

— Юнәлеш ачык булмагач, картаны ничек хәтерлисең? Әгәр безне ул тарафка җибәрмәсәләр?

— Мин гаҗәпләнебрәк калдым әле, Онисим Гуриевич, — диде Муса, тынычлыгы җуела баруын яшерергә тырышып. — Моннан бернечә сәгать элек, культвзводның таркалу хәбәрен ишеткәч, үкенгән идем мин, хәрәкәт үзәге югала дип курыктым. Ә инде сезне майор үзенә ординарец итеп алуын ишеткәч, сөенгән идем: димәкки, Краузены алыштырасы командир аның үз янында ук, һәрвакыт постка басарга әзер дип уйладым. Ә хәзер ничек килеп чыга? Соң сез денщик булып кына яшисезмени анда? Ә командирлык ролегез фәләнчә генәмени?..

Онисим Гуриевич аягүрә басты. Командиры алдындагы гади солдатча җаваплы сизә иде ул үзен.

— Алай ук борчылмыйчарак аңлашыйк әле, — диде ул, бик нык борчылып. — Минем колак һәм күзләр һәрвакыт Краузеда. Алар әле юнәлеш мәсьәләсен үзләре дә ачык белмиләр. Смоленск тарафына җибәрәләр икән дип утырды майор кичә Шпигельгә. Ә теге көлде: үзең командир, янәсе, үзең бернәрсә дә белмисең. Безнең азиатларны Ковпак партизаннарына каршы җибәрәләр. Карпатка хәтле барып йөри торган шундый бер атаман бар икән. Ә инде андагы регуляр частьларны Курск ягына озаталар, анда фюрер Шталинград өчен реванш алырга җыена... Менә шуларны ишеткәч, үзебезнең штаб писаре Шәмсетдиновка шул тирәләрнең картасын кул астындарак тотарга куштым, майорга кирәк булуы бар, дидем. Шуннан ул үзе аңлый. — Актабанов, бераз җанланып, озын мыегын сыпырып куйды. — Карта мәсьәләсе төп проблема түгел, — дип дәвам итте ул. — Краузеның планшеты миңа күчәчәк... Ә менә сигнал мәсьәләсе катлаулырак. Көтмәгәндә ракета чөелсә яки һавага яктырткыч пулялар сиптерелсә, немец сискәнеп, шунда ук автоматына ябышачак. Бу ярамый. Без «эш»не башлап җиппәрмичә сизмәсен. Бер минутка булса да внезапность көче кирәк. Шул көч аларны паникага ыргытачак.

— Һәм дөрес тә, — диде Габидуллин. — Андый чакта бер минутның көче бик зур. Көтелмәгән бер минутта — биш самолетны егарга була!..

Муса да бу хакта күптән уйлап утыра иде инде. Габидуллин дә шуңа килеп терәлгәч, бу ике солдатның өмете үзендә булуын тагын да ачыграк аңлап алды ул. Кызык бит: элек кешеләрне ничәмә сугышларга алып кергән бу ике командир, хәзер шул ук эшне, дошман белән каракаршы түгел — янәшә баскан хәлдә, аңа тойдырмастан башлап җибәрү мәсьәләсе кузгалгач, гомерендә берәүне дә сугышка алып кермәгән, ә

фәкать җыр кочагына, поэма киңлегенә генә алып кергән шагыйрьдән ярдәм көтәләр. Әмма шагыйрь каян тапсын соң? Ул бит хәрби командир түгел...

— Сыбызгы турында уйлаганыгыз юкмы? — дип сорады Муса. — Әйтик, көтүче курае сыман гади бер нәрсә...

Актабанов елмаеп куйды. Нократ буйларында ат көткән чакта кара курайдан шундый сыбызгы ясаганы бар иде аның. Баш башына бөке тыгып, берничә тишек ясап сызгырта башлагач, көй килеп чыкты! Гади бер көпшә эчендә музыка ятуына шаккаткан иде үсмер Үничим. Шул курайны уйнатып, атларны бер табынга җыелырга өйрәткән иде ул хәтта!.. Ә менә хәзер шуның моңсу авазлары белән кешеләрне яуга күтәрә алсаң — нинди шәп булыр иде!

Шулай ук елмаю белән Мусага җавап бирде ул:

— Курай әллә ярап куяр иде... Ясаган бар, кулдан килә...

— Әгәр «эш» башлау көн яктысында булса, сыбызгыга мин дә кушылам, — диде Габидуллин. — Төнлә туры килсә, немецлар бу сызгыртудан тиз сагаерлар: партизаннар түгелме, янәсе. Төнлә булганда, команданы сүз белән генә тапшыру ничек булыр икән? Әйтик, сез, иптәш Актабанов, нәкъ урны һәм вакыты килеп җиткәч, «Башларга!» дип, җилкә аша гына татарча сүз тапшырасыз. Мин аны артымдагы үз командирга тапшырам һәм шулай строй буйлап китә. Бер минуттан һәркем белеп ала. Моның өчен колоннаның бер кырыена иң ышанычлы кешеләр куелыр. Солдатның да актив өлешенә бу сүзнең мәгънәсен алдан аңлатырбыз...

— Менә ич! — дип куйды Муса, куанычтан кулын шапылдатып. — Иң мөһиме шул: уңышлы башлап җибәрү. Эшне уңышлы башлый алсагыз, эз югалту белән тәмамларсыз һәм юлыгызга имин китеп барырсыз.

— Без әле эш башлауны тагын күп тапкыр уйларбыз, — диде подполковник. — Безнең хәзер көн-төн уйлыйсы мәсьәләбез шул гына. Бөтен язмыш шуңа бәйләнгән.

— Ә солдатларның максат белән танышлыгы ничек? Алар арасында шымчылар юкмы?

— Солдатның дүрттән бере яхшы сыналган һәм аларга мәсьәлә аңлатылган, — дип җавап бирде Габидуллин. — Листовкалар да күп нәрсә аңлатты, аларны солдат илдән килгән хат шикелле итеп укыды. Агитаторлар юлда тагын ике өлешенә аңлатачаклар. Барысына да монда ук туп-туры әйтсәң, тегендә рикошет белән маңгайга суктыруы мөмкин, үзегез беләсез. Шымчылар булуы ачык беленми. Элегрәк ике арада буталып, шыңгырап йөрүчеләр, коткы салучылар сизелгәли иде. Без аларны берәм-берәм, сиздермәстән генә, тимер юл саклаучы, урман кисүче командалар арасына җибәреп бетердек. Һәм моның ярдәме бик тиде...

— Ә нинди коткы салалар иде алар? — дип сорады Муса.

— «Безгә туган илгә кайту юк инде. Анда һәрбер әсирне җинаятьче саныйлар. Ә легион солдатын — бигрәк тә... Анда кайтсак, уныбызга бер пуля безнең...» — дип, шыңшый иде алар. Ә бу, чынлап та, иң нечкә урын бит безнең, — дип, башын чайкап куйды Габидуллин. — Хәтерлисездер, безнең анда, дөрестән дә, шундыйрак караш бар бит. Мәсәлән, без үзебез дә шулайрак уйлый идек түгелме?

— Уйлый идек шул, — дип, тирән сулап куйды Муса. — Җиңелрәк акыллы идек, дөрес... Ә хакыйкать бөтенләй башкача икән...

— Белмим, иске солдат булгангамы, андый сүзгә ышанмый идем мин, — диде Актабанов. — Ник дисәң, бер генә сугыш та пленсыз булмый. Бу минем өченче сугышта катнашуым. Әр кайсында да әр тараftан да әсир күп булды. Минемчә, үзе сугышның ни икәнен күрмәгән, йомшак креслода гына утырган кешенең карашы ул. Дөрес, вак җанлы

сволочьлар да очрый очравын, әмма миллионнарча солдат бервакытта да хыянәтче булмый.

— Без менә теге шыңгыравыкларны тазарткач, солдатка шул фикерне аңлаттык та инде, — дип өстәде комиссар.

— Туган җирләргә исән кайтсак, акыллырак булыр идек инде, — дип куйды Муса.— Без һәр адымыбызда артык дәрәҗәдә «кызыл», чәчрәп торган ортодокс дип әйтимме, ниндидер шундый «ультра революцион» куыклар булып кылангаладык шул. Ә андый куыклар тиз шартлый икән. Волхов фронтында чакта шундый берәүне белә идем мин. «Смерш»та эшли иде. Көн-төн солдат арасында чабып, күзләренең агы белән генә карап, шпион һәм хыянәтче эзли иде. Ә беренче куркыныч килү белән, яшереп тә тормыйча, партбилетын ертып, якасындагы кубикларын өзеп, сазга ыргытты да кулларын күтәреп немецка качты. Ә ул шикләнгән гади солдат, камалышта калганнан соң да, ай ярым буена сугышып йөрде... Һәр төрлесен күрдек инде, дускайлар. Тик яңадан шундыйлар хөкеме астында калмасак кына иде.

— Дөрес, — диде Габидуллин, моңа кушылып. — Алар безнең дә җелеккә тияр әле кайткач...

— Ярый, дуслар, хисләргә бирелеп киттек, — дип көлде Муса. — Алары соңыннан инде. Сугыш беткәч, җиңгәч! Ә хәзер — хәрәкәткә! Әгәр бүтән мәсьәләләр булмаса, шушында төгәллик. Хәерле юл телим сезгә! Уңышлы башлагыз, уңышлы тәмам итегез!

— Амин! — диде комиссар.

— Амин! — дип көлде Актабанов. — Кайчан да ярый тагын бу сүз.

— Эх, кызыгам сезгә! Үзем дә китәргә кызыгам, — диде Муса, моңая төшеп.

— Ник, әйдәгез!

— Ярамый. Калганнар язмышы бар ич... Без озакламабыз...

Ишек ярыгыннан Арыслан тавышы килде. (Мондый чакта үзе белеп сакка куя иде ул үзен.)

— Габидуллинны рота командиры эзләтә!..

— Хәзер! — дип кычкырды ул. — Ярый, Муса абый, хуш. — Исәнлектә күрешик!.. — Аның тавышы сынып китте, тамак төбенә нидер утырды. Һәм ул, башка бер сүз дә әйтә алмастан, җәһәт кенә чыгып китте...

— Хуш, Онисим Гурич, — диде Муса. — Сез дә ашыгыгыз, я теге кайтып килер... Мин инде сез киткәндә яулык селкеп кала алмам... Үзегезгә мәгълүм... Әмма үзегезне саклагыз. Сездән башка солдат нишләр? Охранагыз бармы?

— Ул хакта уйлаган юк, ник дисәң, үзем немецның охранасы бит мин, — дип көлде подполковник. — Денщикның сакчысы буламыни?

— Биш кеше билгеләгез. Әлбәттә, иң активлардан. Һәм алдан ук әйтеп куегыз, — диде Муса, җитди төс белән. — Уен эш түгел!

Актабанов аны, күтәрә төшеп, кочаклап үпте.

— Хуш, дустым, син дә нык сакла үзеңне! — Бу юлы ул солдатча житез борылмады. Аерыласы килмәгән кебек, ниндидер салпы адымнар белән генә ишектән атлады.

## II

Гайнан Кормашев, Демблиннан батальонга килеп, җыр-музыка авазы ишетә башлагач, яңадан терелеп китте. Кайчандыр күптән күрелгән төш шикелле, канатлы яшьлеге юри генә кабатлана сыман тоелды аңа. Ул педагогия техникумыннан укытучы булып чыкса да, аның бөтен мавыккан нәрсәсе, бөтен гыйшкы, бөтен хыялланганы сүз сәнгате иде. Мари республикасындагы Бәрәңге татар техникумында чакта сәхнәгә чыгып Тукай, Такташ шигырьләрен уку, иптәшләре куя торган һәвәскәр

спектакльләрдә берәр роль уйнау аның өчен иң зур бәхет иде. Өлкән курсларга табарак бу үсмер егетләр, әдәбият түгәрәге оештырып, анда үз шигырьләрен укый башладылар. Малайлар «шагыйрь!» дип көлсә дә, «сүндер инде утны!» дип ачуланса да, төн буе шигырь яза иде ул. Аның кесәсе саен урталай бөкләнгән шигырь дәфтәре булмыйча калмый, ә кайчакта шундый ук дәфтәр итек кунычында да йөргәли иде. Аларның җитәкчесе — өлкән курстагы Мансур Гаяз дигән егет. Ул инде танылып килә, аның шигырьләре хәтта Казанда да басылгалый. Әмма шулай да үзе бер дә мактанчык түгел, бик кече күңелле бер кеше!.. Шулай канатланып йөргәндә генә узды да китте ул чаклар. Техникумны тәмамлап, таралышып та беттеләр. Гайнан Актүбә каласына килеп, җидееллык мәктәптә укыта башлады, аннары завуч һәм шул мәктәпнең директоры да булып китте. Казан педагогия институтында читтән торып укучы булды, тик алай да аның әллә никадәр вакыты кала иде. Актүбә татар клубында үзешчән сәнгать түгәрәге төзеде, җитәкчесе булып спектакльләр куйды, ә төннәрен һаман шигырьләр һәм пьесалар язды. Пьеса язмый хәле юк шул, чөнки сәхнәдә уйнарга әсәр җитми. Казан язучыларын көтеп ятып буламы? Җитмәсә, утыз җиденче еллар бит әле ул. Аларның кайсы исән дә, кайсы «кунакка» киткән,— каян беләсең?.. Гайнан җәй саен калын бер дәфтәр шигырь кыстырып, Казанга заочный сессиягә килә һәм үз әйберләрен күрсәтү өчен «чын шагыйрь» эзләп китә иде. Ләкин барган саен бер үк «кәтүк консультант»ка туры килә, ә ул әз генә «сәрхуш» күңелле була һәм, өстәл артыннан шыңгыравык борынын гына күрсәтеп, бер үк төрле җавапны шыңгырата бирә иде: «Шигырьләрегез батардай түгел, энем!»

Соңгы баруында гына Гайнан Тукай клубындагы ул пыяла ишекне читләтеп узды да икенче бер бүлмәгә кагылды. Анда утырган кеше үзен «Муса Җәлил» диде. А-а, менә бу «чын шагыйрь» инде! Гайнан аның күпме шигырь һәм поэмаларын укыганы, сәхнәдән сөйләгәне бар!

Яшь егетнең Актүбә хәтле ерак җирдән килгәнен белгәч, Муса аның калын дәфтәрен үзенә алып калды. Өч көннән керергә кушкан иде, ләкин Гайнан, зачетлары күп булу һәм күренергә куркып йөрү сәбәпле, алтынчы көнне генә керде. Курыкмаслык та түгел: ул кеше бит Язучылар союзының җаваплы җитәкчесе икән! Ә Гайнан аңа үзенең шул хәтле язмаларын китереп тоттырды. Аның болай да эше муеннандыр!.. Шулай да караңгы чырай күрсәтмәде тагы. Инде алты көннән соң кергәч, Гайнанга үзе үк кул сузып күрешеп, кара диванга утыртты, үзе дә аның янына килеп утырды. Иң элек: «Бик күп язасың икән, дәфтәреңнең авырлыгын кара әле!» дип, аны учында үлчәгәндәй итеп көлде. Аннары әз генә мактаган булды, кайбер шигырьләрнең кайбер уңышлырак юлларын күрсәтеп, әз генә өмет бирде, аннары кеше фикерләрен, тоймастан кабатланылган кеше юлларын китереп, нечкә генә чеметкәләп алды. Кыскасы, сөендерде дә, көендерде дә һәм канат та куеп, чыгарып җибәрде.

Шул көннән башлап «чын шагыйрь» булу хыялында исереп йөргәндә генә, армиягә алып куйдылар. Ә солдат тормышы майлы бутка түгел инде ул. Аяк белән йөрүгә караганда, түш белән күбрәк йөрергә кушалар анда. Шулай да алты айдан сержант булып, ел ярым дигәндә кече лейтенант исеме алып, калганнарны үзе өйрәтә башлады ул. Шуның өстенә полкның үзешчән спектакльләрендә катнашырга да вакыт табыла. Иске офицерлар ролен уйнарга кирәк булса, һәрвакыт аны кушалар. Моның өчен аның ирләрчә матур һәм аксыл чырайлы төс-бите, килбәтле буй-сыны килешеп үк тора иде. Үз гомерендә кинодан башка беркайда да күрмәгән иске офицерны, чыннан да, бик ябыштырып уйный иде ул. Эх, кайда ул бәхетле чаклар хәзер!..

Эт чыдамас ничәмә этаплар аша килеп егылган Демблинда җаны белән дә, тәне белән дә үлеп бара иде инде Кормаш. Юк, андый исем

эллә кайчан онытылган, ул бары тик «№ 93891078» генә иде хәзер. Муенына җеп белән асылган шул калай жетонны кулына тота да:

— Әби патша салдырган шушы калын һәм биек стеналы, шайтанның үзе дә кача алмаслык таш крепость синең мәңгелек йортың, «җылы» каберең, «якты оҗмахың» булачак инде, иптәш, номер фәлән-фәлән!» — дип, үз-үзенә ясыйн укый иде ул. Ә мондый сөйләнүләрнең ни белән тәмамланасы билгеле иде... Нәкъ менә шундый чакта Муса Җәлил килеп чыкты, йөрәгенә җылы салды, сер салды һәм, теге вакытта Казандагы шикелле, кечтеки генә өмет шәме кабызып китте. Ул шәм яктысына да пычрак сулар кичеп, тигәнәкле юллар узып барырга икән әле. Булсын! Шулай да «номер фәлән-фәлән» дигән җан иясе үз исеменә кайтты хәзер. Аңа «Гайнан дус» дип эндәштеләр. Һәм тетрәнеп уянып киткән Гайнан шагыйрь күрсәткән шул шәм яктысына үлем аша барырга да әзер икәнлеген аңлап алды. Менә бит нинди кешеләр бар: башкаларны уятып йөриләр! Ә Гайнан, кабыргасына китереп төртмичә, үз-үзен дә уята белмәде. Хәер, яшь шул, яшел шул әле ул, Лаеш шулпасын бер дә эчмәгән булган. Ә дөньяда кешеләрнең шулай берберен уятып, фикердәш булып, акыл һәм тәҗрибә бирешеп яшәүләре бик яхшы икән. Шунсыз җирдә яшәү дә, көрәшү дә, җиңү дә мөмкин булмас иде. Гайнан да, күзләре ачылу белән, үз иптәшләреннән унөч кешене ияртеп, легионга алып килде. Һәм алар немец биргән «ирек»тән файдаланып, кайнар эшкә тотындылар, күңелләрендә яңадан дәрт кабынды. Инде өметсезлек томаннарына күмелеп, күңел күзеннән бөтенләй югала барган сөекле Дания образы да яңадан яктыга чыгып, аңа елмая башлады. «Көрәшү мөмкин!» дигән өмет яңадан терелде. Әүвәлгечә үк дәрт һәм ялкын белән Такташның «Алсу»ын, «Мәхәббәт тәүбәсе»н укыганда, легион солдатлары белән бергә аның каршында гүяки Даниясе дә басып тора иде. Хәтта ул аңа багышлап, аның образын да кертеп, сәхнә әсәре язды. Мондагы солдатның күңелен күтәрер өчен генә түгел, үзенең дә кайтыр юлларын шуның белән билгеләргә теләде ул...

Гайнан Кормаш шулай озак уйланып, үткәннәрен яңадан кичереп утырды. Батальон клубының сәхнә артында кечкенә генә фанер бүлмә бар. Шунда кереп, ялгыз гына эшләп утыруы бик рәхәт, бик тыныч була. Бүген дә ул, шушы хөҗрәгә бикләнеп, Муса килеп җиткәнче пьесасын тагын бер кат карап чыгарга теләгән иде, әмма булмады, канатлы аттай ярсу уйлары, әнә кайлардан әйләндереп, аны яңадан сөекле Даниясе янына алып китте! Һәм Гайнан, әсәр төзәтү шикелле күңелсез эшне бөтенләй онытып, дәфтәр тышына карандаш белән Дания рәсемен ясап утырды. Җитмәсә, бик охшаган шикелле булып чыкты! Аннары, шул ук карандашның икенче башын чәйни-чәйни, рәсем астына дүрт юл шигырь дә язып куйды:

Зәңгәр күзләреңне юлга текәп
Көтмә әле, Даниям, матурым.
Халык өчен көрәш мәйданында,
Ут эчендә синең батырың...

Язуын язды, әле көтмәскә кушты, әмма үзе, әгәр мөмкин булса, дөньяның иң шәп самолетларыннан да җитезрәк тылсымлы канат белән очып, Даниясе янына шушы минутта ук кайтып төшәр иде ул!..

Культвзвод командиры Рушатов белән Муса килеп керде. Муса аны әдәбият-сәнгатькә кагылышлы һәр эш белән таныштыра бара иде. Чөнки сугышка кадәр ерак Кыргызстанда ветврач булган бу кешенең сәнгать өлкәсендәге барлык мәгълүматы буш чакларында мандолин чиртkәләүдән генә гыйбарәт иде. Кара язмыштан котылу теләге монда китереп, культвзвод житәкчесе иткәч, ул «белем» генә җитмәве күренде. Яшькелт-соры күзләре акыллы караш ташлаган бу олы гәүдәле, әз сүз-

ле кешенең сабыр табигатьле булуы Мусага охшый һәм ул аңа, партиясез дип тормыйча, ышанып карый иде. Ул аны бик күп яңа көйләргә, яңа җырларга өйрәтте. Композиторлар һәм шагыйрьләр дөньясын ачты. Элек шигырьне укый да белмәгән Рушатов Муса аркылы шигырьнең чын тәмен, образлар тирәнлеген аңлый башлады. Шулай итеп ул хәзер шактый ук сәнгать кешесе булып китте. Кормашның сәхнә әсәрен дә Муса килгәнче үк укып чыккан иде инде ул. Һәм алар аны автор белән икәүләп штабтагы немецча машинкада ике данә басып та алдылар. Мусага да укыр өчен җиңеләйде.

Гайнан үз әсәренә хөкем каты булыр дип курыккан иде, ләкин «бәйләнүләр» әллә ни булмады. Хәтта киресенчә, Муса бу яшь егеттән киләчәктә яхшы драматург чыгачагын сизеп алды. Әсәрне сәхнәгә куярга тәкъдим итте. Чөнки андагы образлар солдат күңелендә илгә мәхәббәт көчәйтәчәк. Ә Дания исемле кыз аеруча җылы һәм ягымлы итеп сурәтләнгән иде.

Клубка «артистлар» җыела башлады. Алар арасында профессионал артист бары тик Борис кына булса да, немец штабындагы исемлектә һәркайсы: «фәлән театрдан», «фәлән филармониядән», «фәлән ансамбльдән» дип язылган иде. Электән таныш булганнары Муса Гумеров белән үзләре килеп күреште. Теге вакытта беренче батальонда концерт куешкан башкорт егете арыслан тавышлы Кыекбаев та, «Пар ат»ны сөйләгән укытучы да һәм тагын башкалары да бире җибәрелгән икән. Калганнар белән Кормаш һәм Рушатов таныштырды.

— Менә бу безнең Казан филармониясе җырчысы Фәхри Димски,— диде Гайнан. — Тавышы бик шәп, хәтфә баритон!

Муса каршына таррак җилкәле, буйчан гәүдәле, кабарынкы куе чәчле, әз генә дугаланып торган кара кашлары астыннан караучы кара җете күзле, юка, йомшак иренле һәм озынча йөзле бер егет килеп, кул бирде.

— Бәй, — дип куйды Муса, кинәт башкортча. — Мин бу егетне Демблинда күрдем түгелме соң? Нигә ул чакта әйтмәдегез? Кайсы елларны эшләдегез Казанда? Нишләп мин хәтерләмим соң сезне?..

— Мин, абый... — дип көлемсерәде егет, — туганнан бирле булганым да юк Казанда... Филармония дигән сүзне дә белми идем, менә болар бит... — Ул Кормашка таба ымлады да башкалар көлешкән арада читкә китеп барды.

— Безнең шагыйрьләр дә күп монда, бер Кормаш кына түгел, — диде Рушатов. — Әнә килә тагын берсе. Сез аны әле белмисездер. Зиннәт, кил әле бирегә!

Алар янына спортчыларча таза тыгыз гәүдәле, урта буйлы, үлем лагерьлары да йөзенә сары коя алмаган түгәрәк битле, урта яшьләрдәге бер кеше килеп басты.

— Бу безнең шагыйребез Зиннәт Хәсәнов, таныш булыгыз.

Муса бу юлы да гаҗәпләнеп калды. Аны да бер күргән иде бит ул. Әллә шаярталармы болар?.. Шулай да җитди төс белән кул биреп:

— Кайларда басылдыгыз? — дип сорады.

— Мыскыл итәләр! — диде Зиннәт.— Олы җәһәннәмнән фашист оҗмахына чыккан чакта менә шундый тамга суктылар. Эмтыес механиге мин. Армиядә лейтенант... — Соңгы сүзләрен тавышын әкренәйтеп һәм як-ягына каранып әйтте ул. — Менә монда шигырь укыйбыз инде хәзер...

Габдулла Батталов, аксаклап килеп, үзе күреште.

— Мин дә шаирь әлдә мында, алар гына түгел, — диде ул, Биләр мишәрләречә. — Мине янтайтмасыннар, Муся кәбәм.

Муса аны кочаклап алды.

— Беләм инде мин сине, иске дус бит, — дип көлде ул. — Әйдә, сугыштан соң Казанда китабыңны чыгарырбыз.

— Юк, кәбәм, — диде Габдулла кырт кисеп кенә. — Мин хәзер фокусник. Кайткач шыл хакта китап язам. Нинди фокуслар дисеңме? Һич канятым, чуты юк. Например, җепне борыннан тыгып җибәрәм, авыздан тартып алам. Энәне бер битемнән кертсәм, икенчесеннән чыгарам. Шытырдатып лампа куыгы ашыйм. Һәй, лампа куыгы гынамы? Пешереп китерсәләр, бер чокыр шурпа белән бер бозауны ашап бетерәм. Әмма китермиләр генә, каһәр. Үзем кәлимә булсам да, сәхнәдә тәгәрмәч булып тыгыри алам, энә күзеннән дөя кичерәм, этнең һәртөрлесе булып өрә беләм, тик менә фүрир булып өрә генә белмим дә, кеше аса белмим.

— Ансы өчен үкенмисеңдер ич?

— Үкенеп тә куям, — дип көлде Баттал. — Әҗәтне түләргә туры килүе мөмкин ведь...

Репетиция башларга вакыт җиткән иде. Гайнан аларны залга алып чыкты. Иң алдан Габдулла аксаклап атлады. Ул монда «артист»лыктан тыш, Берлиннан газета-журналлар ташучы булып та эшли иде.

— Безнең Сәлих хакында цуп тә белмимсең? — дип сорады ул, артына борылып. — Мин аны фронтка киткәндә дә күрә алмый калдым.

— Юк шул, — диде Муса. — Ул бит Ерак Көнчыгышта иде. Бу якка күчергәннәре ишетелмәде...

— Сез репетицияне карыйсызмы, Муса абый? — диде Гайнан, аларның сүзен бүлдереп. — Безнең хәзер башларга исәп бар.

— Ярый, башлагыз, — диде Муса. — Мин генеральныен гына карармын, йөрисе җирләрем дә бар...

— Алайса... — диде егет, мәгънәле пауза белән. — Урман. Су ясы. Чишмә... Карап кайтыгыз, матур урыннар... Кешеләргә әйтелгән... — Һәм борылып китеп тә барды.

Муса шул «матур урыннар»га юнәлде. Клубтан чыгып сулга борылгач та, штабны узу белән, урман башлана иде. Ул, Берлиндагы бомба газларыннан соң, мондагы тыныч саф һавага гашыйк булган кешедәй, бәхетле бер кыяфәт белән пинжәген җилкәсенә салган килеш, җилбер-җилбер атлап, ялангач башындагы җил тузгыткан чәчләрен уңайга сыпыргалап, урман эченә атлады. Ары табарак кечкенә генә инеш күренде.

Чишмә үз җырын ишеттерергә ашыкты. Кайдадыр күзгә күренми торган биектәге тургай тавышы сыман иде ул. Муса шул чакыручан тавышка таба борылды. Әнә кайда икән: өстенә юан нарат үскән комлы ташлар арасыннан чылтерәп яткан була икән. Аның суы чаптырып аксын өчен бәләкәй генә улак та куйганнар. Муса кызыгып китте, бик тәмледер шикелле тоелды бу чишмәнең суы. Һәм ул җилкәсендәге пинжәген нарат төбенә ташлады да, улакка каршы басып, чишмә суын куш учлап эчә башлады. Тешләрне сындырырлык салкын су аның үнәчен яндырып төшкәндәй булды һәм каннарына йөгерде. Аннары шул ук боздай суны куш учлап битләренә сибәргә тотынды, муен һәм ачык күкрәкләрен чылатты, беләкләрен юды. Тагын кат-кат битләренә сибеп, иреннәрен бырылдата-бырылдата, малайлар шикелле шаярып, пошкыргалап куйды. Аңа монда бик ваемсыз кешедәй кыланырга кирәк иде: алай-болай чит күзләр сагаласа, гамьсезлеге әллә кайдан күренеп торсын!..

Муса, кесә яулыгы белән битләрен, муеннарын сөрткәләп, нарат төбенә утырды. Куен кесәсендәге хәтер дәфтәрен алып, нәни генә сызыклар белән чишмәнең рәсемен ясады. Астына: «Сандугач һәм чишмә» өчен... дип язып куйды. Шагыйрь күңеле бит...

Кемнеңдер тамак кырган тавышы ишетелде. Муса борылып карады: арт якта Фоат Сәйфелмөлеков басып тора иде. Ул, читтән үк әйләнеп, урман куелыгы аша килеп чыккан булса кирәк.

— Әйдүк, Фоат дус, — диде Муса, аны чакырып. — Якын кил, утыр.

Сәйфелмөлеков, кыюсыз гына килеп, ылыслы үлән өстенә утырды. Аның киң түгәрәк битләренә, йомры башына һәм тәбәнәк итләч гәүдәсенә немец формасы бер дә килешми, әллә ничек сәдәпләре өзелердәй тар, курач булып күренә иде. Бигрәк тә, аның баш очына гына эләгеп торган бәләкәй картузы, олы чәйник өстендәге кечтеки генә капкач шикелле, мәзәк булып күренде Мусага. Сөйләшә торгач, аның Сәмарканд университетын тәмамлап, Үзбәкстан сәүдә наркоматында экономист булып эшләгәне аңлашылды. Кормашлар аны үзләре белән Демблиннан алып чыкканнар. Ләкин һич кенә дә артистлык һөнәре юк икән егетнең, хәтта кубыз да уйный белми, сәхнә уены юк та юк инде!

— Бөтен кеше дә артист булып бетми, — диде Муса. — Безгә башка кешеләр дә кирәк. Син батальонның штатный пропагандисты булырсың, Фоат.

— Ничек? Фашист пропагандистымы? Мин партия әгъзасы бит!— Аның бастырынкы тавышында ук калтырану сизелә иде.

— Син бик куркак кеше мәллә, дускай? — дип сорады Муса, кинәт кенә аның күзләренә туп-туры карап.

— Ничек дип әйтим... Куяннан да котсыз түгел идем шикелле... Ләкин бу бит — дошман коткысы сөйләү! Авызың ничек ачылсын аңа?.. Эх, артист булсаң! Чыгып бер җырлаган булдың, я биедең, һәм — эшең бетте! Ә монда фашист пропагандисты бул!

— Менә шунда шул хикмәт, — диде Муса, имән бармагын күрсәтеп.— Син партия әгъзасы булганга һәм югары белемеңә күрә сине Зикендорф әфәнде раслаган рәсми пропагандист итеп билгелибез. Еланның агуын алып ташларсың да кеше үтерми торган кабыгы белән генә дарударсың. Ә кирәк урыннарда ул агуны нечкә шприц белән дошманның үзенә җибәрерсең.

— Шулай да, барыбер фашист куйган рәсми пропагандист инде... Солдат мине шулай кабул итәчәк, — дип борчылды Сәйфелмөлеков. — Чөнки нәҗеснең кырыена бастың ни дә, уртасына бастың ни? Барыбер пычранасың. Ә минем гаиләм бар, балаларым бар. Минем шундый булуымны ишеткәч, алар нәрсә әйтер?

— Эх, дускай! — диде Муса, әрләү тавышы беләнрәк. — Минем юкмыни? Башкаларның юкмыни? Алайга калса, барыбызга да тик кенә ятырга кирәк, ходайның фирештәләре коткарганны көтеп. Бәлки мин ялгышамдыр?.. Бәлки син, чыннан да, куркасыңдыр?..

— Икенче тапкыр әйтәсез инде шул яман сүзне, — диде егет җәберсенеп. — Алайса, белегез: «Куян булып күренсәм дә, арысланга атланам!» — дип әйткән ди бер үзбәк. Ихтимал, мин дә әле бөтенләй юкка чыкканнардан түгелмен! Эшлисем килә һәм эшләрмен, кушыгыз! — Тәвәккәл чалымлы иреннәрен кысып, нарат кайрысына йодрыгы белән сугып куйды ул.

— Менә күптән шулай кирәк иде! — дип көлде Муса канәгатьләнеп. — Икеле-микеле — сукыр тәкә шикелле, дип әйткәндәй булса, әйбәт түгел бит, туган. Безнең якты йөз белән кайту юлыбыз шушы!

— Әйе, Муса абый, башкача юл бикле безгә... — диде Фоат, җитди төс белән. — Әмма, мондый зур эшкә тотынганда, эчеңдәгене әйтмичә, иптәшең белән киңәшләшмичә булмый.

— Әлбәттә, эчтә төен калмау яхшы, — дип җөпләде Муса, аның сүзен. — Эшең, чыннан да, җитди синең. Башка бүлекчәләргә дә йөреп лекцияләр укырсың. Алдан ук язып, гыйльми нигезгә корып хәзерлә. Андый чакта Эзоп теле бик файда итәчәк.

— Эзоп теле?

— Әйе. Эзоп белән безнең язмышларда да шактый уртаклык бар: ул — коллыктан ireккә җибәрелгән шикелле, безне Гитлер абзаң, аякларга озын җеп бәйләп, үз коллыгыннан иреккә чыгарды бит. Эзоп та үз фикерләрен ачыктан-ачык әйтә алмый торган «ирекле» мәсәлче

булган, без дә үз сүзебезне әйтә алмаучы «азат» кешеләр. Шуңар күрә Эзоп читләтеп сuктыруны, кыек атып туры тидерүне уйлап тапкан. Безгә дә төп фикеребезне кай урында мамыкка төреп, кайчак төрле битлек кидереп әйтү һәм солдатка җиткерү кирәк. Безнең кешеләр акылсыз түгел, төшенерләр...

— Улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла! булып чыга инде алайса? — дип көлде Фоат.

— Нәкъ үзе! — диде Муса. — Җае килгәндә шундыйрак мәкальләрне дә кыстыргалап җибәр. «Колак белән тыңла, башың белән уйла» дигән сүз дә бар бугай. Тизрәк төшенерлек булсын.

— Ярый алайса, Муса абый, уңыш теләгез миңа! — диде Фоат урыныннан торып. — Мин әле чиркәнчек алмаган бит. Шуңар күрә, чумарга куркып, яр буенда торган кеше төслерәк...

Фоат шуның белән китмәкче булган иде. Ләкин, үзләренә таба килгән Мичуринны күреп, каушабрак калды. «Безне монда күрүләре яхшы түгел инде...» дип уйлады ул. Ә Мичурин, нәкъ шуңа басым ясаган шикелле күзләрен кыскалап, әйтә салды:

— Менә кайда заговор корып яталар икән болар! Җәһәннәм машинасы кайсыгызда?..

Какча гәүдәле, урта буйлы, кылыч борынлырак бу кеше шактый кыю күренә һәм үзен иркен тота иде. Моңарчы да Муса белән очрашканы бардыр, күрәсең.

Сәйфелмөлеков тагын китмәкче булды. Әмма бу юлы аны Муса туктатты, әз генә сабыр итәргә кушты, үзе Мичуринны сөйләштерергә кереште.

— Я, син ниләр бетерәсең?

— Мин Англо-Америка плутократиясенең сакалын йолкырга уйлыйм, — дип башлады Гали. — Чистый тетмәләрен тетеп салырга исәп бар, тел дә кычытып тора, ачу да килә икенче фронт өчен...

— Кирәк аларга, кирәк, — дип көлде Муса. — Сыртларын каезламыйча уянмаслар, ахры.

— Ачу килмәслек тә түгел, — дип сукранды Мичурин. — Һаман икенче фронтны ачмыйлар. Пропаганда дәресендә болай дип әйтергә исәп бар әле: «Фүрирнең данлы гаскәрләре Сталинград шәһәренә барып җитеп, бөек Идел-ананың бугазына ябыштылар. Һаман бер ялгызы сугышкан Совет иле өчен иң авыр куркыныч көннәр килде. Ә теге плутократлар, сигара тартып, тыныч кына карап тордылар. Әмма инде, кайчан да кем, авыр кузгала торган урыс аюы җиңел сикерә торган немец пантерасын Идел буенда әйләндереп салган иде (вакытлыча гына, әлбәттә), менә тегеләр кул чаба башладылар. Бөтен дөньяда «Сталинград та Сталинград!» дигән алкыш китте. Американски сенаторлар, английски лордлар совет солдатын мактаудан туктамас булды. Әйтерсең лә, үзләре җиңеп чыкканнар! Кеше кулы белән утлы күмер чүпләү, кеше яккан утта кызыну — менә шул була инде ул! Безнең фүрир исән булса, кирәкләрен бирер әле аларның!..»

— Ярый бу, — диде Муса көлемсерәп. — Монда эзопчылык бар әзрәк. Рәсми пропаганда сүзе чүбек чәйнәү төслерәк булырга тиеш. Җае килгәндә шул чүбек арасына чын сүз кыстыргалау да ярый. Ә яшерен рәвештә, солдат белән бергә-бер калып, үз сүзебезне таратыгыз. Иң яхшы агитатор — сводка хәзер, безнекеләр һаман болай таба килә.

— Ул эшне дә рәткә салабыз, — диде Гали Мичурин. — Батальонның элемтә взводында радист булып безнең егет эшли.

— Сез, рәсми пропагандистлар, ничә кеше соң? — дип сорады Муса.

— Ун кеше, — диде Фоат. — Шулардан Гали белән без генә бу якта. Ә калганнар безнең йогынтыда түгел...

— Нindирәк алар, бик шәрран яра ялчылар түгелме?

— Артык сизелми. Бер хәтле пошыныбрак йөргән сыман күренәләр.

— Алайса, — диде Муса, — сез ул егетләрне аерым-аерым ныклап өйрәнегез. Эч серләренә кереп, үз йогынтыгызга алыгыз. Бер-берегезнең тезисларын, лекция һәм беседа планнарын үзара тикшерү тәртибе кертегез. Һәм теге егетләрнең тезисларында илгә каршы начар урыннар очраса, төрле сәбәпләрен табып, кыскартыгыз. Солдат колагына пычрак сүз күп сеңмәсен. Бу — бер. Икенчесе: һәрберегез үзегезгә икешәр пропагандист хәзерләгез, аларга үз тезисларыгызны, үз планнарыгызны биреп өйрәтегез, дуслашырга тырышыгыз. Ниһаять, өлгертеп җиткергәч, минем белән таныштырырсыз. Ярардай табылсалар, оешмага алырбыз.

— Монысы тагын да кыенрак,— дип куйды Сәйфелмөлеков.— Кеше бит ул һич вакыт укып бетерү мөмкин булмаган китап шикелле. Аның яңа сәхифәләре һаман ачыла тора...

— Бөтен хикмәт тә шунда шул, дускаем,— диде Муса.— Кеше өчен көрәш ансат түгел. Еллар буе сузылган яшерен көрәшләрдә партия эшчеләрне ничек туплаган? Хәер, сезгә политграмота укып тору кирәкми. Берегез югары белемле экономист, икенчегез хәрби юрист. Юлларын, әлбәттә, табарсыз.

— Тапмый булмый, — диде Мичурин. — Без, Фоат, синең белән кирәшебрәк хәрәкәт итәрбез, шулай җиңелрәк булыр.

— Яхшы,— диде Муса, аягүрә басып.— Мин икенче килүгә сез яна уңышларыгыздан хәбәр бирерсез. Ә хәзер, дусларым, сафка басыгыз. Без, туган илнең җиңелмәгән һәм баш имәгән яшерен солдатлары булып, явыз дошманга каршы сугышка чыктык. Безнең изге антыбыз бар һәм ул антка без мәңге тугры булырга тиешбез! Мин әйтеп торам, сез кабатлагыз.

Егетләр, икесе янәшә туры басып, җитди төс белән тантаналы тынлыкта калдылар.

— Мин — Ватан солдаты, ант итәм!..

Кайнар дәрт белән кабатланган сүзләр, тын гына лепердәшкән яфракларга һәм челтерәп аккан чишмә суына кушылып, мең йөрәкләргә барып җитәрдәй яңгырап киткән кебек тоелды...

Муса аларны күңел түрендәге күркәм җылылык белән озатып калды.

— Хушыгыз, дусларым, эшләрегез уң булсын!..

Аннары чуваш егете үзенең эшләре турында сөйләп бирде.

Иртәгесен Муса үзе вәгъдә иткән эшләрне тәмамлады да легион штабына юнәлде. Килгәннән бирле ул инде монда бернichә мәртәбә кагылып караса да Зикендорфны туры китерә алмады. Хөрмәтле шеф әфәндегә хөрмәтле Шәфи Алмаз әфәндедән дуслык сәламнәрен тапшырырга кирәк иде. Аннары ул үзенең эшләгән һәм эшләячәк эшләре турында да аның белән сөйләшергә тиеш. Ә Зикендорф әфәнде менә ике көннән бирле инде өйдә юк. Аны һаман икенче батальонда диләр. Нинди гыйшкы төште икән аның бу батальонга? Мусага да хәзер шунда барырга һәм үз кешеләрен күрергә кирәк. Шуның өчен Зикендорфның анда түгел, бу батальонда калуы хәерлерәк булыр иде. Әмма нишләмәк кирәк, шунда очрашырга һәм эш планнарын аның белән килештерергә теләгәнлектән генә, тизрәк юлга ашыккан кеше булып күренергә туры киләчәк.

Муса, кунак йортка кайтып, үзенең кечкенә чемоданын һәм плащын алды да поездга ашыкты. Едлинодан Крушино станциясенә ике сәгатьлек юл гына иде. Вак шәһәрләр арасында кылтыр-кылтыр сөйрәлә торган бу поездда кеше бик аз була, таланган поляклар немец күзенә күренеп күп йөрергә яратмыйлар иде. Муса, бөтенләй диярлек буш вагоннарның берсенә урнашып, кул чемоданын үзеннән читкәрәк өске сәндерәгә куйды да түбәнге каты урында черем итеп барды. Чемоданда

«кызлар хаты» бар иде. Андый нәрсә йөртү Муса эше түгел, югыйсә. Моның өчен батальоннардан махсус элемтәчеләр билгеләнгән. Житмәсә, куркыныч та әле ул: оешма житәкчесе буларак, зур эшләр башкарырга тиешле кешегә листовка белән тотылып, көтелмәгәндә сафтан чыгу — кичерелмәслек хата булачак!

Мондый бәхетсез вакыйганың бик ихтималлыгын Муса яхшы төшенә, Алиш та аңа бу хакта кат-кат әйткәләде инде, әмма шулай да ул һаман үзенең бу дуамал гадәтеннән туктала алмый. Чөнки солдат арасына буш кул белән барасы килми аның. Нинди дә булса яңа сүз, яңа өндәү илтергә кирәк ләбаса. Ә «кызлар хаты» аның кулы белән языла. Андагы һәр сүзгә Муса үзенең жан жылысын, йөрәк тибешен куша, кайчакта алар нәсер белән язылган шигырь шикелле чыгалар. Менә шул йөрәк ялкынының кушылган кадерле сүзләрнең солдат күңелендә дә тизрәк яңгыравын ничек теләмисең?..

Муса китеп, атна узганнан соң, солдатларның салам мендәре астыннан, тәмәке тарту бүлмәләреннән «кызлар хаты» табыла башлый. Тагын бер-ике көн узгач, шундый ук хатлар барак арасындагы юлларга сибелгән, почмакларга кнопка белән беркетелгән яки бәрәңге белән ябыштырылган булып чыга. Кайбер солдатлар хәтта үзләренең пилотка ярыгыннан да шул ук хатны табалар икән.

Шушы хәлләрне гел күзәтеп йөргән Арыслан кызык итеп сөйли моны: солдат хәрби өйрәнүләр беткәннән соң барагына кайта. Көн буе йөгерә торгач, эттәй арган була. Кичке ашка чаклы биш кенә минут булса да ятып алырга тели. Салам мендәрен чаштыр-чоштыр каккалап, йомшартып маташканда гына нәкъ солдат хатыдай өч почмаклап бөкләнгән бәләкәй кәгазь кисәге идәнгә төшә. Ул аны иелеп ала да гажәпләнеп сүтеп карый. Һәм шунда ук ялт бөгәрләп кесәсенә тыга, як-ягына карана: кеше күрмәдеме, янәсе. Шуннан кызу-кызу атлап курилкага чыгып китә. Анда кешеләр бар. Нишләргә? Ә йөзендә каушау һәм кызыксыну галәмәте. Бәдрәфкә чират көтеп ала да шунда кереп бикләнә. Озак кына утырып чыга. Ә чыкканда инде йөзе балкыган, гәүдәсе, адымнары жиңеләйгән була. Чынлап та, ул сөйгән ярыннанмы, туганнарыннанмы, ниндидер яшерен юллар белән чын хат алган дияр-сең! Шуннан соң ул, янчык төбен кагып, тәмәке төрә башлый, ә куллары жиңелчә генә дерелдиләр. Үзе тәмәке төрә, үзенең күзе башкалар өстендә уйный. Караса, башкалар да аның хәлендә үк шикелле тоела. Я еш-еш тәмәке суырып, баскан урыннарында таптаналар, я тиз генә әбрәкәйгә кереп бикләнәләр дә озак торып, йөзләрен үзгәртеп чыгалар һәм тәмәкегә тагын тотыналар. Эчләренә әллә нихәтле ут һәм сер тулганлыгы күренеп тора, түгелергә генә кыймыйлар, бер-береннән тел яшергән кешеләрдәй, чыгып китәләр. Әмма ертылып ташланган яки немец кулына илтеп тапшырылган бер генә хат та булмый. Аларның әле бу хакта бер шау-шу да күтәргәннәре юк...

Йокылы-уяулы елмаенкырап барган Мусага шушы уйлар жылысыннан ничектер рәхәт булып китте. Шыгырдавык вагонның һәм ниндидер ачулы машинистның аны як-якка шәфкатьсез чайкавына карамастан, бәхеткә тарыган бәләкәй малай кебек, киерелеп-сузылып куйды ул. Шушы уңайсыз һәм шомлы юлларда көн-төн гизүнең, текә кыялы һәлакәт чокыры кырыеннан күз йомып атлагандай гел куркыныч астында йөрүнең үзенә бер ләззәте, ни күрсә дә үкенмәслек мәгънәсе бар төсле тоела...

Инде әкренли башлаган поезд коры тактада сузылып яткан Мусаны идәнгә кагып төшерерлек итеп кырт кына туктап калды. Муса башын күтәреп тәрәзәдән карады. Жимерек бер стена кисәгенә ниндидер кара белән «Крушино» дип латинча язылган иде. Муса сикереп торды да, өс-башын рәтләп, эшләпәсен киде һәм, өстәге чемоданын элэктереп, вагоннан төшеп китте. Станциядә тыз-быз йөрүче немецлар гына күренә

иде. Лэкин Муса алардан курыкмый, аның кэгазьлэре немецның үзен өркетерлек!

Ул батальон казармаларына барып житкэндэ сэер бер тамаша күрде, андагы бөтен солдат, дүрт почмаклап тезеп, мэйданга бастырылган. Уртада киң бушлык. Шунда шактый биек бер багана утыртылган. Баганаңың югары башында шулай ук шактый юан аркылы арата да бар. Читтэн караганда, бу араталы багана поляк католикларының басуларга утырга торган мэһабэт тэресен хэтерлэтэ иде. «Нинди тамаша икэн бу?» дип уйлады Муса. Якынгарак килеп житкэч, аркылы аратаның ике башында ике зур тимер божра барлыгын һэм аларга түбэн салынып төшкэн ике бау кигезелгэнлеген күреп алды. Аның йөрэге жуу итеп китте. «Я алла, дар агачы түгелме соң бу!..» — дип кычкырып жибэрэ язды ул. Аны-моны уйлап тормастан, солдат сафын ерып, мэйдан эченэ узды. Күзлэре белэн Зикендорфны эзлэп, багана төбенэ карады. Анда дүрт немец солдаты баулар астында өч-дүрт кенэ басмачалы такта тумба куеп маташа, аларны кара киемле бер офицер өйрэтеп тора иде. Тукта, кем икэн ул, Зикендорф үзе түгелдер бит? Хэрэкэтлэре таныш шикелле. Һэм Муса бик тиз танып алды: бу аның күптэнге «дусы» иде. Ах, йөзе кара! Шпигель икэн! Нэкъ үз эшенэ керешкэн! Муса йөзен читкэ чөерде. Кайда соң Зикендорф? Тизрэк аны табасы, белэсе иде бит. Нэрсэ бу? Кемнэрне?.. Ни өчен?.. Туктату мөмкин түгелме?

Муса ярсыган ачу тулы күзлэре белэн мэйданны тагын бер кат айкады. Сулдарак, тактадан эшлэнеп, яшелгэ буялган бер трибуна сыман урын күрде. Анда Зикендорф белэн батальон командирлары басып тора иде. Ул шунда йөгерде. Һэм йөгереп килешли үк: «Туктагыз!» дип кычкырырга телэде. Эмма шундук бу уйны кире какты. Кычкырырга түгел, кесэсеннэн «ТТ» чыгарырга да яшел трибунадагы шул шомлы өрэклэрне берэм-берэм чүкеп төшерергэ кирэк! Моны да кире какты: мөмкин түгел иде, коры ярсыну гына иде. Шуннан соң ул, боларның һэммэсен дэ йөзеннэн юып ташлап, көлемсерэү битлеге киде дэ, тыны-көне бетеп килүен яшерергэ тырышып, жиңел генэ адымнар белэн трибунага менде. Легион башлыгы белэн күптэнге якын танышларча, лэкин шул ук вакытта дистанция саклап, ягымлы гына күреште, исэн-саулык сорашты, Шэфинең сэламен дэ эйтеп өлгерде, башка офицерларга ике бармак белэн честь бирде. Аннары, Зикендорфка елмаеп:

— Тамашадан соңга кала яздым бит, майн һерр, — диде.

— Юк, эле соң түгел, нэкъ вакытында өлгердегез, — дип көлде немец.

— Э нэрсэ соң бу? Кемнэрне?.. — дип сорады Муса.

— Э-э, маленки экзекуци... два черемис... — диде Зикендорф, ак перчаткасының бармак очыннан нииндидер кара чүп кисэген чиртеп жибэрэ-жибэрэ. — Һундин! [1]

— Гаеплэре зурмыни шулай ук?..

— Карак, диверсант, дизертир! Асу гына да эз аларны!

— О-о! — дип куйды Муса, жирэнгэн булып. Э үзенең эчендэ мең төрле сорау, мең төрле талпыныш һэм чарасызлык үкенече айкала иде. Нинди бэхетсез жаннар хэрап була икэн? Элбэттэ, аларның кешелек каршында һичбер гаеплэре юктыр, бу ерткычлар гына тагалардыр... Нишлэргэ соң, нишлэргэ? Эх, булсын иде хэзер бер «максимка!» Үзем ятар идем төбенэ, үзем бер-ике генэ тапкыр чайкап алыр идем! Күпме кирэк боларга!..

— Кыргыйлар, бет симертүче урман вэхшилэре, — диде Зикендорф, Муса үзенең булмас хыяллары эчендэ бата-чума йөзгэндэ. — Э бит үзлэрендэ яхшылык чаткылары да күренгэли алар халкының: унбишенче елны без Кокшай урманнарында агач кистек. Плен дип, үз иллэреннэн

[1] Этлэр!

аерылган кешеләр дип, җәллиләр иде. Бәрәңге ашаталар иде. Бәйрәмнәрдә хәтта самогон да сузгалыйлар иде. Әлбәттә, аларның ул сасысын эт тә эчмәс, әмма ул чакта мәҗбүр идек...

Мусаның күңелендә кинәт бер фикер уянды: әгәр үтенеп карасаң?.. Менә шул яхшылыклары өчен дип?.. Аннары кычкырып көләсе килде: Иблисне иманга өндәү? Кертерсең иблискә иман!..

Ә шулай да бу уеннан бөтенләй үк арына алмады. Гомумән, бүген ничектер «хыялый»рак иде ул. Шаярган-көлгән булып кына әйтә салды:

— Бәлки аталарының шул яхшылыклары өчен, мин әйтәм, бу экзекуцияне башка бер җәза белән алыштырырга мөмкиндер?

— Юк, — диде Зикендорф, кырт кисеп. — Закон. Калганнарга сабак булыр. Юкса бу батальонда шәләй-вәләй күбәйде.

Мусага һаман үзсүзләнү уңайсыз иде. Аның шушындый богаулы иректә йозаклы тел белән яшәүгә ачуы килде. Нервлары калтырана башлады. Ләкин ачуны да күрсәтмәскә кирәк иде бит әле. Шуңа күрә ул гайре табигый тавыш белән көлә башлады. Һәм көлә-көлә генә тагын бер сорау бирде.

— Ә Шәфи әфәнде беләме? Президент кеше бит...

— Белә. Сөйләштек. Риза, — диде подполковник. Муса яңа күрде: аның чыны шулай иде хәзер. — Башка допросларыгыз юкмы, майн һерр Һумероф?

Муса уңайсызланып китте. Тыенкылыгы җитмәүгә үзен әрләп алды. Инде мәсьәлә дар агачына килеп житкәч, аны туктатып буламы соң? Нигә бер генә көн алдан килә алмады ул, нигә?..

Ярый әле, Зикендорф аның күзенә озак карап тормады, шактый нәрсәләр укыган булыр иде. Муса үзенең шушы «кимчелеген» тиз генә юып ташлар өчен тагын гамьсез төс алырга, бу тамашадан тәм табучыдай шат күңелле булырга тырышты. Ә Зикендорф, бәйге башлыгы шикелле, һәрьякны күзәтеп, әле теле белән, әле кулы белән боерыклар биргәләп тора иде. Менә, әлегәчә дар баганасы төбендә ниләрдер эшләттереп маташкан Шпигель, хәрби адымнар белән кырт баса-баса, Зикендорф каршына килде дә, ике бармагын СС фуражкасының киң, озын кырыена куеп:

— Бар да әзер! — диде. Аның йөзе ниндидер кыргый куанычлы тантана бозы белән каткан, тик күзләре генә, менә хәзер үләксә өстенә ябырылачак карчыганыкы шикелле, агына сибелгән бөртмәч кан тамырлары белән кызарып яна иде.

Зикендорф аның сүзләренә ияген генә селкетте һәм кулын күтәреп команда бирде:

— Башларга!

Шпигель шундый ук кискен һәм кызу адымнар белән үз урынына китте. Шул ук вакытта якындагы гауптвахта бинасыннан кара киемлеләр чыгып юлга басты һәм ямьсез, шом бирә торган барабан тавышы ишетелде. Менә солдатлар сафының бер почмагы икегә аерылды да барабан сугып килүчеләр мәйдан эченә керделәр. Хәзер инде барын да ачык күрергә мөмкин иде. Муса трибуна кырыенарак килде. Алда кара формалы ике ССчы атлый, автоматларын әзер тотканнар. Алар артыннан гәүдәләре кайгы белән бөкрәйгән ике мескен килә. Бил каешлары салдырылган, погоннары һәм яка трафаретлары йолкынган, башлары ялангач, куллары артка богауланган. Бу мескеннәр артында тагын дүрт ССчы, автоматларын менә хәзер үк сиптерердәй киереп тотып, барабан ритмына атлый. Алардан соң үзәк өзгеч әшәке тавыш белән барабан сугучылар тезелгән.

— Шаңк! Шоңк!

— Даңк! Доңк! Доңк!..

Мусаның башы һаман түбән иелә барды. Ул хәзер аларны күзләренең өске кырые белән генә күрә иде. Әнә ул җәһәннәм мәрасиме дар агачы төбенә килеп туктады. Әмма барабан һаман тынмый:

— Доңк! Доңк! Доңк!..

Шул җан өшеткеч тавыш астында теге ике мескенне ике яктагы ике гумба өстенә меңгереп бастырдылар. Баш очларында торган бау элмәкләрен тартып төшереп, муеннарына салдылар... Мусаның бер кулы чалбар кесәсендә, икенче кул бармаклары белән пинжәк сәдәфенә тотынган. Ул бармаклар бер туктаусыз шул сәдәпне бөтерәләр. Әле бер якка, әле икенче якка... Кесәдәге кулы яулык уалый. Бармак аралары тирләгән шикелле була, шуны корытырга тырыша. Ә барабан һаман дәвам итә:

— Доңк!... Доңк... Доңк...

Кинәт Муса берни дә күрми башлады. Күз төпләрендә түгәрәк ясмыктай гына ниндидер утлы пыяла бар төсле. Ул һаман ныграк яндыра. Күрергә дә, күзне йомарга да ирек бирми. Ә йөрәге тамак төбенә үк килеп кысылган да кычкыртып җибәрердәй сулкылдый. Сәдәп һаман ешрак бөтерелә, йодрыктагы яулык һаман ныграк бөгәрләнә: әгәр ул шушы секундта үзен борып җибәрә алмаса, бар да хәрап булачак. Аның бөтен эчке серләре фаш ителәчәк. «Йотыл, яшем, сукрайтма күзләремне!.. Ул, йөрәк, ул!» — дип ялвара ул. Уйнак чырайлы, янында торган Зикендорф төсле таш елмаюлы булырга тиеш Муса! Яхшы әле, озын буйлы һерр подполковник янәшәсендәге бәләкәй Мусаның күзләренә, йөзләренә иелеп карамый. Рәхмәт төшсен ул каһәр суккырыга! Ул һаман үз командалары белән мәшгуль. Әнә тагын нәрсәгәдер кулын һавага күтәрде...

Барабан шомы кинәт туктап калды һәм дөнья да, хәтта саңгыраулландырырлык булып, тынып китте. Дүрт почмаклап баскан меңләгән кеше дә, әйтерсең, үлеп, тораташ булып каткан иде. Шул чагында, үзенең чалма-чапаннарын җилбердәтеп, шушы ук җәлладлар менбәренә Бикмулла хәзрәт килеп менде. Зикендорф шуны гына көткән булса кирәк, солдатларга таба кулын сузып, сүз башлады:

— Легиончы солдатлар! Кадерле фюрер сезне әсирлек лагерьларында тоткын булып ятудан коткарып, тулы ireккә чыгарды. Туган җирләрегезне большевиклар изүеннән коткару өчен сезнең кулларга корал биреп, сугышчылар итеп хәзерләде. Менә нинди зур ышаныч сезгә! Ә мондый ышанычны бары тик гуманистлар гына күрсәтә ала. Без Европада иң мәдәни халык һәм иң зур гуманистлар. Шуңа күрә дә без сезгә ышанабыз. Киләчәктә сезнең халыкларга тулы ирек вәгъдә итәбез. Әмма сез дә бу яхшылыкның кадерен белергә тиешсез. Легионда тимер дисциплиналы, фюрер өчен үләргә торган батыр солдатлар булырга тиеш. Ә сезнең арагызда тәртип бозулар, менә бу сукбай чиремис егетләре шикелле җинаятьчеләр күренә башлады. Ул бандитлар касса басалар, пушкаларны суга батыралар, ат урлап качалар, имеш! Бу була разбойник! Бу була диверсия! Бу була дизертир!

Муса кинәт айнып киткәндәй булды. Йөзенә балку чыгып, гәүдәсе турая төште. Менә кемнәр икән алар! Ах, җанкисәкләрем, лачыннар икәнсез!.. Аның күзләрен тагын әлеге кызган пыяла ясмыклар яндыра башлады. Ә Зикендорф әле һаман сөйли иде:

— Әмма моннан качып китү — иллюзия! Немецның күзе мең, миллион! Һәр немец дүрт күзле: икесе алда булса, икесе баш артында! Качып котылу юк! Моны исегездә тотыгыз! Менә бу бандитлар бүген дар агачына күтәреләчәк, бу сезгә сабак булсын!

Зикендорф үзенең бу кайнар нотыгын немецча башлап, урта арага русча да кыстыргалап, йодрыкларын еш-еш болгый-болгый ерып чыкты. Аннары муллага тәрҗемә итәргә кушты.

Муса кышкы килүендә бу «хәзрәт» белән очрашкан иде бит. Ул хәзер үз кешесенең ниләр әйтәчәген көтеп алды. Мулла, башта Зикендорфка мөрәҗәгать итеп, үзеннән дә берничә генә вәгазь-нәсихәт сүзе әйтергә рөхсәт алды, аннары тәрҗемәгә тотынды. Җилән астыннан Коръән чыгарып, күкрәгенә куйды. Тәрҗемәсе беткәннән соң вәгазь сөйләде. Коръән сүзләре китерде. «Күршебез мари халкының бу бәхетсез уллары чит җирләрдә вакытсыз корбан булалар, дип кыстырды. Агаһ булыгыз, бу бик гыйбрәтле хәльдер... Онытмагыз моны, туганнар! Иманыгыз какшамасын!..» дип бетерде ул. Солдат арасында нииндидер җанланып алу, йөткергәләп кую булды. Боларның һәммәсен дә җитез күзәтеп торган Мусага җиңелрәк булып китте. Димәкки, хәзрәтне байтаклар аңлады: «онытмагыз, уч алыгыз!» диебрәк әйтергә теләгән иде бит ул.

Барабан яңадан «даңк-доңк!» килә башлады. Муса сискәнеп, йөрәге куырылгандай булып китте. Асучылар, ыгы-зыгы килеп, мари егетләренең гимнастерка һәм итекләрен салдырып маташалар иде. Шул кыйшаеп беткән итекләр дә, шул тузган гимнастеркалар да үлек өстендә әрәм калмасын, янәсе!

Бу мөһим эшләрне дә бетергәч, ике яктагы икешәр ССчы бауны тикшереп карады, Шпигель һаман шунда тыз-быз чабып, ниләрдер өйрәтеп йөри иде. Ниһаять, андый эшләр дә бетте булса кирәк, билгеләнгән җәлладлар һәммәсе үз урыннарына басып, казыктай катып калдылар. Барабан да туктады. Зикендорф салмак кына кулын күтәрде, ләкин Мусаның күзләре анда түгел, ул аны болай гына тойды, аның күзләре дарга кадакланган иде. Тагын баягыча авыр, үле тынлык урнашты. Мәйдандагы меңнән артык солдат, әйтерсең, сулыш алмый иде. Менә хәзер шартлап китәрдәй дәһшәтле тынлык иде бу. Зикендорфның ак перчаткалы кулы, һаваны кылыч белән урталай ярган сыман, кинәт кенә түбән төште. Һәм шул ук авыкта нииндидер көчле йөрәк тавышы белән:

— Виян лийже эрык! [1] — дигән билгесез сүзләр яңгырады. Муса аларны ничек тә булса хәтерләп калырга тырыша иде. Шул авыкта бу сүзләр, әллә кайтаваз булып, әллә икенче егетләрнеке булып яңадан кабатланды:

— Виян лийже эр-р!.. — тик ахыры өзелеп калды. Җәлладлар бөҗрага кигезелгән бауларны көч белән аска тарта башладылар. Шпигель исә шашкын җитезлек белән егетләрнең аяк астындагы тумбаларны читкә тибеп җибәрде... Тагын шашкын барабан сугылды:

— Доңк... доңк... доңк...

Муса әллә кайчан баягы сәдәпләренә тотынган һәм туктаусыз бөтерә торгач, башта берсен, аннары икенчесен өзеп чыгарган иде. Бар да бетте... Бар да бетте... Хушыгыз, батырлар... Бармакларының өченче сәдәпне бөтергәнен шунда гына күрде ул һәм гаҗәпкә калды: кайда өзелде микән аның бу ике сәдәбе? Әле иртә белән генә урыннарында шикелле иделәр бит?..

— Энде процедур, майн һерр Мусза [2] — диде Зикендорф, бәйге мәйданын уңышлы тәмамлаган судьядай җиңел сулап. — Сез инде ачыгып беткәнсездер.

— Ә-ә, әйе, әйе... — дип көлемсерәде Муса, әче чырай белән. — Чынлап та, бик ачыкканмын шул.

— Әйдәгез алайса, бергәләп батальон командирына киттек. Сыйласын әле безне!

---

[1] Яшәсен ирек!
[2] Процедура тәмам, Муса әфәндем!

## III

Ул аларның ашын бер генә дә капмас иде, хәтта табыннарына төкереп чыгып китәр иде, бәлки. Бу минутта кеше тамагыннан ризык узуы мөмкинме соң? Алай гына да түгел: шагыйрьнең палачлар белән бер табынга утырып кәефләнүе, гомумән, мөмкинме? Шул табында, күрше батальоннан килгән «эшле» кунак буларак, хәтта Шпигель дә бар ич әле! Дөрес, ул хәзер тынган, өс-башын алмаштырган, аңардан хушбуй исләре генә килеп тора. Әмма кулларыннан, бармак очларыннан барыбер кан тамчылап торадыр сыман тоела. Нинди усал шаяра бу язмыш! Теләсә дә, теләмәсә дә утырырга мәҗбүр ул. Көләргә, елмаерга мәҗбүр! О, белсә иде кешеләр! Шушы минутта үзлегеңне ярешеп бер көлүгә караганда, каршыларына басып автоматтан сиптерү һәм шунда үзең дә үлү никадәр җиңелрәк булачагын белсә иде кешеләр!

Муса әз генә чемченгәләп утырса да, авызына эчемлек алудан бөтенләй баш тартты. Юкса аның үз-үзен тота алмавы, эчендәге бөтен давылларны чыгарып бәрүе мөмкин. Шуңа күрә ул сылтау тапты. Үзенең әле хезмәт башкарган вакыты икәнен, солдат, сержант, пропагандист арасында һәм хәзрәт янында буласы барлыгын әйтеп котылды.

— Халык арасында йөргәндә, бигрәк тә, хәзрәт янына барганда, авызыңнан аракы исе килмәскә тиеш. Шәригать моны бик нык тыя безнең! — дип өстәде ул.

Иң башлап Зикендорф яклады аны:

— Кунакны артык көчләмик, әфәнделәр, — диде. — Мин аны яхшы беләм. Бахус белән дуслыгы шәптән түгел. Дини гадәтләре кушмавы да дөрес. Аннары, Мусза әфәнде, русьча әйткәндә, бик службист кеше. Айнык булуны ярата...

Немецлар, әлбәттә, бу мәсьәләне артык куертып тормадылар. Бер азиатның эчү яки эчмәве алар өчен барыбер түгелмени? Һәм бокалларын күтәрә-күтәрә, үзара гөжләшә башладылар. Тик Шпигель генә, өй кыегындагы күгәрченгә кызыккан мәче шикелле, иреннәрен ялмыйялмый Мусага карап куя иде.

— Бәбәге чергере! — дип тиргәде Муса эченнән. Тегеләрнең гөжләүләре тагын да кәефләрәк булып киткәч, шуннан файдаланып, урыныннан торды да:

— Рөхсәт итегез, әфәнделәр, мин үз эшемдә булыйм инде, — диде һәм ишеккә атлады.

— Арбайткомандага да яхшы пропагандист тапсагыз икән! — дип үтенде аннан комбат һәм хәзрәтнең хәзер кайда торганын әйтте.

— Тырышырбыз! — диде Муса. Төрмәдән ычкынгандай куаныч белән чыгып китте. Ул, чынлап та, мулла янына ашыкты. Монда хәзер бараклар салып кергәннәр, пропагандистлар торагы — штабтан ерак түгел кечерәк кенә бер бина, ә мулла шуның бер почмагындагы бүлмәдә яши икән.

— Нинди коточкыч хәлләр булып ята сездә? — дип пышылдады Муса, ишектән керүгә үк.

Бикмулла хәзрәт үзенең чалма-чапаннарын салып аткан да, ачык мич авызына чүгәләгән хәлдә, тәмәке пыскытып азаплана иде. Мулла кеше булгач, яшереп кенә тарта, күрәсең. Әмма бүлмәгә шактый ук сөрем җыелган, мөгаен, бу аның беренче сигареты гына түгел... Күрешергә сузган куллары да дерелдәгән сыман тоела...

— Исәнмесез, Муса иптәш, утырыгыз, — диде ул, тыныч күренергә тырышып. — Хәзер Уразаев та керер, сөйләшербез. Сезне күзәтеп чыккан иде.

Муса тәрәзәдән карады һәм сискәнеп китте дә почмакка барып утырды. Теге ике бәхетсез, әлбәттә, һаман дар агачында иде һәм ничектер салмак кына чайкалып торалар шикелле тоелды. Аларны чайкар-

лык көчле җил дә юк бит югыйсә... Озак тотарлар әле... «Сабак өчен» диде бит...

— Ник бу тәрәзәңә өлеңге кормыйсың? — диде Муса, ачулы тавыш белән. — Бөтен кабахәт дөнья күренеп тора!

— Солдатка өлеңге не положено.

— Син мулла ич. Күп хокукларың бар, файдалан! Бүлмә эчеңне тыштан күзәтмәүләре дә яхшырак түгелмени?

Мулла акланып яки бәхәскә кереп тормады, «дөрес инде анысы...» дип кенә бетерде.

Харис Уразаев килеп керде. Аның да йөзе сары киндер төсле иде. Мусага сүзсез генә кул бирде. Әмма Муса сүзсез кала алмады:

— Нәрсә бу? — дип сорады зәһәр пышылдап һәм йодрыгы белән тезенә сугып куйды.

— Булды инде... Безнең тарафтан бик зур упущение...— Һәм Уразаев өстәлгә башын салындырып үксеп җибәрде. Муса беравыкка шаккатты. Ләкин шунда ук, аяусыз булырга тырышып:

— Тукта, райком секретаре, нәрсә син, кызлар шикелле!..— дип кычкырды боерык интонациясе белән. Тик соңгы авазы кинәт сынып китте. Ул үзе дә ирексездән күзләрен түбән төшерде һәм пинжәгендәге өзелгән сәдәп урыннарын өйрәнә башлады. Немецлар белән утырганда ул аларны яшерү өчен пинжәген гел җилбәгәй җибәреп, уң як чабуын әйләндереп утырган иде. Ә монда инде күрсәләр дә ярый...— Аңлатып бир!

Уразаев, терсәкләре белән өстәлгә таянып, башын күтәрде. Сөйли башлады.

...Мари егетләре. Икесе бертуган Пекпулатовлар. Берсе Миклай, берсе Асан. Эшче командада булганнар. Качарга җай эзләп йөргәннәр. Җай табылмаган. Үзләренең тагын бер-ике якташларына да әйтеп караганнар, тегеләрнең тәвәккәллеге җитмәгән. Ә күптән түгел генә язмышларын менә бу фаҗигага борып җибәрүче бер көтелмәгән вакыйга булган. Станциядән ун ат белән пушкалар алып кайталар икән. Шактый тирән һәм каты агымлы Ижня суына салынган агач күпер бар. Моңарчы шуннан күпме йөриләр, һич нәрсә булмый. Ә ул төнне исә, авыр йөкле пар-пар атлар кереп бетү белән, күпер сыгылып, кыйшаеп, суга ава. Пушкалар да су төбенә китә. Кешеләр һәм кайбер атлар йөзеп чыгалар. Иртәгесен тикшереп карасалар, күпер баганалары һәм өрлекләр киселгән була. Күрәсең, поляклар эше булгандыр. Әмма Зикендорф моны югары командованиегә белдермәскә тырыша. Чөнки бигрәк борын төбендә бит, гамьсезлеге белән күрмәгән булып чыга. Шуның өчен Зикендорф күпернең искереп җимерелүе һәм аны тиешле поляк общинасы вакытында карамавы турында шикаять белән югарыга рапорт бирә. Ә бу егетләргә, юри җимерек күпергә алып кергәнсез дип, концлагерь вәгъдә итә. Шунда ук озатучы булып йөрүче немец солдатлары да була. Әмма аларга җил дә тими. Кычкырып торган гаделсезлек аркасында концлагерьда үләргә теләмәгән Миклай белән Асан тиз арада качарга җыеналар. Зикендорф концлагерьга озату белән куркытса да, алар әле кулга алынмаган була, эшләп йөриләр, нәүбәтләре җиткәч, нәрәт торалар. Ул төнне Миклай бер немец солдаты белән хозкоманданың штаб канцеляриясендә, Асан исә атлар янында нәрәттә була. Төнге икеләрдән соң Асан абыйсы янына керә һәм Миклай шул минутта ук, үзенең иске рус мылтыгына беркетелгән рус штыгы белән, каршында калгып торган немецның эчен айкап ташлый. Теге, черек тумран шикелле, шап итеп идәнгә ава. Асанның кулында балта булган икән, тимерләгән агач ящикны арттан каерып ача, кассадан юк кына суммада акча табыла. Кесәләренә тыгалар да, немецның автоматын алып, конюшняга йөгерәләр. Һәм анда тиз генә үз атларын чыгарып атланалар да төн карангысында юк булалар.

Тик тояк тавышлары гына ишетелеп кала. Болар һәммәсе дә күз ачып йомган арада эшләнә. Күрәсең, алар моны алдан бик нык уйлашып куйганнар. Төнге сакчылар нәрәте ике сәгатьтән ике сәгатькә алмашына. Тик әнә шул нәүбәттәге алмаш килгәч кенә немецлар хәлне күреп алалар, һәм шау-шу күтәрелә, төрле якларга машиналар, мотоциклар чаба. Билгеле инде, авыр йөк аты белән чапкан һәм рәтләп юл белмәгән, кулларында компаслары да булмаган егетләр күпме җир китә алсыннар? Таң атуга аларны тотып алып кайталар...

— Менә шундый батыр егетләрне оешмага тарта белмәгәнбез, әрәм булдылар, мескенкәйләрем! — дип, тагын бер көрсенеп куйды Уразаев.

— Сәбәбе? — дип сорады әле һаман кырыс тавышлы Муса.

— Сәбәбе гади: без эшче командадагы кешеләрне, әз дипме, картлары, аксак-туксак диебрәкме, исебездән чыгарып җибәргәнбез. Ә безгә асыл кешеләрне бөтен почмаклардан берәмтекләп җыю кирәк булган икән. Хәзер менә, авыз пешкәч, өреп каба башладык инде!..

— Мари егетләре нәрсә сөйли? — дип сорады Муса, күзләре мөлдерәвен тыярга тырышып.

— Алар бездә унлап кына кеше. Әмма шул унавы да дөрләп яна. Каргыйлар: «Каһәр төшсен фашистларга!» диләр. «Бирмибез мыскыл итәргә үз кешеләребезне!» диләр.

Муса хәтерләп алды. Яз көне Волхов фронтына пополнениегә марилар килгән иде. Ак бүрек, ак тун, ак итек киеп йөрделәр. Күрәсең, аларны бу формага үз илләреннән үк киендереп җибәргәннәрдер. Әйбәт сугыштылар, бердәм һәм туганчыл иделәр. Тик, үзләренең рухлары саф булганга, дошманның мәкерен, явызлыгын гына аңлап бетермичә, хәрап булалар иде. Дошман минасыннан берәр мари егете яраланса, калганнары шуның янына йөгереп килеп кызганышырга тотыналар, ә мәкерле дошман нәкъ шулай бергә өелешүне генә күзәтеп тора да берьюлы берничә мина китереп сала. Һәм бер яралы урынына ун яралы була иде.

— Булыр,— диде Муса, озак паузадан соң,— алар бик туганчыл халык. Нишләмәкчеләр соң?

— Үлсәк шунда үләбез, бүген төндүк алабыз без аларны! — диләр.

Муса өчен бу яңа фикер иде һәм ул аны куандырып куйды. Юкса, Зикендорф атна буена шунда тотып, солдат йөрәгенә курку сеңдермәкче була бит.

— Ә бу — әйбәт идея! — дип, ачылып китте ул.— Шундый тәвәккәл егетләр булуы ни тора! Сез ничек уйлыйсыз?

Моңарчы тын утырган Җиһаншин үзенең муллаларча түгәрәк сакалын сыпырып куйды.

— Шәп булыр иде бу!

— Әгәр оештыра белсәк,— дип өстәде Уразаев.

Муса байтак кына уйланып утырды һәм әйтте:

— Эшләгез. Немецлар бүген бәйрәм итәләр әле. Иртәгә якшәмбе. Шулай булгач, тантананың сузылуы да мөмкин. Зур чара үткәрүләренә һәм эксцеслар булмыйча тыныч узуына куаналар. Алар шул сөрем белән иртәгесен торуларына дарда мәетләр булмаска тиеш. Эшегез чиста булсын!..

Аннары ул штабка килеп, Зикендорфка үз йомышларын язып калдырды да станциягә китеп барды. Бу үлем мәйданында төнгә калуның кирәге юк иде, егетләр ышанычлы — үзләре дә башкарырлар...

## IV

Беренче батальон кешеләре үзләрен кай тирәләргә китереп бушатачакларын һәм ничек файдаланачакларын алдан белә алмадылар. Әйтик, тыштан алып кергән туң утынны шунда ук дөрләп янган мичкә

ыргыткан шикелле, боларны да килешли үк сугышка илтеп тыгарлармы, әллә башта оборонага куеп киптерерләрме,— билгесез. Әмма мондагы солдатның күпчелеге үз язмышы алданрак хәл ителәчәге турында уйлый иде. Фронт сызыгына барып урнашканчы икенең берсе булырга тиеш: я котылу, я үлү. Әлбәттә, берәүнең дә үләсе килми. Һәркем үзенең нинди кыенлыклар белән булса да котылуын, алдан күзаллап та булмаган яшерен сукмаклар белән үзебезнең якка чыгуын һәм үз туганнары белән күрешү көннәрен хыялында күрә иде. Аларның күбесенә берәм-берәм аңлату булды: житәкче кеше — подполковник, тәжрибәле, ышанычлы командир, диделәр. Комиссары да майор дәрәжәсендәге кеше икән. Шуңа күрә солдатның тәвәккәллеге тагын да ныгыды.

Подполковник Актабанов үзе дә юл буена шул хакта уйлап барды, үзенчә төрле планнар корды. Ләкин аның планнары, кабул булмаган ураза шикелле, күккә асылынып тора иде әле. Командир планын раслау өчен жир кирәк. Урынның рельефына карап рекогносцировка,— монысы инде жир өстенә аяк баскач эшләнер, күз һәм уй-хәрәкәткә әллә нихәтле үзгәреш кертер. Тик урман гына булсын иде. «Ради бога урман бир, ходаем!» — дип ялвара ул эченнән һәм үзе әз генә көлемсерәп куя. Малай чакларын, яшьлек елларын искә төшерә. Төн эчендә егерме биш чакрымны атта кайтып, Маржи белән кавышканнарын хәтерли. Гажәп, шул чакларын хәтерләсә, күңеле ныгып китә, булмастай кыен эшләр дә жиңел генә булыр сыман тоела башлый, берәр хәйләсе табылгандай була.

Муса киткәч, күтәрелеш сигналы турында баш ватып утырганда да ничектер шул чакларын яңадан бер кат кичереп алды. Бәхетле көннәрне искә төшерү — һәрвакыт күңелле шул... Эзли торгач, әлеге кара көпшәсе дә табылды тагы. Поляк жирләрендә үсә икән ул. Аргы урман кырыендагы кечкенә бер болыннан тапты ул аны һәм үзенең сөяк саплы бәләкәй пәкесе белән төптән үк кисеп алды да, яфракларын чистартып, башын өзеп, аннары дүрт почмаклы дүрт тишек тишеп, сызгыртып карады. Бармакларын төрлечә баскалап маташа торгач, көй чыгара башлагандай булды, Галиябану көе! Кырык биштән узган Актабанов, унбиш яшьлек Уничим шикелле, сөенеп куйды. Як-ягына карап алды: кеше күрмиме, адәм көлкесе! Юк, берәү дә күрмәде аны. Аннары ул шул ук урынга комиссарын алып килде. Көпшәне күрсәтеп, курай ясарга һәм ничек көй чыгарырга өйрәтте. Тиешле кешеләрне шушындый курай белән тәэмин итәргә һәм Галиябану көен өйрәтергә кушты.

— Ә Сәйдәш маршының беренче мелодиясен өйрәтсәк? — диде Габидуллин.

— Читен булмасмы соң ул, үзләштерә алырлармы?

— Тырышып карыйк, нәрсә чыгар. Ләкин бик шәп булыр иде!

— Жахшы алайсам,— диде Актабанов.— Әйдә, тырышыйк...

Ә кичен инде оффицирсбурше[1] Актабанов бу уенчыгын үзенең майорына да сайратып күрсәтте. Татарларның бик яраткан милли көе, диде. Немец майоры көлә-көлә тыңлады да, бала-чаганы куандырган шикелле, диншигенең аркасыннан кагып куйды: егет икәнсең! янәсе. Актабанов исә үзенекен уйлады: ишетә тор, колагыңа ят тоелмасын. Вакыты житкәч, сискәнмәскә яхшы булыр...

Вагонда немецлар бик шәп әйттерел килделәр. Эчемлекләрнең һәртөрлесе, бигрәк тә, офицер вагоннарында, агылып кына торды. Вагон яңгыратып акырулар, авыз гармонена биюләр, туры килгән жирләрдә «тәтәйләр» белән күңел ачулар хәттән ашты. Шул чакларда майор Краузе үзенең һөнәрле диншиген дә онытмады: әледән-әле уйнаттырып

[1] Диншик.

кына торды. Азиатның кыргый музыкасын тыңлау — үзе бер экзотика, үзе бер хозурлык иде...

Шулай шәп кенә күңел күтәреп килгән бу эшелонны Орша белән Витебск арасындагы Дерюги станциясенә туктаттылар. Анда батальон, вагоннардан бушатынып, автомашиналарга төялде дә Чикләвек күленә килде. Тагын бушатындылар; чөнки, алдагы утыз-кырык чакрымда гел күлләр дә сазлыклар гына булганлыктан, үз аягы белән йөрердәй кешеләрне машинада ташу түгел, алгы сызыкны кораллар һәм азык-төлек белән өзлексез тәэмин итү дә шактый кыен икән. Җитмәсә бит әле, болар немец солдатлары да түгел, азиатлар! Атлый бирсеннәр тәпи-тәпи!

Шулай итеп батальон алгы сызык тирәсендәге Осинторф пунктына җәяүле марш белән юнәлергә тиеш булды. Моңа Актабанов белән Габидуллин бик сөенсә дә (чөнки машинага төялгән килеш хәрәкәт башлау бик кыен булыр иде), немец офицерлары ризасызлык күрсәттеләр. Ничек инде майор, капитан, оберлейтенант һәм башка немец офицерлары утыз сигез чакрымны җәяү атласын? Шуннан соң аларга иярле атлар таптылар. Майор хәтта үзенең диншиген дә онытмады: Актабанов та бер тимгелчуарга атланды. Чөнки ул һәрвакыт үзенең командиры янында булырга тиеш бит. Тик немецның унтерлары һәм гади солдатлары гына җәяү калдылар.

Көндезге сәгать икеләр иде. Батальон Чикләвек күлендә төшке аш ашаганнан соң юлга чыкты. Батальон командиры, тагын берничә офицер озын торыклы, елдам йөрешле атлар өстендә алдан баралар. Җилкәсенә немец автоматы аскан Актабанов та үзенең тимгелчуарында алардан әз генә арттарак атлый. Аннары, роталап-взводлап, бишәр кешедән тезелгән озын колонна сузыла. Рота һәм взвод командирлары үз бүлекчәләре башында. Немец һәм татар унтерлары кырыйлардан киләләр. Колонна койрыгында гестапочы Шпигель белән тагын берничә кара киемле унтер шулай ук ат өстендә теркенлиләр. Беренче ротаның башында, уң флангта, Габидуллин. Ә койрыгында, шулай ук уң яктан, Арыслан бара. Ул бер генә минутка да күзләрен комиссардан алмый һәм колакларын торгызып курай көтә.

Баткак җир өстенә агач түшәлгән тар гына юлдан ике автомашина кара-каршы узарлык түгел. Андый урыннар торымнан-торымга гына эшләнгән. Юлның ике ягында җир өсте генә түгел, агачлары да мүкләнеп торган калын урман. Инде иртәгә май башы булуга карамастан, мондагы язгы сулар әле һаман кипшереп бетмәгән, шактый урыннарда агач юл өстенә дә нииндидер яшькелт күләвекләр чыгып тора. Солдатлар «чап-чоп» итеп аларның күзләренә басып узалар. Атлый торгач инде ун-унбиш чакрым юл кителгәндер. Чыршы-нарат урманы һаман калыная бара. Куе яшел төстәге калын шәл өстенә сыек кына саргылт-яшел бизәк сибелгәндәй агач яфраклары да отыры сирәк күренә хәзер. Ә җирдә котырып яшь үлән ускән. Кыяк, камыш, шылан шикелле саз үсемлекләре, нарат төпләрендәге кара-кучкыл абагалар, әле бик озын булмасалар да, сәгать саен өскә үрмәлиләр төсле. Бу тирәләрдә зуррак авыл урыннары да күренми. Әллә нидә бер очрый торган өч-дүрт йортлык бәләкәй хутор урыннарында да кайбер морҗа калдыклары гына ыржаеп тора. Тирә-якны ныклабрак күзәтә барган саен Актабановның тамырларына кан тула, нервлары киерелә, йөрәге кысыла бара кебек тоела. Әнә колонна да нииндидер тирән тынлык эчендә калды төсле. Гадәттә солдат, сафка тезелеп ерак юл алганда, узара әкрен генә нидер мыдырдап баручан була. Урман күләгәсендәге умарта кортларының үзара тыныч кына кайнашуларыннан да шундый тавыш килә бит. Әмма колоннада бу гамьсез серләшү дә ишетелми. Алар, сулышларын яшергәндәй тын алып, көтәләр, күрәсең. Тик кырыйдан һәм арттан килүче немецлар гына ара-тирә кыйгылдап куйга-

лыйлар. Иң койрыкта килүче интендант һәм медпункт обозларында ат пошкырулары да бу дәһшәтле тынлыкка үзгәреш кертә алмый. Моңарчы арьергардта шактый ук шукланып килгән автоматчылар төркеме дә, немецлар белән катнаш булуга карамастан, тынып калды. Актабанов өчен арьергард шактый ук куркыныч нокта иде. Чөнки анда барган немецлар, эш башлану белән, колоннаны арт яктан кыра башлаулары мөмкин. Шуның өчен күп кенә сәбәпләр табарга һәм, үз командирлар аркылы сөйләшеп, немец автоматчылары янына әсирләрдән хәзерләнгән автоматчылар төркеме дә ябыштырырга туры килде. Хәзер инде арьергард өчен бик ул хәтле кайгырырга кирәкми иде. Ләкин ничек кенә итсәң дә шактый корбансыз булмас инде. Ник дисәң, колоннага җәелер урын юк, мөмкин дә түгел. Нинди команда бирергә кирәклеген дә белер хәл юк. Чөнки юлда бара торган колоннаның кинәт кенә коралга тотынып, үз янындагы кешеләр белән сугыша башлау мисалы бер генә хәрби уставта да юк шикелле. Бу бары тик шушы сугышта туган факт булып кына калачак...

Колонна өстенә сарылган бу кургаш тынлык майор Краузены да баса башлады булса кирәк, җилкәләрен селкеткәләп, атын яртылаш борды да немецларгамы, Актабановкамы, кемгәдер эндәште:

— Нәрсә болай, үлек күмгәндәге шикелле, тынып калдылар? Әллә ардылар дамы? Бик иртә!.. Яле, Анисмин, уйнап җибәр кураеңны, күңелләре ачылсын азиатларның!..

Онисим Гуриевич, немец майорына ихлас күңелдән хезмәт иткән кешедәй киң елмаеп, мыекларын сыпырып куйды, үткен күзләрен кыса төшеп, як-якка, Габидуллинга һәм башка үз кешеләренә күз йөртеп алды, көпшәсе түбән асылынган автоматын җайлаштырган булып (гүяки ул аңа бик комачау итә) бот өстенә салды, аннары атын шулай ук яртылаш борып, кунычыннан кураен тартып чыгарды, өргәләп карады һәм шул ук елмайган килеш майорга күз төбәп:

— Була ул, майн һерр! — диде, гадәттәгедән катырак тавыш белән. Аннары, нихәтле генә сиздермәскә тырышса да, чак кына калтыранган куллары белән кураен авызына китерде. Итагатьле елмаюы сүнде һәм: «Хәерле сәгатьтә!» дигән сыман җитди төс белән атаклы маршның беренче мелодиясен уйнап җибәрде:

— Ләл-ләл-лә-лә-ләл-лә-лә-ләу-ләу!..

Шул ук сулышта колонна буйлап та шундый ук нечкә тавышлы курай моңы яңгырады. Бу тавышта малайлар сыбызгысы да, болын өстендә әйләнеп очкан тәкрарлек авазы да, көмеш яфраклы тал куелыгына качкан сандугачның сызгырып куюы да, шул ук вакытта йөрәкне кинәт ашкындырып җибәрүче моң да бар иде шикелле. Ләкин кешеләрнең бу аһәңнәр белән ләззәтләнергә вакытлары булмады, алар фәкать ярсу чакыру авазын гына ишеттеләр. Тик майор Краузе гына авызын ерып җибәргән иде, әмма шул ук сулыштаниндидер шашкын тизлек белән каяндыр сибелгән яшен утлары аны урталайга кисеп ташлады, майор янындагы ике офицер да шунда ук башлары белән җиргә кадалдылар. Яраланган атлары, үрле-кырлы сикереп, чыйный-чыйный, юл буйлап чабып китте.

Актабанов инде сикереп җиргә төшкән, үлеп яткан Краузеның планшетын алып кигән иде. Аның һәрбер хәрәкәте автоматыннан сибелгән яшен чаткылары тизлегендә булды. Атылып колонна эченә килеп керде ул. Монда атыштан бигрәк штык сугышы бара, кул белән буыш бара иде.

— Кыр дошманны! Бетер! — дип кычкырып җибәрде ул.

Немецларның шактый өлеше юл читендәге агач, куак төпләренә ятып өлгергән һәм автомат, пулемет уты белән безнең солдатларны кыя иде. Уттан качар урын юк, винтовка белән бер пуля атканчы немец биш-алты кешене кырып сала. Менә, чакрымга сузылган мең

җанлы, мең куәтле колонна кинәт бер мәһабәт тибрәнеп алды да, ике якка аерылып, ут нокталары өстенә ташланды. Алар тына төште һәм буылган дошманның үлем ачысы белән чыккан соңгы гыжылдавы гына ишетелә башлады. Шул ук мәһабәт дулкын белән бергә ташланган Арыслан җиргә тигән салынкы ботаклы карсак бер чыршы төбендә автоматтан сиптереп яткан Шпигельне күреп алды. Күреп алуы булды:

— А-а, майн хер! Фашист күзгесе, исәнме! — дип бер кырыйдан аның өстенә ябырылды. Көпшәсеннән тоткан винтовкасы белән болгап башына тондырырга чамалаган иде ул аның. Ләкин Шпигель автоматын бора башлагач, ашыгыч сугылган приклад немецның беләкләренә туры килеп, коралын кагып төшерде. Арыслан автоматка үрелгән генә иде, гестапочы кинәт аның өстенә ташланып, озын бармакларын абзыйның бугазына батырмакчы булды. Аста калган Арыслан көч белән тыпырчынып, әллә нинди еландай боргалана-боргалана ычкынды да:

— Булмас ул! — дип кычкырды.— Сузма пычрак кулларыңны! — һәм ничектер җаен китереп, тегене башы белән чөеп җибәрде. Төсләренә, күзләренә чыккан чамасыз ярсу белән аягүрә басты. Басты да Шпигельнең якасыннан үзе эләктереп алды. Алар көрмәкләшә башладылар. Башкаларның моны күрергә вакытлары юк, һәркем үз эше белән мәшгуль иде.

— Җаның җәһәннәмдә, энекәем, барыбер! — диде Арыслан. Һәм Шпигельнең бил сөякләрен сындырырдай шытырдатып кысып алып, бөтергәләде дә әллә кая атып җибәрде. Сабан туенда көрәшәмени! Әмма хәл уен түгел иде. Әле һаман үз этлегендә булган Шпигель автоматына таба үрмәләргә маташты. Арыслан да үзенең мылтыгына ташланды. Ләкин аны корып торырга вакыт бармыни? Пулялары әллә кайчан атылып беткән. Шуның өчен ул аны тагын көпшәсеннән алды һәм чукмарлы бүре күсәгедәй болгап китереп, Шпигельгә алданрак тондырып өлгерде. Бу юлы приклад туры төште. Фашистның биек түбәле, үләксә сөякле картузы урталай янчелде, нәрсәдер «чыррк!» итүгә, тамак астыннан эләктергән сагалдырыгы шартлап өзелде. Шул ук секундта картуз астыннан кызыллы-аклы ниндидер куе күбек күренде. Шпигель башта чайкалды, аннары тезләре сыгылды да саз каены шикелле «гөрс» итеп җиргә ауды. Арыслан үләксәдән җирәнгән кешедәй йөзен чытып бер төкерде дә башкалар янына ашыкты. «Эх, бәләкәчем, күрсәң иде син бу сабан туйларын! — дип сөйләнә иде ул үз-үзенә.— Менә «Көзге» дустыбыз да ватылып, оҗмахның түренә сәфәр китте... Көзге булгач, хур кызларының кесәсендә генә йөрер инде ул анда...»

Атыш тора-бара тәмам тынды. Актабанов планшет өстендәге компас белән янәшә беркетелгән сәгатькә карады: эш башлануга егерме минут вакыт узган иде. Беләгенә ак марля бәйләгән комиссар килде.

— Тәмам,— диде ул, тыныч тавыш белән.— Йөз туксан биш.

— Туктале, дустым, беләгең нәрсә синең? Башта шунысын әйт...

— Пустяк! — дип көлде Габидуллин.— Арыслан, җиңми торып, ярасын яламас, диләр бугай. Без дә яраларны җиңгәч санашырбыз инде.

— Йөз туксан биш, дисеңме? Сталь быть, бер генә немец кача алган? Бу бик яхшы. Артта да, алда да хәзергә һични белмиләр. Разведка командиры! Алга да, артка да яңа дозорлар билгеләү! Интендант командиры Арыслан Алыпкулов! Азык-төлек обозларын урманга тарттыр! Рота командирлары! Колоннаны урман эченә; яралылар һәм үлгәннәрне транспортлауны тәэмин итәргә! — Ул шулай кыска-кыска командалар бирде дә тагын комиссары белән сөйләшә башлады: — Ә бездән күпме үлгән, күпме яралы?

— Күп шул, Онисим Гурич,— диде Габидуллин.— Позициясез сугыш булды бит. Просто бутка. Солдат үзен аямады. Үлгәннәр йөз дә

ике кеше. Уртача һәм җиңел яралылар туксан өч, эчләрен автомат өзеп киткәннәр — биш. Аларны коткара алмабыздыр...

— Нишлисең бит, корбансыз мөмкин түгел,— диде Актабанов, тирән сулап. Аннары фуражкасын салып маңгай һәм муеннарын сөртте дә, Габидуллин каршына басып:

— Исәнме, дустым! Котылуның беренче минуты белән котлыйм! — диде. Тегесе аны кочагына кысты һәм алар ике як битләреннән алмаштилмәш үбешеп алдылар...

Батальон колоннасын урман үз карнына йотып бетерә язган иде инде. Кояшның кичке сары ефәге нарат башларындагы иң биек боткаларга элеңгән иде. Әле генә шашынган мылтык тавышларыннан куркып качкан булсалар кирәк — кошлар сайравы да ишетелми иде. Немец офицерларыннан исән калган атларның барысын да обозга биреп, Актабанов белән Габидуллин да, рота командирлары да шул тынлыкта колонна белән бер сафта җәяү атладылар.

Беркаян да куа килү билгесе сизелмәде. Немецлар әле хәбәрсез иде, күрәсең. Һәм шулай булырга тиеш тә. Чөнки колоннаның Осинторфка килеп җитүе төнге уникеләргә генә билгеләнгән. Андый-мондый сигнал булмаса, төн уртасы урынына иртәнгә хәтле көтүгә дә немецлар гаҗәпләнмәячәк. Тик шуннан соң гына алар уйлана башларга тиеш. Әмма алар уйлана башлаганчы, шушы төн эчендә үк икенче бер участокны кинәт өзеп, максатның соңгы өлешенә ирешү кирәк...

Ни дисәң дә, бәхетле башлангыч иде бу. Краузеның азиатиш мюзикны үзе сорап уйнатуы, бик вакытлы булып, дошманны тойдырмастан кыра башларга юл ачты. Сугыш һәрвакыт шулай бит ул: кем алдан ора? Дошманың бер генә минутка йоклап, синең беренче хәрәкәтләреңнән үк абайлап алмаса, син инде операцияне яртылаш оттың, дигән сүз. Чөнки беренче сугу көче белән бергә йөрәк кыюлыгы да, мораль көч тә синең якта була!

Батальон юлдан җиде-сигез чакрымнар эчкә кергәч, бәләкәй бер үргә тукталды. Меңләп солдат кәрәге эшкә тотынды. Һәм Белорус җире тиз арада үзенең йомшак комсу балчыклы озынча куенын ачты. Үлгәннәрне рәт-рәт тезеп, шунда салдылар. Командир Актабанов баш киемен кулына тотып, ике-өч кенә авыз сүз әйтте:

— Газиз дусларым минем! Сез ирек өчен батырларча корбан булдыгыз. Туган ил сезне онытмас! Без әле монда яңадан килербез. Килербез! Һәм дошманны себереп түгү белән, каберегез өстенә онытылмас һәйкәл кую — безнең солдатлык бурычыбыз булыр! Хушыгыз, туганнар, хушыгыз!..

Аннары ул балчык өстенә тезләнде. Аның артыннан меңләп кеше озынча кабер якасына чүкте. Солдатның традицион залпы яңгырамады, мылтыклар тын калды. Тик командир авызында әлеге нечкә генә тавышлы курайның сыкрап кына моңайганы ишетелде. Аңа башка курайлар да кушылды. Үсә барды. Баштарак Галиябанунуың Хәлил гәүдәсе өстендәге актык җыры, актык мәртәбә йөрәк сыкравы күз алдына килде, аннары бу моң ниндидер икенче интонацияләр белән кинәт көчәеп китеп, башны югары күтәрергә, ирекккә ыргылырга, үч кайтарырга, утка керергә чакырды. Гаҗәеп, кайчандыр саф сөю рәхәтендә күгәрченнәрдәй гөрләшкән татар кызы белән татар егетенең иң бәхетле минутларында йөрәкләреннән түгелгән күңелле бер көй дип һич кенә дә әйтерлек түгел иде бу. Аның эчендә урыны белән бөтенләй икенче төрле яңгырый торган дәһшәтле кыллар да бар икән... Ул бары тик бер генә минутка сузылды. Шулай да мең мылтыклы залптан көчлерәк яңгырый сыман тоелды. Ул өзелгәннән соң, аның кайтавазын тыңлап калгандай, бөтен батальон беравык тирән тынлыкка күчте. Тик шуннан соң гына Актабанов, әкрен генә басып, солдат кәрәге алды һәм кабер эченә беренче балчыкны ыргытты. Калганнар да шуны үк кабат-

ладыі, һәркем ярты гына көрәк булса да үз өлешен салып калырга тырышты. Тигез җирдә озынча калкулык хасил булды. Бер башка кечкенә такта суккан казык утыртып калдырдылар. «Без сезне онытмабыз!» — дип язылган иде анда...

Кухня кешеләре чәй өлгерткәннәр иде. Һәр солдат берәр кружка кайнар чәй белән коры паегын чәйнәп алды да яңадан аякка бастылар. Батальон командиры әйтте:

— Урман серен немецлар әле белмиләр. Һәм таңга хәтле белмәүләре дә ихтимал. Шуннан файдаланып, без шушы төндә үк үзебезнең якка чыгып өлгерергә тиешбез. Туп һәм минометларның авырларын калдырырга туры килер. Төп корал — винтовка, пулемет, автомат. Патроннар — муеннан булсын! Азык-төлек һәм санчасть обозларын үзебез белән тарттырабыз — ышанычлык өчен яхшы булыр. Яралыларны, бала бишегедәй уртада саклап, җил-яңгыр тидерми алып чыгарга. Бу безнең изге бурыч. Хәерле юлга, иптәшләр!

Рота һәм взводларда да команда тавышлары тонык кына кабатланып узды. Мең кешелек батальон, урманның язгы тере гөрләвеге шикелле, агач араларыннан боргалана-сыргалана үзенә юл табып, төнге сәфәренә юнәлде. Һәртөрле көтелмәгәнлек, бәхетсезлекләр тулы караңгы урман эченнән, күлләр-баткакларны әйләнеп, кояш чыгышына таба атлый торгач, төнге икеләр җиткәндә дошманның эчке оборонасын уздылар. Монда эш кыен булмады, эчке оборона дигәннәре сыек иде, постовойларның йокылары да тәмле иде булса кирәк. «Зайнеген»[1] дигәч, «алгы сызыкка» дигәч, немец киемендәге бу колоннаны бик төпченеп тормыйча, уздырып җибәрделәр. Тышкы оборонаны аеруча сак һәм сиздерми капшарга кирәк иде. Батальон вак төркемнәргә бүленеп, ут нокталары, блиндаж һәм дзот араларын сайлый-сайлый, алга саркыла башлады. Төнге салкын чыктан тезләренә хәтле чыланган һәм авыр юлда болай да талчыккан кешеләргә бу хәвефле тирәләрдән артык киеренкелек белән атлау, сират күпере кичү шикелле, кыен һәм хәтәр булып тоелды. Хәтта, бер дә эссе булмаса да, әлсерәп төште алар. Шулай да актык җегәрләрен туплап, бер генә урында да эленке-салынкы сузылмыйча, бу шомлы ояларны җәһәт-җәһәт кенә сикереп узарга тырыштылар. Инде кешеләрнең байтагысы «иясез» зонага саркып өлгерде, командир Актабанов белән комиссар Габидуллин да алар арасында иде. Инде бәхет, җилкәңә килеп кунаклаган урман күгәрчене шикелле, колак төбендә генә сихри аваз белән гөрли иде. Инде солдатның байтагысы: «Исән-сау уздык бугай, тиздән үз якыннарыбыз белән күрешербез!» дип хыяллана иде. Ләкин дә алай ук була алмыйча калды шул. Кинәт уң флангта коры нарат ботаклары шытырдап сынгандай тавышлар ишетелде. Шуны гына көткән шикелле, бу коры тавыш бөтен сызык иңенә сикерде. Яшелле-кызыллы якты бөҗәкләр агыла башлады. Баш очында, колак төпләрендә яңа чыккан тычкан балалары чинаша кебек иде. Чучкадай улап килгән миналар, тимер чыңы белән һаваны кискән снарядлар гөрселдәп ярылырга тотынды. Батальон җиргә сеңде. Әмма таң алды караңгысында шуышып, агач төпләренә, чокыр һәм үзәннәргә посарга команда бирелмәде, каршы ут ачарга кушылды. Чөнки батальонның шактый өлеше һәм алар белән бергә яралылар обозы сызыкны узып бетмәгән иде әле. Аларны калдырмаска, ничек тә коткарырга кирәк иде. Ул ара да булмады, безнең яктан да давыл купты: батальон ике ут арасында калды. Баш калкыту мөмкин түгел иде. Комиссар, мылтык башына үзе ак чүпрәк бәйләп, бу якка өч парламентер җибәрде.

— Барыгыз, үрмәләгез, җылан булып шуышыгыз, ак флагыгызны болгаудан туктамагыз, тик белдерегез: «Үзебезнекеләр!» дигез...

[1] Үзебезнекеләр.

Алар кайтмадылар, тагын җибәрде, тагын кайтмадылар... Ут кызды. Кешеләр дистәләп кырыла иде...

Инде арбалардагы азык-төлекләрен әллә кайчан ташлап, кичке яралыларны төягән Арысланның бөтен атлары үлеп бетте. Арбалар ут эчендә туктап калдылар, яралылар кабат яраланып һәм күпләре үлеп баралар иде. Нишләргә соң Арысланга! Алай чапты, болай йөгерде, нииндидер усал кигәвеннәр әле ботын, әле балтырын, әле беләген, әле колак яфрагын ачы чеметтереп тешләп уздылар, моны абайларга вакыт та юк иде. Ул, арбалар өстенә мәһабәт калкан булып, үзе капланырга теләде. Тик файдасыз иде бу. Нишләргә соң Арысланга! Шуннан соң ул үз тирәсеннән узучы кешеләрне мылтык белән туктатып, арбаларга китерде. Һәркемнең җилкәсенә авыр яралыны кочтырды.

— Үрмәлә һәм алып чык! — дип әмер бирә иде ул.

Күрәсең, немецлар, я үзләре сизенделәр, яки хәбәр килеп җиткән булырга тиеш: үз формаларында булуга карамастан, икеләнеп тә тормыйлар — котырып ут ташкыны гына түгәләр. Ниһаять, Арысланның актык яралысы калды. Ул аны үзенең олы аркасына кочтырды да, озын буе белән мәһабәт кәлтә еланыдай житез боргаланып, төптән түмгәккә, түмгәктән иңкелгә поса-поса шуышып китте. Әлеге утлы кигәвеннәр һаман аның тирәсендә кайнашалар, һаман аңа гына ябырылалар кебек иде. Аркасындагы яралы солдат авыр бер ыңгырашып куйды, тагын да авырайгандай булды.

— Түз, җаным, түз әз генә, — дип пышылдый иде Арыслан. Әмма аркасындагы кеше шул ыңгырашудан соң җавап бирмәде, түзәргә булды, күрәсең.

Шулай мең кыенлыклар эчендә иза чигеп сугыша торгач, нииндидер могҗиза беләнме, әллә бетмәс-төкәнмәс яшәү инстинкты беләнме, ут өермәсеннән исән котылды ул. Кешеләр җыелган сайрак кына үзәнгә төште. Монда комиссар белән командирны да күреп алды. Яралыларны озатып бетерүе турында хәбәр итәргә теләп, җилкәсендәге кешене сак кына җиргә куйды.

— Менә кайтып та җиттек, дустым,— диде ул, чалкан яткан яралыга карап. Тегесе тагын эндәшмәде. Арыслан аның өстенә үк иелде. Күзләре йомык булуын шәйләде. Тиз генә маңгаена кулын куйды,-- суык иде, шул ук кулын яралының күкрәгенә салды — анда да суык иде. Тагын да иеләрәк төшеп, сулышын тыңлады: ул әллә кайчан үлгән иде инде...

— Эх, дускынаем, белтеки генә сабыр итсәң соң...— дип үкенеп куйды Арыслан, тирләгән бит һәм яңакларын учы белән сыпырып. Шунда учының канга буялганын күрде. Тагын капшангач, колай яфрагының йомшак ите өзелгәнен аңлады. Икенче кул аркасына да җиң эченнән нәзек кенә юл ясап, кан агып төшкән иде.— Карале бу нәләт кигәвеннәрне! — дигән булды ул.

Немецлар һаман шашынып ут яудыралар. Батальон төркемнәре, шушы кечкенә үзәнгә ышыкланып, экрен-экрен артка чигә, ут зонасыннан котылырга тели иде. Габидуллинның дүртенче тапкыр җибәргән кешеләре дә кайтмады. Тик шулай да безнең яктан ут кими төште. Егетләр барып җиткән идеме, әллә инде, немецлар уты безнең алгы кырыйга яумагач, анда тынычлана төшкәннәр идеме — билгесез. Тик бу хәл солдатларга бер сулыш алырга мөмкинлек бирде.

Актабанов өчен бәләкәй генә чокыр казылган. Бу аның команда пункты. Ул шунда чүгәләп, инде икенче тапкыр майор Краузеның картасын карый. Кесә фонаре төрле урында бии. Бая ялгышмадым микән, дип уйлый ул. Әмма ничә генә караса да ул картада бу урыннар юк икән шул, эләкмәгән. Инде нишләргә соң? Рельеф таныш түгел. Ләкин из, бик тиз моннан китәргә кирәк. Немецлар йөз-йөз илле метрда. Ут

ташкыны туктамый, кешеләр һәлак була, таң беленә башласа — бөтенләй хәрап! Үзән буйлап китсәң дә куркыныч, чөнки ул — ут сызыгына буйдаш яткан, яңадан алар өстенә килеп чыгуың яки мина кырына эләгүең бик мөмкин. Комиссар белән киңәш итте. Ул да яңа фикер әйтә алмагач, берәмләп йөгерү-үрмәләүләр белән үзәннең аргы ягына, снаряд һәм миналар ярылып торган ут мәйданына күтәрелүдән башка чара калмады. Кайсы якка борылсаң да бер үк хәл иде.

— Батальон! Берәмләп минем арттан! — дип кычкырды ул һәм алга йөгерде. Солдатлар аны капларга теләде, ләкин ул аларга таралырга кушты. «Барыгыз бергә үләргәме?» диде ачуланып. Дошман уты тагын да котырды. Миналардан башка эре калибрлы пулемет һәм автомат пушкалар уты аеруча җан койгыч иде. Арыслан шулай да аның артыннан калмаска тырышты. Азык-төлек запаслары теге якта ук калгач, озаткан яралыларның да күбесе ут кичкәндә һәлак булганлыгы беленгәч, ул бөтенләй эшсез кеше булып калган иде. Яралыларны озатып бетерүе турында доложить итәргә дә туры килмәде аңа. Нәрсә дип мактанасың?.. Үзенең «кигәвен тешләгән» җирләрен бәйләштерде дә солдат юлын дәвам итте.

Бер йөгереп, бер ятып, һаман Актабанов артыннан барды ул. Сул яктарак, башы кыелып төшкән юан агач күренде.

— Әнә шул агач төбенә тизрәк сыеныгыз! — дип кычкырды ул тыны-көне бетеп.

— Ориентиргамы? — дип көлде командир. — Үләсең килсә... — Һәм алга үрмәләвен дәвам итте. Һәр солдат аны күзәтә һәм артка калмаска тырыша иде.

Кинәт, баш очында гына, кадалып җиргә төшә торган берничә олы калибрлы минаның әшәке чыйкылдау тавышы ишетелеп калды. Алда, якындарак кына, кап-кара төтен һәм балчык гөмбәзләре күтәрелде. Бер минут чамасы җиргә сеңеп калган солдат төркеме шул урынга йөгерде. Бер үк чокырга икенче мина килеп төшмәячәген солдат яхшы белә бит. Озак та үтмәде, шул ук чокырга бит-күзләре кап-кара корым, балчык булган Арыслан да килеп төште. Үзенең легиондагы дусты һәм командиры Актабановны күтәргән иде ул.

— Әйттем бит мин сезгә, җыландай телләремне чыгарып әйттем...— дип офтана иде Арыслан.— Ниндәен әйбәт иде шул агач төбе кана...— Үзе мыгырданды, үзе тиз-тиз хәрәкәт белән командирның китель һәм эчке киемнәрен чишеп, ярасын ачты. Анда төерле-төерле кара кан, тетмәләнгән эч кисәкләре иде. Солдатларның кайбере үкси башлады. Арыслан ярсу күзләре белән аларга борылды:

— Нәрсә сез? Кечтеки балалар шикелле! Читкәрәк! — диде ул һәм тагын үз эшендә булды: умырылган бүректәй ярага бинт тутырырга теләде. Әмма анда олы бер ак җәймә тутырсаң да капланмас иде.

Шул ук минутта Габидуллин да чокырга сикереп төште һәм, командир каршына тезләнеп, пульсен тыңлый башлады. Медфельдшер килеп җитте. Кызыл айлы сумкасыннан әйберләр чыгарып, канны туктатырга тырышты. Тирә-як һаман гөрли иде. Фельдшер комиссар өчен генә башын чайкады: сүзсез дә аңлашыла иде бу...

Бераздан Актабанов күзләрен ачты. Зур тирән чокырдагы шактый кешене күреп, чыраен бозды.

— Нигә җыелдыгыз? — диде ул, әкрен генә, хәлсез генә тавыш белән.— Юлыгызны дәвам итегез... Боерам...— Күзләре тагын йомылды.

Солдатлар беравык эчендә тып-тын басып тордылар да, күзләрен җиргә төбәп, чокырдан чыгып киттеләр. Кычкырып елардай булып алга йөгерде алар.

*(Дәвамы бар )*

*Зыя Мансур*

## Маршак

Мин
Маршакны күрдем Ялтада,
Сәхнәдә ул
Шигырь укыды.
Зал шым иде,
Хәтта диңгезнең
Тынган иде кебек дулкыны.
Юк иде һич бүтән мәхәббәт,
Күзләр безнең тик бер аңарда.
Пәһлеванга, гүя, карыйбыз,
Очкын уйный, дөрләп, җаннарда.
Ә үзе ул,
Болай карасаң,
Чебеш кенә,
Ышан-ышанма,
Бер Леонид Соболев чыкмастыр,
Биш Маршакны бергә кушсаң да.
Әмма үтә,
Җитә йөрәккә
Шушы чәбек картлач аркылы
Гүзәллеге Шекспир сүзенең,
Бернс җырларының балкуы.
Бер карасаң,
Тын да алмый зал,
Бер карасаң исә,
Шундый хәл:
Күтәрелә алкыш,
Чатырдап
Яна башлый кебек бөтен зал.
Бар дөньяга мәшһүр талантлар,
Сүз куешып, гүя,
Бу көнне
Җыелган да әлеге сәхнәгә,
Чыгыш ясап тора шикелле.
Родарийлар һәм Ян Райнислар
Килеп баса безнең каршыга.
Киңлекләре
Олы дөньяның
Тагы да киңрәк булып ачыла.
Мең баһадир атлый, гүяки,
Яктыртышып
Барыр юлларны...
Ә үзе ул
Чәбек йөзле бер
Картлач кына иде нибары!..

1965.

## Хатын-кыз кардәшем

Дөньяның йөзләгән, меңләгән
Мәшәкать йөкләрен сөйрәгән,
Назласаң, назланып туймаган,
Булмаса, ялвара белмәгән
Хатын-кыз кардәшем, чәчәк син,
Кул тисә, черт итеп өзелгән,
Ник ләкин ут яумый, кирәктә,
Чыдам син җеннәрнең үзеннән!
Гөлләрем борлыга син юкта,
Әйләнә бар дөньям котыпка.
Нур белән, ямь белән тула Җир
Син кайтып, елмайган минутта!
Карыйм да, уйланып, сиңа мин,
Эчемнән тын гына сүз катам:
«И, хода, (ә үзем алласыз),
Аера күрмә, дим, бу заттан!..»

1965

## Бакчада

Им өчен бер яфрак күренми,
Урын юк хәтта җил үтәргә.
Алмалар тутырып, һәр агач
Берьюлы мең кәрзин күтәргән!
Утыра тик кысыр алмагач,
Яфракка күмелеп, бакчада.
Калтырый алмасыз, мескенем,
Юк кына җил килеп какса да...

1964

ӘХМӘТ ИСХАККА, ЯГЪНИ ХӨРМӘТЛЕ
МӘСӘЛЧЕБЕЗ КАРАХМӘТ АГАГА
60 ЯШЬ ТУЛУ УНАЕ БЕЛӘН

Тарих тугыз йөз дә бишенче ел,
Беренче Май. Халык һәр якта
Маевкага чыккан. Бөркет булып,
Җилләр уйный кызыл байракта.
Һәм Казанда, нәкъ шул көнне әнә:
Мин дә синең белән булам, Май,
Көрәшчеләр сафына теркә, давай,
Дигән кебек, туып, аваз биргән
Әхмәт атлы елтыр бер малай.
Тукайлардан күреп, бераздан ул
Кулына каләм алган, әлбәттә.
Һәм әйләнгән кешеләрнең аңын
Агартучы Кара Әхмәткә...

1965

## Шәфкать туташы

Шәфкатьсез утлы елларның
Юктыр истән чыгасы.
Дәһшәтле, авыр юлларда,

Тиң булып егет дусларга,
Барды шәфкать туташы.

Дошманга нәфрәт белән ул
Ярсыган иде тәмам.
Яраларны бәйли-бәйли,
Җиңүләргә әйди-әйди,
Юл ярды алга һаман.

Ягымлы, йомшак куллары
Килеп бер тию белән,
Җаннарга сихри көч кереп,
Без кабат торып өлгердек,
Кан йотып яткан җирдән.

Елмая инде тыныч көн,
Ямьле аның дөньясы.
Назлый кояш, әйтерсең лә,
Шат елмаеп, баш очында
Тора шәфкать туташы!..

1965.

## Минем адресым

Минем адресым:
Татарстан, Казан,
Комлев урамы, 17—17.
Хаҗәт булсам, шуңа карап, һәркем
Таба ала мине, билгеле.
Шушы адрес белән хатлар килә,
Хатлар белән килә мең хәбәр.
Хатлар, хатлар,
ә кем генә яза:
Бар яктан да эш, дип, мөгътәбәр?
Дөнья шул бу,
ә дөньяны әле
ышкыларга кирәк, җайларга.
Яза дуслар
һәм мин сүрелмәс бер
Җан дөрләве күрәм аларда.
Коткарырга тизрәк тырышалар
Җирне алар барлык чир-чордан.
Ә нәрсәдер җитми,
ә кайдадыр
Артык нәрсә килеп кысылган.
Эчләр яна,
тешләр шыгырдыйлар,
Җыенмыйлар юкны мактарга.
Зарлану күп
ләкин мин канәгать, —
Алдашу юк чөнки хатларда!

1965.

## Янар чәчәк

Янар чәчәк күрдем тауда мин,
Туңмый икән салкын карда ул.
Күзләреңнең явын алырлык
Кып-кызыл ут булып яна ул.

Һәртөрлесен күргән карларның,
Юк-бар җилдән курку аңармы!
Үзе эретеп бетерер кебек ул
Дөньядагы барлык карларны!

1964.

## Депутат

Сания ханым Сабировага.

Искитәргеч оратор дип,
Исәбем юк мактарга.
Һәм җыенмыйм, авызыннан
Сүз чыкмый, дип, таптарга.
Сөйли, әйтә үз карашын,
Җиткерә ничек тә ул.
Шакый да, ача да беләә
Күңелнең ишекләрен.
Кырда, цехта, юлда, залда, —
Көн вә төн кайный эше.
Уйлама, кереп чумар дип,
Тынлыкка мондый кеше.
Яши гел шатлык уятып
Һәм үзенең йөзе шат...
Хәер, гаҗәп эшме соң бу,
Булмый икән әгәр шундый,
Ник хаҗәт ул,
Мандат йөртү өчен генә
Сайланмый ич депутат!

1965.

## Әйтте Хәйям...

Әйтте Хәйям: ни мәгънә бар
Яшәү дигән вәсвәсәдән? —
Чебен кебек безлисең дә,
Җан бирәсең һәм вәссаләм...
Әбит Хәйям, ялгышмасам,
Туган моннан мең ел элек.
Ә ул язган робагыйлар
Йөри һаман дөнья гизеп.—
Ярап торыр иде әле,
«Чебен» булсаң шуның кебек!

1965.

## Зурлыйлар һаман Толстойларны...

Дөнья белә,
Камышлы кешеләрен түгел,
Толстойны, Руссо, Дюмоны...
*Әнвәр Давыдов.*

Зурлыйлар һаман Толстойларны...
Турысын гына әйтсәк бит әгәр дә,
Бар әле
Куйбышев өлкәсенең
Камышлы авылыннан
абзагыз Әнвәр дә!

Теркәмиләр нигә бер исемлеккә? —
Без генә
сыяр идек әле, ничек тә,
Толстой ише гигантлар сыйган ишеккә...
1965

## Җырчы арыслан

Нури ага Арслановка.

Арысланнар матур була,
Көчле була, хурламыйм.
Беләм мин бу батыр затның
Искитәргеч зурларын.
Күп ишеттем, дөнья бетереп
Үкерүен дә мин аның.
Юк иде тик уйлаганым:
Күрермен, дип, җирдә аның
Болай җырлый торганын!..
1965

## Китап киштәсе яки иске дус турында яңа җыр

Хатыны белән
Бик яман телгә
Килгән, нишләптер,
Бер дустым төнлә:
Җитте, дигән ул,
Аерылам синнән.
Теге бүлмәгә
Күчәм бүгеннән.
Ә син шушында
Кал балаң белән, —
Туйдырдың тәмам
Шул бәлаң белән...
Көтми бу хәтта
Көннең иртәсен,
Сүтә дә башлый
Китап киштәсен.
Терәлгән, гүя,
Бөтен эш шуңа.
Пыр да пыр килеп
Тузаннар чыга.
Китаплар ава
Өелгән җирдән.
Калтырый дер-дер
Түшәм вә идән.
Котыра кеше,
Җенләнә кеше.
Шул аның, гүя,
Иң изге эше.
Ә бит бер көндә
Ул моның ише
Егерме киштә
Ясарлык кеше!
Калдырмый ләкин,
Каерып ала...
Хәер, ник әле
Бәйләндем аңа?
Культурный кеше
Культурный инде.
Бүтән якларын
Ул күрми инде.
Культурный кеше...
Ә бит дуслар без.
Тагын ни булыр,
Тагын нишләрбез?
Уйласын, дидем,
Оялсын бераз.
Калмасын бездән
Әшәке мирас.
Һәм дуслар булгач,
Дус булыйк, дидем.
Чын дусларчарак
Эш кылыйк, дидем.
Һәм бик шәп итеп,
Кече бүлмәмдә
Китап киштәсе
Эшләттем мин дә.
Зур бүлмәмдәге
Киштәмдә инде
Урын ягы да
Чикләнгән иде...

Чакыртып алдым
Дустымны чәйгә,
Сайрашып, дидем,
Утырыйк, әйдә...
Яңа киштәгә
Карый дус кешем.
Аңламыйм, бу, ди,
Синең ни эшең?
Ә мин, берни дә
Белмәгән кебек,
Җавап кайтарам,
Тик эчтән көлеп:
Җилләр киредән
Исәләр кайчак.
Сак булу кирәк
Һәркайда, һәрчак.
Запас бер киштә
Эшләттем менә.
Хатын белән бит
Киленсә телгә,
Ташларга булсаң
Һич кичекмәстән,
Булмаса әгәр
Бер запас киштәң,
Каян алырсың,
Теге бүлмәдән?..

Ходай сакласын
Андый хәлләрдән!
Киштәсе киштә,
Ә намус кайда?
Хатының белән
Балаң бит кала...
Андый ахмаклык
Эшлисем юк һич.
Башыма әле
Тай типмәгән ич.
Адәм актыгы
Булсам да хәтта,
Юл тотмас идем
Мин андый якка!
Кулым салынган
Иңенә моның.
Сүз белән үзем
Вөҗданын туныйм.
Ни әйтергә дә
Кыймый әле ул.
Һәрьяклап үлчи,
Уйлый әле ул.
Йөзе агарган,
Күзләре яна.
Иске дустым ул,
Ә киштә — яңа...

*Касыйм Хәмзин*

# СОҢГЫ СЫЙ

## Хикәя

### I

Лядской бакчага [1] килгәч, Нигъмәтҗан калын өрәңге агачы янындагы озын эскәмиягә утырып, Газзәнең килүен көтә башлады. Алар һәрвакыт шушында очрашалар иде.

Ялгыз утырганда минутлар да сәгать булып тоелалар бит. Аллеяда йөргән яшьләр Нигъмәтҗанга карыйлар, гүя аның кемне көткәнен белгән кебек, елмаешып узалар иде. Егет үткән-барганнарга карамаска тырышты. Вакыт үткәрү өчен, кесәсеннән газета чыгарды. Бу инде уку түгел, күңел юату гына иде. Менә Газзә дә килеп җитте. Карт егеткә ул бүген кичәгегә караганда ягымлырак, матуррак булып күренде. Күргән саен Нигъмәтҗан Газзәдә бер яңалык ача иде. Бүген Газзә аны гаҗәп матур елмаю белән әсир итте. Нигъмәтҗан да елмаеп Газзәгә кулын сузды, утыр дип, газетаны эскәмиягә җәйде.

— Нигә .соңга калдың?

— Бер дә калмадым, үзең иртә килгәнсең, — диде Газзә.

Бу гади сүзләрдә әллә ни хәтле җылылык бар иде. Кичке әнгер-меңгер ара тиз үтте. Бакчага, урамнарга караңгылык төште. Төн карасы җиргә иңгән саен алар янәшәрәк, кысылыбрак утырдылар. Башта күргән-белгән, гомуми хәлләр турында сөйләштеләр. Ә бара-тора тик үзләре өчен генә әһәмиятле мәсьәләгә күчтеләр.

— Газзә, алма бизәкле күлмәк алдым мин сиңа.

— Нигә кирәк, нигә акча әрәм итәсең, юләр.

— Юләр булса да алдым, туй көнне киярсең.

Газзә ярты минут чамасы башын иеп, бармак очларына җеп чолгады, аннары сүтте. Шул вакыт югарыдан, баш өстеннән ниндидер кара кош очып үтте. Газзә сискәнеп китеп, агач башларына карады да:

— Ярканат очты, яхшылыкка түгел, — диде.

— Ташлале әбиләр гадәтен.

Нигъмәтҗан ялгызлыктан зарланды һәм, кызның аңламаганга салышып утыруын сизеп, кинәт:

— Газзә...— диде дә тукталып калды.

— Нәрсә? — дигән булды Газзә елмаеп. Ул Нигъмәтҗанның нәрсә әйтергә теләвен бик яхшы белә иде.

— Иртәгә ЗАГСка тәвәккәллик инде, озак йөрдек бит.

— Көзгә дип сөйләштек ич.

— Юк, хәзер, иртәгә.

Нигъмәтҗан туйны тизләтү өчен нигезле дәлилләр тапты.

Бу кичне алар озак утырдылар, һәм чынлап торып туйга әзерләнергә сүз куештылар.

Икенче көнне алар тагын шул ук урында, әлеге агач янындагы яшел буяулы озын эскәмиядә очраштылар. Ай әле калыкмаган, зәңгәр күктә йолдызлар гына яна иде.

— Газзә, әллә туй көнен тагын да якынайтыйкмы?

---

[1] Казандагы бер бакча.

— Сөйләштек ич инде. Июльдә. Минем укуым беткәч.
— Бик озак бит.
— Күбенә чыдаганны, азына гына чыдарбыз.
Ләкин язмыш кеше белән уйный икән.
Туйга санаулы көннәр калгач, 22 июнь иртәсендә радио дәһшәтле хәбәр китерде. Германия гаскәрләре безнең илгә һөҗүм иткәннәр иде.
Ирләр, егетләр, күп еллар буе тыныч яткан хәрби билетларын чалбар, күкрәк кесәләренә тыгып, шәһәр военкоматларына киттеләр. Нигъмәтҗан да чакыру кәгазе килгәнне көтеп тормады, документларын алып, Ирек мәйданы янындагы военкоматка барды. Ул килгәндә военкомат коридорлары халык белән тулган: бүлмәләрдә, кабинетларда моңа кадәр күренмәгән җанлылык сизелеп тора иде.
Нигъмәтҗан Кәбировны Казандагы бер батальонга җибәрделәр. Бер сәгать вакыт эчендә ул инде солдат иде. Бу үзгәреш шундый тиз булды, ул ни арада гражданский киемнәрен салып, яшел кием киюен сизми дә калды. Комиссардан рөхсәт алып, бер сәгать срок белән өенә кайтты. Бүлмә эчендәге әйберләрен җыештырды, гөлләрен күршеләргә бирде. Тәрәзә пәрдәләрен төшерде, мәчене коридорга куалап чыгарды. Зур йозак белән бүлмә ишеген бикләде. Күрше карчык янына саубуллашырга керде. «Бүлмәгә күз-колак булыгыз, апа, гөлләргә су сибегез, мәчене ашатыгыз. Хушыгыз. Исән булсак, бер кайтырбыз. Мине сорап килсәләр, фронтка китүемне әйтегез», — диде һәм, ике кулын сузып, күрше өйнең карты-карчыгы, кызлары белән саубуллашып урамга чыкты. Ул туп-туры Газзә торган квартирага китте. Ләкин Газзәне туры китерә алмады. Кайда булгандыр, нәрсә эшләгәндер, тик бүлмә бикле иде. Нигъмәтҗан борчылып, башын түбән иеп, батальонга кайтып керде. Шул ук кичне ул хәрби часть белән шәһәрдән китәргә тиеш иде.
Сугышның башында ук Нигъмәтҗан китеп барыр дигән уй Газзәнең башына да кермәде. Көннең беренче яртысын ул вак-төяк эшләр белән үткәрде. Бу явыз хәбәр аны тетрәткән иде. Ул көзге каршына басып үзенең йөзен, буен-сынын карады да урамга чыкты. Урамдагы кешеләрнең йөрешләре дә, сөйләшүләре дә башка көннәргә караганда ничектер үзгәрәк иде, аларның йөзендә, карашларында хафалану, борчылу сизелә иде.
Газзә беркемгә дә карамаска һәм тиз-тиз атларга тырышты.
Бу көнгә кадәр Нигъмәтҗанның бүлмәсенә барып йөрүне әхлаксызлык дип санаган Газзә бүген туп-туры аның квартирасына китте. Күп булса чирек сәгать вакыт үткәндер, ул инде тәрәзә пәрдәләре төшерелгән, ишеге бикләнгән буш бүлмә каршында тора иде. Күрше әби бүлмәдә кеше юклыгын аңлатып бирсә дә, Газзә һаман да ишек катында басып торды. Беркадәр вакыттан соң гына: «Хушыгыз, әби, гаепләп калмагыз», — дип чыгып китте. Искереп бара торган зур такта капка төбенә чыккач, аңына килә алмыйча, тагын бераз басып торды. Шуннан соң гына, як-ягына каранып, урам буйлап китеп барды.
Аның башында хәзер инде туй түгел, бәлки Нигъмәтҗанны соңгы тапкыр күреп, аның соңгы сүзен ишетеп калу иде. Зур шәһәрдә хәрби частьны табу җиңел эш түгел. Нәкъ кояш баеп килгән вакытта Газзә частьны тапты. Өч катлы кызыл таштан салынган бина биек койма белән уратып алынган иде. Тимер капка янында бер часовой егет басып тора иде. Газзә часовойдан ике сүз дә сорарга өлгермәде, зур капка ачылып китте. Ишек алдыннан взвод-взвод тезелеп өч төркем гаскәри кешеләр чыкты.
Менә ул — Нигъмәтҗан — беренче взводның арткы сафында бара. Артта булса да, Газзәне карчыга шикелле күреп алды. Елмаеп, аз гына алсуланып, әкрен генә: «Газзә», — диде. Аның күңеле нечкәреп китте. Нәрсәдер йөрәгең, бәгырен әрнетеп-әрнетеп алды. Үзенең хәзерге хәле чын түгелдер, гүя төштәге кебек генә тоелды. Чөнки ул ярты тәүлектә

булган үзгәреш һич табигый түгел шикелле иде, бу хәлгә ышанасы килми иде. Ләкин... ләкин бу инде чын иде. Моңа ышанырга кирәк иде. «Нигъмәтҗан!» — диде Газзә, аның белән янәшә атлый-атлый. Һәр икесе өчен дә мәсьәлә ачык. Хәзер инде Газзә дә сугышның чын булуына ышанды.

Взвод Пионер урамы буйлап тимер юл вокзалына табан юл тотты. Алар шактый вакыт бергә бардылар. Взвод командиры Газзәгә нәрсәдер ымлый. Әйе, китәргә вакыт, аерылырга вакыт.

— Көтәрсеңме, Газзә?

— Көтәм, Нигъмәтҗан!..

— Газзә, әгәр озак вакыт хатым-хәбәрем килмәсә...

— Нигъмәтҗан! Нигә ул сүзне әйтәсең, нигә бәгыремне теләсең?! Юк, юк, исән йөреп, сау кайт. Хуш, хуш, ак юл сиңа...

Кызның йөрәге чыдамады, ул атылып килеп Нигъмәтҗанны кочаклады, үпте һәм елап җибәрде.

## II

Ватан сугышы башланганга ике ай тулганда, Газзәгә өч хат килде. Өчесе дә кош теле кадәр генә, өч почмаклы ясалма конвертта һәм карандаш белән язылганнар иде. Беренчесе Суслонгер полигонынннан. Икенче хаты — юлдан. «Киттек, кая баруыбызны белмим, барып җиткәч адреслап язармын», — дигән иде. Өченче хат Новгород өлкәсе, Ильмень күле буеннан килде. Бу хат соңгысы булды. Шуннан соң Нигъмәтҗаннан ләм-мим бер сүз, бер хәбәр ишетелмәде. Әйтерсең лә, ул кайнап торган упкынга чумды.

Газзә укыган институтның бинасын госпиталь иттеләр. Газзә үзе дә шул көзне, беренче кар яугач, радист булып, үзе теләп армиягә китте.

Хатын-кыз ирләргә караганда да күбрәк уйланучан, хыял дәрьясына чумучан була бит.

Газзәнең дә башында шундый уйлар туды: «Кешенең язмышы белән эчке тойгы түгел, ә тышкы шартлар идарә итә икән. Әйе, кеше дигән исем бик зур, әмма ялгыз кеше бик кечкенә икән. Ул шаулаган диңгез өстендәге бик кечкенә көймә кебек айкала да чайкала, ә дулкын аны ярга китерә дә бәрә икән. Куркам, минем мәхәббәтем дә шулай булмаса иде...» — диде ул.

Газзә дә бер генә шәһәрдә, бер генә урында тормады. Атна саен яңа авыл, яңа шәһәр күрде. Полк, күчмә чегәннәр кебек, бер урында бер тәүлектән, бер атнадан артык тормый иде. Көндәлек ыгы-зыгы, яңа урыннар, яңа кешеләр, безнең гаскәрләрнең чигенү хәбәрләре күңелдәге мәхәббәт урынын ала башладылар. Нигъмәтҗанны сагыну хисе торган саен арткарак күчә барды. Беренче урынны ил кайгысы, илне саклау мәшәкате алды.

Кайберәүләр авырып, ә күпләр яраланып илләренә кайттылар. Газзә дә язгы көннәрнең берендә туган-үскән авылына кайтты. Ул кайтканда җиңү байрагы әле эленмәгән иде. Шулай да безнең гаскәрләр дошманның үз җиренә кергәннәр, безнең халыкның җиңеп чыгуында шик юк иде. Шәһәрләрдә тормыш авыр булганга күрә, Газзә авылга кайтты. Авылда аның бердәнбер карт әнкәсе яши иде.

Карт ана, кызының кайтканын гына көтеп торган кебек, икенчеме, өченчеме көнне авырып урынга егылды. «Башым әйләнә, күңелем болгана», — дип зарлана башлады. Кызының кайтуына атна-ун көн дигәндә үлеп тә китте.

Газзә ялгыз калды. Бик үк яңа булмаса да, аның өе, каралтылары бар. Нигъмәтҗаннын исән кайтуына аның өмете юк иде инде, ә гомергомергә бер ялгызың яшәп булмый. Кичләрен өендә бер үзе утырганда күптән сөйгән егетен күз алдына китерде, аның әйткән сүзләрен исенә төшерергә тырышты. Ләкин хәзер бу истәлекләрдән ни мәгънә бар иде

соң? Балаларча сокланып сөю вакыты инде үтеп киткән. Хәзер Газзә өчен көн итү, тормыш алып бару мәшәкате алга килеп баскан иде.

Аннан соң, һәр үткән көн, үткән ай яшьлекнең бер өлешен алып, аның урынына картаюлык билгесе тоттырып китә иде. Анысы белән дә хисаплашмыйча булмый иде...

## III

Сызгырып торган пуля, шартлаган туп тимәсә тими икән... Нигъмәтҗан нинди генә окопларда, блиндажларда ятмады, ничә мәртәбәләр һөҗүмгә, атакага бармады, нинди елгаларны кичмәде. Ничә мәртәбә чолганып, нинди боҗраларны өзмәде. Әсир булып дошман кулына төште, тоткында яшәде. Пленда Нигъмәтҗан күргәннәрне эт тә күрмәгәндер, исән калырга язгач каласың икән. Әллә кем әйтмешли, Нигъмәтҗанга чуртым да булмады. Сигез ел үткәч, әйләнеп шәһәргә кайтты да керде.

Күрше әби белән бабай да, сугышка киткәндә коридорга чыгарып калдырган мәче дә юк иде инде. Күршенең тәрәзә төбендәге зур-зур гөлләрне Нигъмәтҗан таный алмады.

Нигъмәтҗан матур бакча аркылы Газзә торган квартирага китте. Газзә белән утырган яшел эскәмияне, зур өрәңге агачын табарга тырышты, таба алмады. Сугыш елларында бу карт калын агачны да, яшел эскәмияне дә якканнар иде, күрәсең.

Нигъмәтҗан берничә секунд ниндидер каушау, икеләнү, шикләнү эчендә калды, аннары тиз генә Газзәнең квартирасына таба атлады. Әйе, күп сулар аккан, күп еллар үткән шул... Газзә шәһәрдән киткән булып чыкты. Аның турында күрше-тирәләрдән сорашса да, һичкем, һичнәрсә әйтә алмады.

Беренче көннәрдә ул электәге дусларын эзләп карады. Якын дусларының берсе Камил Якуб исемендәге типографиянең директоры Шәвәлиев Бәкер, хәрби комиссар, Ватан сугышында корбан булган иде. Елга техникумының директоры Хәмит Гумеров турында да һичнәрсә белмәделәр. Сугыштан соң, бер ай эшсез йөргәннән ары, Нигъмәтҗанны бер мәктәпкә директор итеп куйдылар. Көндәлек мәшәкать елларның бер-бер артлы тыгылып үтеп торуын сизәргә ирек бирмәде. Электәге кебек ул инде бакчаларга чыгып утырмый иде. Чит кешеләр белән очрашканда үзенең ялгыз яшәвен яшерә, ә хатын-кызлар белән күзгә-күз карап мәхәббәт турында сөйләшергә ояла, мәхәббәт еллары үзе өчен үткән дип саный иде.

Тик Газзә генә аның хәтереннән китмәде. Җылы, моңлы хис булып Нигъмәтҗанның күңел төбендә калды. Газзәнең яшел эскәмиядә утырган сыны һаман-һаман аның күз алдында тора иде.

Сугышка киткәндә бикләп калдырган зур чемоданны актарган чакта, киемнәр арасыннан, туй бүләге итеп бирергә җыенган алма бизәкле күлмәк аның кулына тиеп китте. Күлмәк яңа, бер бөртек кер тимәгән. «Газзә», — диде Нигъмәтҗан, һәм аның күңеленә әллә нинди хисләр килеп тыгылды. Ул көрсенеп, авыр сулап куйды. Әмма бара-тора бу күңел ярасы да басылды.

## IV

Бу еллар авыл хуҗалыгын күтәрү еллары иде. Нигъмәтҗан Кәбировны кичә райкомга чакырдылар. Иртәгә обкомда булырга куштылар. Сүз аны райкомның зона секретаре итеп тәкъдим итү турында барды. «Миннән нинди райком секретаре чыгар икән, характерым бик йомшак бит», — дип уйланса да, бу яңа исем аңа дәрт, көч, гайрәт кертте. Картаеп бара торган сөякләр дә әллә ничек яшәреп киткән кебек булды.

Анда-монда йөртеп берникадәр әвәләгәннән соң, Нигъмәтҗан Кәбиров райкомның зона секретаре булып сайланды.

Бүген Нигъмәтҗан беренче мәртәбә «Үзәк» колхозына килде. Бу колхоз үзенең җимеш бакчасы белән районда дан тота иде. Колхоз житәкчеләре белән агымдагы мөһим эшләр турында сөйләшкәннән соң, ул вакыт табып, колхозның җимеш бакчасын карарга китте. Бакчада көлтә-көлтә карлыган, кура җиләге, крыжовник үсә, алма агачлары тезелеп киткән. Шушы яшь агачлар арасында бердәнбер карт өрәңге агачы басып тора иде. Менә шул агач Нигъмәтҗанның күңелен гипнозлаган кебек үзенә тартты.

«Газзә!» — дип кычкыра язып дәшкәнен ул үзе дә сизми калды. Һәм як-ягына тиз генә әйләнеп карады, берәүнең дә булмавына шатланып, үзен шелтәләп алды. Берничә секунд эчендә күз алдында туган Газзә күләгәсеннән арынырга теләп, тиз-тиз алга атлады. Бераз барганнан соң карлыган агачы янына туктады. Карлыган инде чәчәген койган, җимешләнә башлаган иде. Берничә яшел җимешне учына салып тәгәрәтеп карады. Ул һаман да ниндидер тонык, күптән үткән күренешләр иркендә иде әле. Башын бераз иеп, учына салган җимешләргә карап торганда, әллә кайдан гына урта буйлы бер ир кеше килеп чыкты. Ул ак күлмәгенең итәкләрен чалбар эченә тыккан, җиңнәрен сызганган, башына ак эшләпә кигән, кулына чалгы тоткан. Йөзе ак, ябык, бит сөякләре беленеп тора иде. Корган яфракларны ала-ала, ашыкмый гына секретарьга таба атлады.

Яшел бакчага әйләнгән, «Дустан түбәсе» дип аталган бу җирне, икмәк уңмаган өчен, авыл картлары «алла каһәрләгән түбә» дип йөрткәннәр. Мәрдәновның (хәзер генә килеп туктаган әнә шул ак чырайлы кешенең) бу җирне җимеш бакчасы итәсе килгән. «Чабата туздырып йөрмә, булмый монда», — дисәләр дә, үз сүзле бакчачы чигенмәгән.

— Ун гектар җир билибез. Алма, карлыган, кура җиләген санап бетереп булмый, әнә карагыз, куе камышлык шикелле, иге дә, чиге дә юк, — диде Мәрдәнов.

Алар бакча эчләп әкрен генә атлый башладылар. Өскәрәк, тигез калкулыкка күтәрелделәр. Искиткеч күренеш. Ап-ак чәчәкләргә күмелгән алма агачларының яфраклары да күренми. Тоташ чәчәк.

«Менә нинди була икән ул алма бакчасы», — диде Нигъмәтҗан. Ул мондый бакчаны үз гомерендә ике генә мәртәбә күрде. Берсе сугыш елларында — Литва җирендә, икенчесе менә монда, «Үзәк» колхозында. Алмагачларны бал кортлары сарып алган иде.

— Ничә сорт? — дип сорады ул, сүз юктан сүз булсын дигән шикеллерәк итеп.

— Төрлесеннән бар. Менә Мичурин сорты, менә китайка, әнә күрәсезме, тегеләре антоновка, ак налив. Менә бусы — грушевка-московская, вообще, күп сорт бар.

Сүз артыннан сүз чыгып, гаилә мәсьәләләренә дә кагылдылар.

— Семьягыз бармы, бала-чагаларыгыз?

— Юк, мин ялгыз егет, — диде Нигъмәтҗан.

— Ялгыз уңайсыз инде ул.

— Уңайсыз да бит, нишлисең...

Бал кортлары, алмагачтан алмагачка очып, бал җыялар иде.

— Әйдәгез, иптәш Кәбиров, безгә, берәр чынаяк чәй эчәрбез. Хәзер төш вакыты, хатын мунча да ягырга булган иде, — диде Мәрдәнов.

Нигъмәтҗан: «Җәмәгатегездән яхшы түгел бит», — дип караса да, Мәрдәнов:

— Минем карчык — хәзерге заман кешесе, киң табигатьле, кунак көючән, бер дә тартынмагыз, — диде. Ун минут вакыт үтмәде, алар инде Мәрдәновның калай түбәле өе янында иделәр. Яңа өй, такта түбәле келәт, мал-туар абзарлары... Җил дә, чыпчык та керерлек түгел. Зур кол-

гага утыртылган сыерчык оясы, яшел рәшәткә, тәрәзә каршындагы чия агачлары бу йортка үзенә бер ямь бирәләр иде. Капка янында өч яшьлек кыз үзеннән аз гына кечкенә курчагын күтәреп уйнап йөри. Әтисен күрү белән, курчагының күлмәк чабуыннан эләктереп, аңа каршы йөгереп килә башлады.

— Бу минем кызым,— диде Мәрдәнов һәм кызын ике кулы белән күтәреп җилкәсенә утыртты. Баштан Мәрдәнов, аның артыннан Нигъмәтҗан өйгә керделәр.

Өй ишеге ачык, өйдә беркем юк. Мич буенда зур яшел сандык, түрдә сәке урынында аш өстәле, стена буенда тимер карават, ике тәрәзә арасындагы стенада көзге, почмак ягында кәкре борынлы җиз комган күренеп тора иде. Мәрдәнов җилкәсеннән кызын төшерде дә, почмак ягына кереп, самоварны җиңел генә ике колагыннан күтәреп икенче урынга куйды. Аннары: «Мин хәзер»,— дип, өй алдына чыгып китте.

Күп булса бер минут вакыт үткәндер, өй алдыннан ягымлы хатынкыз тавышы ишетелде. Хатынның тавышында иркәләү дә, үпкәләү дә, тиргәү дә сизелә иде.

— Китәсең дә югаласың, беләсең бит мунча якканны, әзерлән, әйдә, киттек, — диде.

— Ашыктырма, карчык, өйдә кунак бар, — диде Мәрдәнов.

Хатын мич артыннан гына почмак якка үтмәкче иде, кунакны күргәч, икеләнеп калды.

— Таныш бул, карчык, райком секретаре Нигъмәтҗан Кәбиров, — диде хуҗа һәм сөйләнә-сөйләнә чормага, яңа каен себеркесе алырга менеп китте. Күпме минутлар үткәндер, шул вакыт эчендә ике җан берберсенә карашып катып калдылар.

— Таныйсызмы? — диде Нигъмәтҗан, ишек янында басып торган хатынга карап.

Хатынның йөзе алсуланды, аннары агарып китте...

— Таныйсыңмы, Газзә? — диде Нигъмәтҗан, калтыраган тавыш белән. Ул үзенең табигый булмаган тавышыннан үзе дә уңайсызланды шикелле.

— Таныдым, Нигъмәтҗан... Ах, Нигъмәтҗан!.. — диде хатын, сүзләрен өчкә-дүрткә кисәкләп, һәм һушсызланып зур мичкә барып сөялде. Икесе өчен дә бу иң авыр минутларның берсе иде. Хатын сүзне ничек дәвам иттерергә белмәде. Әйе, хәзер инде Нигъмәтҗан аның өзелеп сөйгән егете түгел, тик очраклы кунак кына, райком секретаре гына иде.

— Ә үзегезнең җәмәгатегез, балаларыгыз бармы? — диде Газзә, шулай ук калтыраган әкрен, тонык тавыш белән.

Аның: «Бар, мин бәхетле», — дигән сүзне ишетәсе килде. Бу сүз, бәлки, Газзәнең йөрәк ярасына дару булган булыр иде. Ләкин Нигъмәтҗан:

— Юк, Газзә, мин карт егет булып калдым ахры инде, — дип көрсенеп куйды. — Борчылма, оныт, мин кичерәм, — диде.

Ул тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, нәкъ шул минутта кулына яңа яшь каен себеркесе тотып, Мәрдәнов килеп керде.

— Иптәш Кәбиров, яккан мунчага туры килгән икәнсез, әйбәтләп кенә, ашыкмыйча гына мунча керегез, сез кайтуга аш-су әзер булыр. Без соңрак та өлгерербез. Җәйге мунча тиз суынмый ул, — диде хуҗа һәм себеркене секретарьның кулына тоттырды.

Мунчага бәрәңге бакчасы аркылы гына үтәргә кирәк иде. Нигъмәтҗан, эчендәге утны тышка күрсәтмәскә тырышып, юл йөргәндә шактый керләнгән иске алып, Газзә әзерләгән мунчага китте. Бу мунча һәм мунчадан соңгы аш-су Газзәнең яшьлек дустына күрсәткән соңгы хөрмәте, соңгы бүләге иде.

●

# Очерклар

*Рафаэль Мостафин*

## ҖИРДӘ ЭЗЕҢ КАЛСЫН...

Кадерле редакция!

*Зинһар өчен, минем түбәндәге соравыма җавап бирсәгез иде: тормышның мәгънәсе нәрсәдә, әллә ул бөтенләй юк тамы? Китапларда бер нәрсә турында язалар, ә тормышта ул бөтенләй бүтәнчә. Нигә соң ул болай? Мин романтика, героик хезмәт, үз-үзеңне аямау турында бик күп китаплар укыдым. Ләкин тормышта андыйларны очрата алганым юк. Ә андый булмаганнар, тискәре кешеләр күпме телисең — һәркайда буа буарлык. Минә безнең күршедә генә бер кыз яши. Биш ел югары уку йортында укыды, дәүләт аңа никадәр акча тотты, ә ул алган һөнәре буенча эшкә китүдән баш тартты. Шәһәрдә калу өчен нинди генә хәйләләр тапмады, хәтта ялган документлар белән дә эш итте... Мин, гомумән, үз теләге белән шәһәрне ташлап, авылга, периферияга киткән кешене белмим. Андыйлар юк та ул. Киресенчә, һәркем һәртөрле юллар белән шәһәргә килеп урнашырга тырыша. Мәкальдәгечә, «Балык тирәнне, кеше яхшыны эзли», килеп чыга. «Үз күлмәгең үз тәнеңә якынрак», — дип юкка гына әйтмиләр шул. Кайчагында мин уйлап та куям: «Шулай да чын кешеләр, җирдә эзен калдыра алырлык кешеләр булырга тиештер бит инде дөньяда?» — дип.*

*Кадерле редакция! Минем бу сорауларыма җавап бирсәгез иде. Мондый сораулар бер мине генә түгел, минем иптәшләремне, барлык дус кызларымны да кызыксындыра. Без, унберенче класс укучылары, бу темага бик еш бәхәсләшәбез, ләкин бердәм фикергә килә алганыбыз юк.*

Сәлам белән **Наилә Д.** Казан шәһәре.

Хөрмәтле Наилә!

**«Казан утлары» журналы редакциясе сиңа җавап язу эшен миңа тапшырды. Мин журналда басылып чыгачак бу җавабымда гомуми сүзләрне, һәркемгә мәгълүм хакыйкатьне кабатламаска теләр идем. Аларны син үзең дә беләсең. «Гомер итә торгач, үзең барысын да аңларсың», — дип, син язган мәсьәләнең асылыннан читкә тайпылырга да теләмим мин. Чөнки моңа үзеңнән бурычны төшерү дип кенә карарга мөмкин. Әйе, сине һәм синең иптәшләреңне борчый торган бу сораулар сезнең яшькә җиткән бик күпләр алдына килеп баса. Һәм кеше тормыш китереп куйган бу сорауларга нинди җавап таба, тормышның нинди философиясен сайлый — күп вакытта аның киләчәктәге гомер юлы да шуңа бәйле була.**

**Синең хатың белән танышкач күп тә үтмәде, мин Кама буйлап сәяхәткә чыгып киттем: яшь шәһәр — Түбән Камада булдым, химия комбинаты төзелешен карадым, уннарча бик һәйбәт кешеләр белән очрашып сөйләштем, алар турында шактый уйландым. Мин анда, гигант төзелешләр барган урында, син очрата алмаган уңай мисалларны, героик хезмәт баһадирларын күп очраттым. Һәм алар турында сиңа сөйләп**

бирергә булдым. «Абстракт фикер йөртүдән бигрәк, тормыш үзе синең икеләнүләреңә яхшырак җавап булыр», — дип уйладым мин.

Гүзәл Каманың биек яры өстендә өч яктан да урман белән әйләндереп алган киң, тигез яланда шәһәр күтәрелә. Хәзергә әле андагы биналар төзелеш сәндерәләре эчендә. Анда да, монда да башня краннары укларын сузган, бульдозерлар, үзбушаткычлар гөрелтесе анда көнен дә, төнен дә тынмый. Шулай да югарыга омтылып күтәрелгән йортларда, культура-көнкүреш биналарында архитекторларның киләчәк заман шәһәре турындагы хыялларының гәүдәләнеше сизелеп тора инде.

Алсу, зәңгәр яки лимон төсендәге стеналы биш катлы йортлар, аларның төрле төскә буялган балконнары. Йортларга магазиннарның горизонталь яссы биналары сыланып тора. Кичләрен аның пыяла витриналары, асыл таш кырлары кебек, электр утларында җемелди. Яхшы итеп җиһазландырылган балалар комбинатларына зур шәһәрләр дә көнләшерлек. «Юность» кафесы да зур зәвык белән, заманча итеп җиһазландырылган. «Восход» кинотеатры архитектура формаларының тәгаллеге, гәүдәләнеше белән башкалабызның «Россия» кинотеатрыннан да калышмаслык.

Шәһәрдә чын мәгънәсендәге урамнар әлегә юк, ә йортлар һәр тәрәзәсенә кояш нуры төшәрлек итеп салына. Торак йортлардан читтәрәк зур магистраль үтәчәк, аның һәр ике ягында да яшел аллеялар үсеп утырачак. Бу шәһәрдә гадәттә зур шәһәрләр тирәсендә була торган күңелсез, бер катлы, ярым җимерек каралтылар, бараклар, коймалар бөтенләй булмаячак. Промышленность предприятиеләре шәһәрдән читтә салына. ТЭЦ сафка басканнан соң, шәһәрдә төтен чыгарып һаваны боза торган бер генә дә морҗа калмаячак. Монда һәр нәрсә, хәтта бакчалардагы эскәмияләрнең, газлы су сата торган киоскларның кайда куелачакларына кадәр, шәһәрнең архитектура йөзен бозмаслык итеп, баштан ук уйланылган. Моннан биш кенә ел элек бу урында шаулап иген үсеп утырганлыгына, шәһәрнең ул вакытта архитектор Е. И. Кутыревның проектларында һәм сызмаларында гына булуына хәзер ышанасы да килми.

Ләкин шәһәр табигатьтән тыш көчләрнең кодрәте белән бер селтәнүдә генә барлыкка килмәгән. Аны кешеләр салалар. Алар кирпеч белән бергә, таш белән бергә бу шәһәр биналарына, гомумән шәһәргә, үз күңелләренең, үз йөрәкләренең җылысын да салалар...

Менә урам буйлап, як-ягына чайкалып, мөлаем түгәрәк йөзле, кура җиләге төсендәге башлык кигән бер кечкенә малай килә. Әнисенең җитәкләргә дип сузган кулына тотынасы килми аның. Шулай булмыйча соң, балалар бакчасына юлны ул үзе дә белә ич. Аның артыннан иярик. Күз алдына стеналары мозаика белән бизәлгән балалар павильоннары килеп баса. Ике шук кына куян баласы зур гына кишер күтәреп баралар... Ә болары — төлкеләр. Менә монысы — төрле төстәге койрыгын киң итеп җәйгән тутый кош. Үзеннән-үзе бу павильоннарда күңелле балалар уены уйныйсы килә башлый.

Бакчаның эченә үтик. Эчтә дә стеналарга төрле рәсемнәр төшерелгән. Нәрсә генә юк монда. Бер якта — машиналар, экскаваторлар, күтәрү краннары, тракторлар. Безнең таныш малаебыз карандаш-кәгазь алган да, телен чыгарып, тырыша-тырыша стенадагы рәсемнәрне күчереп ясап утыра. Әйдә, аңа комачауламыйк, ул тормышны өйрәнә... Икенче як стенада — әкияттәгечә зур итеп төшерелгән алмалар һәм алар янында кыр казлары, аккошлар очып бара. Мондагы балаларны, тормыштагы беренче адымнарыннан ук, гүзәллек чолгап алган. Кешеләр аларга җылы һәм уңай булсын дип кенә тырышмаганнар, аларның фантазиясе үссен дип, зәвыклары дөрес формалашсын дип, дөньяны өйрәнүгә дәртләре тусын дип тә кайгыртканнар.

Бу әкият гүзәллеген кемнәр тудырган соң? Мондый матур рәсемнәр бер балалар бакчасында гына түгел бит, «Юность» кафесы да, «Кама» кибете дә шундый ук гүзәл итеп бизәлгән.

Бу сорауга Түбән Камада яшәүче һәркем җавап бирә ала. Ул рәсем һәм панноларның, стеналардагы бизәкләрнең авторы — художник Ника Платоновна Тилайко.

Мин аның белән моннан бер ел элек шушы ук Түбән Кама шәһәрендә очрашкан идем. Ябык кына, чәчен малайларныкы кебек кыска итеп кырдырган, тар балаклы чалбар һәм спортчылар свитеры кигән кара күзле кыз иде ул. Яше белән дә, мәгаен, синнән әллә ни олы түгелдер.

Мәскәүдә художество буенча югары уку йортын тәмамлагач, ул үз теләге белән монда килгән. Шәһәрдә, әлбәттә, художник эше таләп ителмәгән ул вакытта. Хәер, шәһәр әле үзе дә булмаган. Зур-зур нигез чокырлары да аннары төбесе ябылмаган берничә йорт кына булган. Әмма Ника аптырап калмаган. Кочегар булыпмы шунда, әллә берәр төрле техник булыпмы төзелешкә урнашкан да зур дәрт белән эшкә тотынган. Архитекторлар белән киңәшкән, төзүчеләр белән бәхәскә кергән, үзенә кирәкле буяулар һәм җиһазлар табып, стеналарга рәсемнәр төшерергә керешкән. Салкын баракта торган, тездән пычракта йөргән — ләкин үз дигәнен иткән.

Хәзер Тилайко Түбән Камада түгел инде. Ул хәзер Мәскәүдә. Ләкин аның биредә эзе калган. Түбән Кама кешеләре үзенең күңел җылысын биредә калдырган бу ябык, тыйнак батыр кызны озак вакытлар хәтерләрендә саклаячаклар...

...Минем игътибарны фортепьяно авазлары җәлеп итте. Башымны күтәреп карасам, стенада:

«ТҮБӘН КАМА БАЛАЛАР МУЗЫКА МӘКТӘБЕ»

дигән язуны күрдем.

Сораша торгач, бу мәктәпнең мин үзенә күрә бер романтик тарихы барлыгын белдем.

1961 елның көзендә Түбән Кама шәһәренә Мәскәүдән бер төркем яшь белгечләр килә. Мәскәү егетләре командировка яки министрлык направлениесе белән түгел, яңа шәһәр салу буенча бөтенсоюз конкурсында беренче бүләкне алган Е. И. Кутырев проекты белән кызыксынып, үзләре теләп киләләр. Аларны монда килергә өндәүче инициаторлары — Мәскәүдәге бер заводның инженеры Борис Перевалов була.

— Ник монда килергә уйладык дисезме? — дип, минем сорауны кабатлады ул (Борис Перевалов хәзер химкомбинат төзү базасының инженеры). — Моны ике-өч сүз белән генә аңлатып булмый. Җырда җырланганча, сервантлардан һәм тагараклардан ераккарак качасыбыз килде. Дөрес, безнең тагаракларыбыз юк иде әле, беребез дә семья корырга өлгермәгән идек. Әмма кайберәүләребезнең сервантлары бар иде инде. Кыскасы, чын эш эчендә кайныйсыбыз килде. Шулай булмый ни: без төзүче инженерлар бит. Менә мин тимер-бетон әйберләре заводында эшләдем. Эш кызыклы, мавыктыргыч, үз һөнәрем буенча, эшчеләр мине хөрмәт итәләр, начальство да эшемне күрә иде. Авырып китсәм яки болай гына эшкә чыкмый калсам да — сүз әйтүче булмас иде. Чөнки моның белән берни үзгәрмәс иде — бөтенесе үз җаена салынган, барысы да үз чираты белән бара... Кичләрен, минем бүлмәгә җыелышып, кая китү турысында уйлаша башладык. Кайда да булса, бөтенләй буш урында, кала салу турында хыялландык. Салыначак кала күренешен күз алдына китердек, төзелеш принциплары һәм планировкасы турында бәхәсләштек. Менә шулай яшәп ятканда очраклы рәвештә генә Түбән Кама проекты турында ишеттек. Проект безгә ошады — ул нәкъ без уйлаганча иде. Татарстан совнархозы белән бәйләнешкә кердек тә, кузгалдык та килдек.

Мәскәү егетләре нәкъ вакытында килеп җиттәләр — алар шәһәр салу эшен «0» билгесеннән башлап җибәрү бәхетенә ирешәләр, беренче йортларның нигезләре алар катнашында салына. Бу тирәләр аларны тездән пычраклы юллары, күзгә төртсәң күренмәслек төннәре, салкын бараклары белән каршы ала. Башта ачлы-туклы торырга туры килә, хәтта юынырга су да булмый: суны машиналар һәм тракторлар белән җиде километрдан ташыйлар.

— Мәскәүдәге эшләрен, квартираларын ташлап килгәннәр, янәсе, — диләр алар турында кайберәүләр. — Башкаланы бер караңгы почмак белән алыштырганнар, имеш. Ышандылар ди моңа! Берәр ел маташып карарлар да кире әниләренең итәге астына таярлар...

Ләкин мондый скептиклар ялгышалар: бер ел уза, ике, өч ел, ә Мәскәүлеләр китү турында уйлап та карамыйлар. Алар барысы да Түбән Кама кешеләре булып калалар, шәһәр салуда һәм химкомбинат төзелешендәге төрле участокларда җаваплы урыннарда эшлиләр, барысына да үз куллары белән салган йортлардан уңайлы квартиралар бирәләр. Алар китәргә җыену гына түгел, киресенчә, үзләре янына яңадан-яңа энтузиастларны «омсындырып» китерәләр.

Бер заман, Казанга командировкага килгәч, Борис Перевалов консерваторияда укучы кыз Эляны очрата. Кешенең бөтен тормышын астын-өскә китерә торган очраклы очрашуларның берсе була бу. Икенче, өченче тапкыр очрашырга да җай чыга. Казанга барып килү өчен Борис кечкенә генә мөмкинлекләрне дә читкә җибәрми. Ниһаять, беркөнне, бар кодрәтен җыеп, Борис аңа тәкъдим ясый:

— Эля, мин синнән башка яши алмыйм... Түбән Камага кил син. Өйләнешик. Миңа яңа йорттан квартира бирергә вәгъдә иттеләр.

— Ләкин бит... мин дә музыкадан башка яши алмыйм, — ди Эля, кыяр-кыймас кына.

— Ә син Түбән Кама музыкадан башка яши ала дип уйлыйсыңмы? — дип кызып китә Борис. — Киләчәк шәһәре, коммунизм шәһәре ничек инде музыкасыз яши алсын!

Борис бөтен инстанцияләрне йөреп чыга, Культура министрлыгына кадәр барып җитә һәм ахырдан үз дигәнен итә: Түбән Камада беренче йортларда тора башлау белән үк музыка мәктәбе дә ачыла. Башта мәктәп җәмәгатьчелек тәртибендә эшли, аннары тиешле штат расписаниесе дә килә. Борис музыка кораллары булдыру артыннан үзе йөри, торак йортының бер өлешен уку класслары итеп җиһазлау проектын да үзе төзи, Эля белән бергәләп, төзүчеләрне балаларын музыка мәктәбенә кертергә үгетли. Хәер, әллә ни үгетләргә дә туры килми — мәктәп, ачылган көннән башлап, тулы нагрузка белән эшли башлый. Хәзер монда ике класс эшли: баян классы һәм фортепьяно классы. Аларда җитмештән артык укучы музыкаль грамотага өйрәнә. Элеккеге бина укырга теләүчеләрнең яртысын да сыйдыра алмый. Хәзер музыка мәктәбенең укытучысы, Казан консерваториясендә читтән торып укучы Элеонора Михайловна Перевалова 260 урынлы ике катлы махсус музыка мәктәбе бинасының салынып бетүен түземсезлек белән көтә.

Әлбәттә, Борис һәм Эля булмаса да, Түбән Камада үз вакыты белән музыка мәктәбе ачылыр иде. Ләкин кайчан?..

...Шәһәрнең һәр почмагыннан күренеп тора торган бу тугыз катлы йорт турында читтән килгән һәркем сораша.

— О, бу атаклы йорт, комсомоллар йорты, — диләр шәһәр кешеләре, горурланып, — Түбән Камадагы беренче небоскреб. Аның турында китап язарга кирәк!

Барысы да комсомол җыелышыннан башлана.

— Менә без монда җыелышлар уздырабыз, членлык взнослары түлибез, вак хулиганлык белән көрәшәбез, — дип сөйли чыгыш ясаучыларның берсе. — Ләкин зуррак эш эшли алганыбыз юк. Кыен, дәртле, эз калдырырлык эш булсын! Беләсезме, һөҗүмгә баргандай хис итәсе иде, аңлыйсызмы?..

Икенче берәү торып баса. Салмак кына атлап трибуна янына килә. Көлемсерәп, залга күз ташлый.

— Һөҗүм, дәрт, эз калдыру... — дип сүз башлый ул, кинаяле итеп. Шунда ук кычкырып ук җибәрә: — Кешеләргә торырга урын юк, ә аңа, имеш, зур эш бир! Тулай торакка кереп карагыз, аның яртысында семьялылар тора. Тәртипмени бу? Ә яшь аналар балалар бакчасында урын җитмәгәнгә өйдә ятарга мәҗбүр. Эшче куллар җитмәве турында сөйлибез, төзелешкә көн саен яңа эшчеләр алабыз, ә дипломлы белгечләр бала карап өйдә яталар...

Көлү тавышлары, бер-берсенә кычкырып эндәшүләр аның сүзен бүлә:

— Турысын гына әйт: әллә өйләнергә уйладыңмы?

— Ә син дуга белән печән чапма: ул бер нәрсәне әйтә, син икенчесен...

— Син эш турында әйт...

— Дөрес сөйли ул!..

Трибунага төзелешнең комсомол штабы начальнигы Валерий Огородников менеп баса. Тавыш тынганны дәшми генә көтеп тора да, арттагы рәтләрдәге кемгәдер күз кысып, сүз башлый:

— Минемчә, чыгып сөйләүчеләрнең икесе дә хаклы. Бездә семьялылар өчен торак йортлар да, балалар бакчасында урыннар да әлегә җитеш түгел. Йортларны күп салабыз, ә халык көннән-көн арта бара. Бу бик дөрес. Шулай ук комсомол эшендә

вак-төяк белән күп булышуыбыз, яшьләрне зур, чын эш белән дәртләндерә алмавыбыз да дөрес бит. Ә безгә нигә мондый эшкә чынлап торып тотынмаска? Әйтик, үз кулларыбыз белән яңа өйләнүчеләр өчен йорт, балалар өчен бакча нигә салмаска! Җәмәгатьчелек тәртибе белән, эштән калган буш вакытларда...

Яшьләр бу фикерне хуплап каршы алалар. Шушы ук җыелышта җәмәгатьчелек тәртибе белән комсомол төзү-монтаж идарәсе оештыру турында карар кабул итәләр. Андагы барлык эш төрләре — штукатур һәм ташчылардан алып прорабларга кадәр — җәмәгать тәртибендә башкарылырга тиеш.

Башлангыч бер нәрсә, аны тормышка ашыру бөтенләй икенче эш.

Идарәне оештыруга трестта бераү дә каршы килми. Төзәргә телисез икән — рәхим итегез. Ә төзү материалларын каян алырга телисез? Ул объектлар бит планда каралмаган. Ә төзелештә аннан башка да төзү материаллары, бигрәк тә тимер-бетон әйберләре җитешми.

Валерий Огородников Түбән Камадагы төзелешне тимер-бетон әйберләре белән тәэмин итә торган Чаллы бетон заводына китә. Комсомолецларны, яшьләрне җыеп ачыктан-ачык сөйләшә. Җәмәгатьчелек тәртибендә балалар бакчасы һәм тугыз катлы йорт салачакларын һәм квартираларны иң яхшы төзүчеләр, активистлар арасында үзләре бүләчәкләрен әйтә...

Әлбәттә, кем каршы килсен инде мондый башлангычка! Чаллы заводында эшләүче яшьләр үзара киңәшәләр, исәп-хисап ясап алалар да җавап бирәләр:

— Бик шәп. Сезгә планнан тыш, эчке резервлар хисабына, тимер-бетон бирәбез. Ләкин цемент кирәк. Аннан башка берни эшли алмыйбыз.

Огородников Волгоград өлкәсенә — цемент заводына чыгып китә, анда бернничә комсомол җыелышлары үткәрә, заводның комсомол комитетын аякка бастыра, җитәкчеләрнең бусагаларын таптый — үз дигәнен итә, ниһаять, үзе әйтмешли, ике мең тонна цементны «сыгып» ала.

Ә кирпеч мәсьәләсенә килгәндә, бусы инде ул кадәр авыр түгел. Күчерүләр, бушатулар вакытында 40 процентка кадәр ватылуга чик куярга! Түбән Кама төзелешендә экономия һәм саклык өчен поход башланып китә, ә һәр экономияләнгән кирпеч комсомол объектлары салуда файдаланыла.

...Мин Түбән Камада вакытта бу йортның тугызынчы катын салып бетереп килаләр иде инде. Түбән катларда җыйнаклау эшләре бара иде. Көндезен анда тып-тын, кичләрен генә эш җанлана. Кая карама — һәр җирдә шау-шу, көлке, җыр, һәркемнең йөзе шат. Аларның инде салкында җиде сәгать эшләүләренә ышанасы да килми — куллары артыннан күз иярми.

Мин газета киоскасы сыман итеп урнаштырылган прораб бүлмәсенә кердем. Бүлмәнең эче көяз итеп җиһазландырылган, стеналары ике контраст төскә — акка һәм кызылга буялган.

Идарә начальнигы Саша Рогов, мин кергәндә, сызымнар корып уйланып утыра иде. Тугыз катлы йорт салу Түбән Кама өчен яңа, сыналмаган эш. Комсомолецларга монда да юл ярып барырга туры килгән. Әйтик, түшәм плиталарын утыз метр биеклеккә ничек күтәрергә? Моның өчен махсус краннар юк бит. Ә гади краннар бары тик биш катлы йортлар өчен генә ясалган.

— Ә ничек бу мәсьәләне хәл иттегез соң? — дип кызыксындым мин.

— Менә исәп-хисаплар, — дип Саша миңа сызымнар сузды. — Әгәр кран угын соңгы чигенә кадәр күтәрсәң, махсус җайланмалар ярдәмендә плитаны бер яктан салырга мөмкин була. Аннары кранны сүтмичә генә йортның икенче ягына күчерәбез һәм калган плиталарны шуннан салабыз...

Прораб бүлмәсенә төзүчеләр өзлексез кереп-чыгып торалар.

— Саша, теркәп куй әле, мин бүген дүрт сәгать эшләдем.

— Мин кичә килә алмаган идем. Балам авырды. Ә бүген алты сәгать эшләдем...

— Бик шәп, бик шәп, — ди Саша, башын кагып һәм «төзелешнең борт журналы»н ачып, кем күпме эшләгәнне билгеләп куя.

Виктор Гудков. Ул һәр көнне 4—5 сәгать эшли. Бер көн дә эшкә килми калмаган.

— Ул безнең монтажчылар бригадиры, — ди аның турында Саша. — Шәп егет. Зеленодольскидан килде.

Колотов Иван. Аның фамилиясе турысында гел җиделе саннар гына. Сашадан аның турында сорашам.

— Анысы — башня краны машинисты. Элек төрмәдә утырган. Аннан чыккач, тәзелешкә килде. Без аны үз яныбызга алдык. Хәзер танырлык та түгел үзен. Һәр көнне икешәр смена эшли. Бер сменаны хезмәт хакы өчен, икенче сменаны җәмәгатьчелек тәртибендә. Дөрес, аның семьясы әлегә баракта яши. Һичшиксез, аңа бу йорттан квартира бирәчәкбез...

Виктор Калинин, Якшыгул Миңлегулов, Александр Мосолов, Хәсән Хәлиуллин, Лев Башев... Аларның һәрберсе, сменалары тәмамлангач, биредә 4—5—6 шар сәгать эшли. Бәлки, чыннан да аларның исемнәре кайчан да булса мемориаль тактага язылыр һәм киләчәк буын кешеләре аларның хезмәт батырлыгына сокланырлар һәм алар тормышы турында материаллар җыйнарлар... Ә алар — әнә прораб булмәсенә җылынырга кергәннәр, электр миченнән чыккан җылылыкка кулларын сузганнар. Битләренә әле чынлап торып сакал-мыек та чыгарга өлгермәгән, сырмалары цемент измәсенә буялган, күзләре мут елмая. Йөзләренә карап әйтеп кара син аларга «геройлар сез» дип — көлкегә калдырырлар үзеңне...

Журналны актарып утырганда, шундый саннарны да күрдем мин: беренче карашка аларга кеше ышанмаслык!

Садыйков Рафикъ. Ташчы. 12 сентябрьгә каршы төнне 14 сәгать эшләгән.

Любимов Павел. Ул да ташчы. Шул ук төнне... 18 сәгать эшләгән.

— Бу ничек була инде? Әгәр кеше үзенең төп эшендә 7 сәгать эшли дибез икән, аңа тагын 18 не кушабыз да, туктаусыз 25 сәгать эшләгән килеп чыга түгелме соң?

Саша беравык уңайсызланып торды да:

— Әйе, — диде, — беләсегез килсә, шундый момент булды. Моның хезмәт турындагы законны бозу икәнен яхшы беләм мин. Бу хезмәт куркынычсызлыгы нормаларын бозу булып та чыга. Ләкин... Без аларны кайтырга кушабыз. Берәү дә китәргә теләми. Шулай итеп берәү дә китмәде. Бу көнне һәркем 12 шәр сәгать эшләде...

Әкренләп шулай сораша торгач, ул киеренке төннең картинасы минем күз алдыма килеп басты.

...Валерий Огородников ике мең тонна цемент «сыгып» алганнан соң, яшьләр тәзелешендә бетон мәсьәләсе хәл ителә. Бер көнне дә әрәмгә җибәрмичә, тоташ нигез плитасын коярга керешергә кирәк була. Ә күп катлы йортларны салуга керешү шуннан башка мөмкин түгел. Ләкин моны тиз эшләргә, бетон һәр урында да тигез катлык итеп эшләргә кирәк була.

Штурм көннең икенче яртысында башлана: шимбә көннең кичендә, якшәмбегә каршы төне буе эш бер минутка да тукталып тормый. Шоферлар белән алдан ук сөйләшеп куйган булалар — алар бу көнне ялдан да, күңел ачудан да баш тарталар. Бу өмәгә комсомолецлар — яшьләр генә түгел, олы яшьтәгеләр дә катнаша.

Бетон эремәсе узелына, бернинди тоткарлык килеп чыкмасын өчен, иң эшлекле, кыю комсомолка, тәзелешнең комсомол штабы члены Тамара Абрамова куела.

Һәм менә зур бетон килә башлый... Бик кызу төн була ул. Тәзелешкә берсе артыннан берсе машиналар агыла гына тора. Кешеләр нинди дер акыл ирешмәслек спорт азартына бирелеп китәләр. Бер төн эчендә 200 кубометрдан артык бетон салына. Бу сан барлык техник нормалардан узып китә.

Бетон салу таң беленә башлагач кына бетә. Өстән көзге салкын яңгыр сибәли. Җил көчәеп китә. Эш белән кайнарланган тәзүчеләрнең эчләренә салкын үтә башлый. Ләкин берәү дә өйгә ашыкмый. Тәзүчеләр, котлованга коелган бетон тирәсенә җыелып, аның куерганын, катканын көтәләр. Әйтерсең, бу нәрсә аларның карап торуларына бәйле.

Менә соңгы үзбушаткычлар белән бетон измәсе узелыннан Тамара Абрамова кайтып төшә. Кемдер аккордеон алып килә дә әкрен генә бер моңлы көйне сузарга керешә. Бу көйгә ияреп Тамара белән Саша бетон өстенә вальс биергә чыгалар. Алар

артыннан бетон өстендә беленер-беленмәс кенә эз кала. Шуны гына көткән кебек яңгыр да туктый һәм болыт арасыннан яңа чыгып килә торган кояш биючеләр өстенә үзенең якты нурларын сибә. Һәркемнең күңелен ниндидер ашкыну биләп ала. Һәркем елмая...

— Әйдәгез, дуслар, кайтырга күптән вакыт, — дип, Валерий Огородников аларны көчләп диярлек өйләренә озата.

Әле хәзер дә, бер елга якын узгач та, ул төн турында исләренә төшсә, яшь төзүчеләрнең күзләре ялтырап китә, йөзләрендә матур, күңелле елмаю балкый.

...Әгәр кешене хыялдан аерсаң, ул хайванга әверелә. Ул беркая да омтылмый, бернигә дә ышанмый, өметсез, яшәү өчен, ашау өчен генә яши.

Мин киемнәре цемент измәсенә буялган, йөзләре җилдә һәм салкында каралган, арыган егетләр һәм кызлар арасында утырам, аларның киләчәк турындагы эшлекле әңгәмәләрен тыңлыйм, алар белән бергә шатланам. Аларның хыялы бик конкрет. Алар тора торган йорт Түбән Камада иң матур, иң уңай булырга тиеш. Аның лифты да булсын, чүп-чар озата торган трубасы да булсын, һәр квартирада аерым ванналары, телефоннары да булсын. Ә идәннәр? Алар нинди булырга тиеш соң? Такта идәнме, әллә паркетмы? Әлбәттә түгел, ачык төсле, матур пластика булсын! Бүлмәгә кергән кешенең күңеле күтәрелеп китсен. Баскыч тоткалары да, ванна бүлмәләренең кирәк-яраклары да шулай ук пластикадан булсын. Аларны табу кыенмы? Ерунда! Әрмәнстандагы пластмасса заводы комсомолларына язабыз. Алар безгә ярдәм итмәс, дисезме? Әгәр шулай икән, бүтән җирдән табарбыз. Һәм һәр квартираның стенасын заманча итеп бизәрбез. Мещаннарча, бронза тәсендәге накат туйдырды инде.

— Ә ничек, дуслар, әгәр мебельләрнең дә типовойларын, секциялеләрен заказать итсәк, — дип, хыялланырга кереште арадан берсе. — Һәркем аларны үзенчә итеп җайласын, стиле белән дә һәркем өчен уртак, уңай булсын. Квартира баштан ук өр-яңа мебель белән җиһазландырылсын. Ачкычны аласы да кереп урнашасы! Шәп бит, егетләр, ә! Валерий, моны эшләп була бит!

Валерий Огородников бу нәрсәне чын-чынлап тормышка ашыру турында фикер йөртергә кереште:

— Рига мебель фабрикасына заказ бирергә мөмкин. Мондый зур заказлар алар өчен дә файдалы. Кредитка җайларга мөмкин. Әйтик, бер ел эчендә түләп бетерергә...

Ләкин, Наилә, син аларны, үзләре турында гына уйлыйлар икән болар, дип аңлама. Бу йорттан аларның барысына да квартира тимәячәк. Башкалар өчен дә кайгыртырга кирәк бит.

Ә аларның хыяллары бу йортка гына кайтып калмый; һәрберсеннән сорашып кара, берсе инженер-химик булырга һәм булачак гигант химкомбинатта эшләргә тели, икенчесе читтән торып төзелеш институтында укый, ә өченчесе кичке мәктәптә белем ала һәм беркемгә дә күрсәтми генә шигырьләр яза. Дүртенчесе музыка белән мавыга...

Мәсәлән, шул ук Саша Роговны алып кара. Аңа әле утыз гына тулып килә. Шуңа карамастан, ул инде техникумда укыган, Казан елга портын төзегәндә мастер булып эшләгән, армиядә хезмәт иткән, институтта укыган, Зәй ГРЭСын салуда катнашкан, аның беренче агрегатын ходка җибәрү вакытында шатлыклы минутларны кичергән, аннары инде — Түбән Кама химкомбинаты. Рогов бәхетле: язмыш аны бер удар төзелештән икенчесенә китерә. Әмма язмыш кынамы икән!..

Әгәр син Түбән Кама шәһәренә килсәң, әлбәттә, булачак химкомбинатның төзелеш мәйданын күрергә теләрсең. Монда эш шундый киң колач белән алып барыла, беренче килгән кешенең башы әйләнүе мөмкин. Цехларның, складларның, ректификацион колонналарның, продукт озату юлларының озынлыгын хәтта километрлап исәпләргә була. Болардан да битрәге, инде салынып бетеп ята торган ремонт-механика цехы зур соклану тудыра. Ул үзенең күләме белән иң зур завод корпусларыннан бер дә калышмый, ә техник җиһазлануы ягыннан фән һәм техниканың иң соңгы таләпләренә җавап бирә алырлык. Мондый зур масштаблы төзелештә читтән килгән кеше, ничектер, гүя көчсез бер җан иясе кебек булып кала. Идәндә кара елан кебек бөгәр-

ләнеп яткан электр кабельләре аша куркынып кына атлыйсың, әле анда, әле монда электросварка яшеннәре кабынып киткәндә, сискәнеп куясың.

Ә бу әллә ничә мең тонналы бинаһая зур корпусларны, әллә нинди чуалчык балкаларны шул ук Саша Рогов төзеган бит. Әлбәттә үзе генә түгел, үз участогы коллективы белән бергә. Ләкин бу төзелеш өчен җавапны иң элек аңардан сораганнар. Чөнки ул прораб. Трестта ул турыда сорап кара: Рогов участогы, Рогов төзегән, диячәкләр. Бу биналарга аның йокысыз төннәре, аның исәп-хисаплары, акылы, көче тупланган. Аларда аның эзе калган.

Саша Роговның китап шүрлегендә аның яраткан шагыйре Сергей Есенин томнары белән бергә, төзелеш эшләре буенча калын-калын китаплар тезелеп киткән. Кичләрен аның тәрәзәсендә бик озак вакыт ут сүнми — Саша махсус журналлар укый, бик күп хәл ителәсе проблемаларга җаваплар эзли.

Саша минем белән үзенең бер мөһим хыялы турында уртаклашты — ул комбинат төзелешенә челтәрле график буенча автоматлаштырылган график кертергә тели. Әллә никадәр вакыт ул миңа бу системаның асылы турында сөйләде. Ләкин мин шуны гына аңлый алдым: бу алым яңа, моңа кадәр әле Советлар Союзында бөтенләй диярлек кулланылмаган бик прогрессив алым икән. Ләкин бик катлаулы икән, бу графикны төзү өчен электрон-хисаплау машиналары кирәк булачак икән.

— Ә ул машиналарны кайдан алырга уйлыйсыз соң?

— Хәзерге заманда бу мәсьәлә катлаулы түгел. Әйтик, Казан университетында электрон-хисаплау техникасы тулысы белән үк файдаланылмый. Телетайп урнаштырабыз да төзелешнең үзеннән хисаплау машиналарына мәгълүматларны тапшырабыз һәм шул ук юл белән әзер җавапларны алабыз...

Институтта алган белем генә аның өчен инде җитәрлек түгел. Саша аспирантурага керү турында да хыяллана. Аннан соң инде төзү эше турында үзенә дә яңа сүз әйтергә мөмкин булачак. Сашаның тәҗрибәсе җитәрлек, язылачак диссертациянең дә төп нигезе төсмерләнгән. Ләкин Саша бу турыда бик җәелеп китми, чөнки моңа кадәр шактый эш бар әле...

* * *

...Мин сиңа, Наилә, Түбән Камага сәяхәтем вакытында үзем күрә алганнар турында гына сөйләдем. Чын кешеләр бармы икән җирдә?! Сикелтәле юллар романтикасы, киләчәк өчен героик хезмәт бармы? Әллә инде һәр кеше үзенең шәхси интереслары турында гына уйлыймы? Болар турында үзең нәтиҗә ясa. Тормышның мәгънәсе дөньяны гүзәлрәк, тагы да ямьлерәк итү өчен көрәште түгелмени?!

Борынгы Көнчыгыш халыкларында шундый мәкаль бар: һәр кеше үз гомерендә йорт салырга, агач утыртып үстерергә, кеше тәрбияләргә тиеш. Мин югарыда сөйләгән Түбән Кама тормышында, минемчә, тирән мәгънә ята, андагы кешеләр җирдә үзләренең эшләрен калдыралар: гигант химкомбинат һәм өр-яңа шәһәр салалар, кешеләргә гүзәллек, ямь бүләк итәләр, кешенең бәхете, аның киләчәге турында кайгырталар.

Мин ышанам, Наилә, син, игътибар беләнрәк карасаң, андый кешеләрне әйләнатирәңдә дә күп күрерсең һәм икеләнүләреңә, борчыган сорауларыңа чынбарлыкның үзеннән җавап та таба алырсың.

●

*Шәукәт Галиев*

## Дүрткүз ник койрыксыз?

Дөбер-шатыр бер-бер артлы
Машиналар үтәләр,
Ә кешеләр тротуарда
Яшел утны көтәләр.

Дүрткүз ахры берни белми
Светофорлар хакында,
Кызыл утка карамыйча
Чаба урам чатында.

«Тукта!» дигәнне ишетми,
Аргы якка ашыга.
Машиналар агылалар
Уңда, сулда, каршыда.

Бөтерелә-бөтерелә
Көпчәкләр арасында,
Куркудан коты алынган
Маэмай да бара шунда.

Күпме генә омтылса да
Үтәр урын тапмады.
Иң соңгы бер машинага
Бәрелде дә тапталды...

Кызганудан күзне йомдык,
«Ah!» дип кычкырып куйдык.
Карасак, үзе исән, тик...
Өзелеп калган койрык.

Дүрт күз булып күрмисең, дип
Дүрткүзне мин орышам,
Светофорның ни икәнен
Аңлатырга тырышам.

Күпме генә өйрәтсәң дә
Төшенмәсләр маэмайлар.
Тик истә тотсыннар моны
Кызлар белән малайлар!

## Ике төрле Тәүфикъ

Мәктәптә безгә еш кына
Күрсәтәләр Тәүфикъны
Һәм мактыйлар:
— Ул тәүфикълы,
Бер дә бозмый тәртипне.

Кызлар белән дә тату бит,
Мөгамәлә матур бик —
Ялгыш кына кагылса да:
— Кичер мине, гафу ит...

Директор да күргән икән,
Үрнәк итеп китерде.
Кайсыннан үрнәк алыйк соң —
Тәүфикъ бит ике төрле?!

Берсе аның дәрес тыңлый
Тыныч кына утырып,
Икенчесе, астан гына,
Чемета борып-борып.

Берсе «Рәхим итегез!»не
Сүз аралаш кыстыра,
Икенчесе тел күрсәтеп,
Аяк тибеп кычкыра.

Тәртипле дип әйтсеннәр дип
Шулай итенгән була —
Юри аякка баса да,
Гафу үтенгән була...

Бер Тәүфикъта — ике Тәүфикъ,
Шулай яши ул һаман,
Тыштан күренгәне яхшы,
Астыртыны бик яман.

Беркөн әйттек: кирәк икән —
Икегә ярыл, дидек,
Әмма икенче Тәүфикътан
Ничек тә арын, дидек.

Беренчесе, ярар, диде,
Бу сүзләрне ошатты.
Икенчесе йодрык төйни —
Кабул итми бу шартны!

## Энә карагы

Күрдем энә карагының
Зарланып елаганын:
— Карак, диләр, ә бит минем
Юк энә урлаганым!

Нәсел-нәсәптән берәрсе
Фаш булганмы тотылып?!
...Яман исем бер ябышса
Булмый шул тиз котылып.

## Бәхет ачкычы

Рәшат яңа әкиятне
Тыңлап-тыңлап тора да,
Бәхет ачкычы яса дип,
Әтисен аптырата.

Әтисе чүкечен бирә:
— Бу, — ди, — бик ансат кына —
Гомер буена тырышсаң
Заводта ясап була.

Әмма һәркем үз ачкычын
Тиеш үзе ясарга,
Шунсыз һич тә мөмкин түгел
Бәхетеңне ачарга!

## Мәүлихан

Без кырда бәрәңге алдык,
Мәүлихан кырын ятты.
Төшкә таба кар очты да
Һаваны салкынайтты.

Тешләре тешкә бәрелә,
Иренчәккә нишләргә?
Чыдамады, аптырагач
Мәҗбүр булды эшләргә!

## Уяулык

Ике яктан ике бозау
Сыерны дер селкетә —
Чапылдатып йолкый-йолкый
Имәләр төртә-төртә.

Шәһәрдән кайткан Эльвира
Куркып кычкыра башлый:
— Әни, әни, тизрәк коткар,
Бозаулар сыер ашый!

## Солдатлар үткәндә

Шап-шап атлап, тигез басып,
Дөп-дөп кагып барабан,
Солдатлар безнең урамнан
Җырлап үтеп баралар.

Үзе дә сизмәстән Вахит
Маршка басып бара;
Ыштанын да онытмаган —
Иңенә асып бара!..

## Кайнар коймаклар

Чаж да чож майда сикертеп
Әни коймак пешерде,
Әбием белән бабайны
Шул чак искә төшерде:

— Бар, йөгереп кенә, бәбкәм,
Җәһәт кенә илтче, ди,
Кайнарлата иң әүвәле
Алар авыз итсен, ди.

Ярар, дидем, булыр, дидем,
Тормадым озак уйлап,
Кулда табак тулы коймак,
Йөгердем урам буйлап.

Югары оч ерак түгел,
Кайнар чакта җиткерәм!
Тыкрыктан борылгач та
Алдымда зур эт күрәм...

Бияләй хәтле телләре
Җиргә чаклы салынган.
«Коймак... әби... суына», дип
Үтмәк булам янынnан.

Эг өрми дә, җибәрми дә,
Тукта, котылыйм сыйлап —
Чеметеп кенә тоттым да,
Күккә чөйдем бер коймак.

Бозау чаклы әлеге эт
Сикерде дә һап итеп,
Җиргә дә төшерми генә
Капты алды шап итеп!

Баш бар инде үземдә дә,
Бигрәк тә кызык иттем —
Коймак белән алдап-йолдап
Бабайларга да җиттем.

«Кайнар коймак китердем» дип,
Йөгереп түргә уздым,
Тастымал япкан табакны
Әби алдына суздым.

Буш табакны күреп бабай
Тора кеткелдәп көлеп.
Ике битем кайнарланды
Нәкъ ике коймак кебек...

Тыңлап-тыңлап тордылар да,
Елама дип, сөйделәр;
Син безгә ул коймаклардан
Кадерлерәк, диделәр.

Әле үзең котылгансың,
Исән калгансың, диләр;
Үгез хәтле этне дә син
Алдый алгансың, диләр.

Ә үземә, кыстый-кыстый
Кыстыбый ашаттылар.
Буш табагыма да өеп,
Өемә озаттылар.

Үзебезгә кайткан чакта
Бабаем да иярде:
— Коймак өстенә кыстыбый
Эт эченә тияр, ди.

Кайнар коймак ашарга да
Өйгә кайтып өлгердем.
Мин алдаган этне сөйләп
Бабай кат-кат көлдерде.

Әти-әни алларыма
Кайнар коймак өяләр:
— Син безгә барлык әйбердән
Кадерлерәк, — дияләр.

## Балыктан кайткач

Кайчак балыкчы бәләкәй
Ташбаш каптыра, диләр,
Шуны да, чуртан иттереп,
Сөйләп арттыра, диләр.

Мин арттырмыйм. Шикләнгәннәр
Бер тыңлап карасыннар:
...Бардым. Салдым кармагымны
Болытлар арасына.

Тилгәннәр әйләнеп йөри
Калкавыч асларында,
Бәртәсләр өере йөзә
Ак каен башларында.

Самолетлар күрәм дә мин
Чабак диеп ымсынам.
Баш әйләнеп, төпсез күккә
Төшеп китәрмен сыман...

Кинәт кенә болытларны
Вак дулкыннар таратты —
Тырпылдатып тартып алдым
Шуннан кызылканатны!

Сизәм инде, баш чайкыйсыз —
Әкият сөйлим, янәсе!
Суда ич болар һәммәсе —
Болыт, каен шәүләсе...

Барсаң, елга көзгесендә
Үзеңне дә күрерсең —
Астан өскә карый-карый
Башың белән йөрерсең!

## Уң кул белән Сул кул

Чүкеч тә тота Уң Кул,
Пычкы да тота Уң Кул,
Яшьтән эшкә көйләнгән,
Өлгерлеккә өйрәнгән.
Ни тотса да булдыра.
Кайчак эшли ул гына,
Тик кенә тора Сул Кул,
Бик оста түгел шул ул.
Аз-маз кузгалган итә,
Арый да читкә китә.
Белми калган күп эшне,
Тота алмый чүкечне.
Сугам дисә кадакка,
Эләктерә бармакка.
Каләм тотса әкәмәт —
Йөри гүя мүкәләп...

Уң Кул эшли тырышып,
Сул Кул йөри булышып.
Кайсы ничек эшләгәнне
Кешеләр онытмыйлар,
Соңыннан Уң Кулны кысып,
Рәхмәт әйтеп котлыйлар.

Сызым да сыза Уң Кул,
Шигырь дә яза Уң Кул.
— Үзең ни дисең Уң Кул?
— Сау булсын дустым Сул Кул.
Без бергә чакта көчле,
Башкарабыз бар эшне!..

## Сер бирми

Күрше авыл елгасы
Тирән дә соң, зур да соң!
Малайлары үртиләр:
— Чын елганы күр, диләр.
Сезнең инеш тар, диләр,
Тавык та атлар, диләр...

Ә Шәвәли килешми,
Күршеләргә бирешми:
— Безнең су — нәни инеш,
Сезнеке — елга, имеш!
Мактанмагыз сез алай
Киң булса да ул бит сай.
Казның түшеннән генә,
Шушы төшеннән генә!..

## Ясыйр

Йокыдан торгач Ясыйр
Көн дә зарядка ясый.
Ясый бик тә яратып,
Бар дөньясын онытып.

Бер урында атлап-атлап
Каядыр барган итә,
Ух-вух килеп, киерелеп
Утын да ярган итә.
Бер кузгалып, бер тукталып
Яңадан йөреп китә —
Себеркесен селтәп-селтәп
Себергән кебек итә...

Шулай зарядка ясый,
Юына, шәпләп ашый.
Һәм хәлдән таеп, арып,
Ава ышыкка барып.
Шелтәли ул әтисен,
Шелтәли ул әнисен:
— Файдасын аңламыйсыз,
Зарядка ясамыйсыз!
«Кайчан культура керер?!» — дип,
Ята Ясыйр орышып.
Әти-әни җир себерә,
Утын яра тырышып...

## Калай бәпкә

Катык ашап тазарырга
Гәүһәр кайткан авылга.
Гәүһәрнең бар бәпкәсе,
Алып биргән әткәсе.
Ачкычы бар борырга,
Кызык карап торырга —
Чайкалып чак-чак кына,
Атлый ул вак-вак кына.
Сап-сары икән үзе,
Зәп-зәңгәр икән күзе,
Кып-кызыл тәпиләре,
Кара әле, кил әле!

Нурулла шаккатмады,
Гаҗәп нәрсә тапмады:
— Үзең кара яхшылап,
Минекеләр яхшырак!

Сәке астына кереп
Алып чыкты зур бүрек.
Гәүһәр моны көтмәгән —
Бүрек тулы бәпкәләр!
Кагынып, ши-ши килеп,
Чыкмакчылар сикереп.

Өч көннән соң аларны
Ияртте аналары.
Бик өлгерләр, бик тизләр,
Бик чаялар, житезләр,
Һич туктамый торганнар —
Ай-һай каты борганнар!
Гәүһәр боларга гашыйк:
— Әйдә, абый, алмашыйк!

●

Нил Юзиев

# СҮЗ ЧЫГАР ШАГЫЙРЬЛӘРДӘН ХИКМӘТ БЕЛӘН...

*(Хикмәтле сүз һәм чәчәнлек)*

Акмулла үзенең бер шигырендә болай дип яза:

Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән,
Анча күз алартмагыз хиддәт белән...
Һәр фәндә шигырь белән китап тулы,
Карасак, иялә(ре) кандай олы.

Акмулланың бу шигыре поэзиянең тормыштагы ролен күтәрүе, шигъриятне һәртөрле надан руханилардан яклавы ягыннан бик тә әһәмиятле. Ләкин шигырьнең мәгънәсе моның белән генә чикләнми. Ул татар һәм гомумән төрки шигъриятенең үзенчәлекле бер сыйфатына да ишарә ясый. Бу — шигырьнең хикмәтле сүз буларак корылуы.

Борынгы һәм урта гасыр төрки әдәбияты турында язылган хезмәтләрдә күп галимнәр шушы үзенчәлекне билгеләп үтәләр. Акыл поэзиясенә, рационализмга, үгет-нәсихәтчелеккә корылган әсәрләрне алар дидактик әдәбият дип атыйлар. «Дидактик поэзиянең нигезен, — дип яза әдәбиятчы Ә. Харисов, — тормыш һәм табигать хакында уйланулар, философик яки дини фикер йөртүләр тәшкил итә» (Ә. Харисов. Үткәнгә сәяхәтләр. «Агыйдел» журналы, 1965 ел, 5 сан, 76 бит). Күрәсез, шушы бер термин фикергә, акылга, фәлсәфәгә нигезләнгән барлык төр әсәрләрне берләштерә. Ләкин акыл, фикер шигъриятенә корылган барлык әдәби әсәрләрне дә шушы термин эченә сыйдырып бетерү үткән әдәбиятны бөтен байлыгында күрсәтергә, аның үзенчәлекләрен ачарга комачаулый дә. Д и д а к т и к а сүзе, үзеннән-үзе, аның бер ягына — нәсихәт рухында төзелгән шигырьләренә, әсәрне әхлак өйрәтү рухында төзү принципларына юнәлтә, фикер поэзиясенең башка якларын һәм башка үзенчәлекләрен йомып калдыра.

Кайбер башка әдәбиятчылар да борынгы һәм урта гасыр әдәбиятындагы дидактик шигырьләрне коры «акыл сату»дан ары китмәгән, «примитив поэтикалы салкын бер нәсихәт» рәвешендәрәк, сәнгатьчә шигырьләрдән берничә баскыч түбәнрәк торган әсәрләр рәтендә бәялиләр. И. Нуруллинның «XX йөз башы татар әдәбияты» (1 кисәк) китабында, татар әдәбиятында критик реализм тамыр җибәрүгә бәйле рәвештә, әдәбиятта дидактизм, рационализм, үгет-нәсихәтчелеккә каршы кискен көрәш башлануы бик матур ачылган. Бу бездә критик реализм формалашуының үзенчәлекле бер сыйфаты. Шулай да, критик реализм дидактизм әдәбиятын бөтенләе белән инкарь итәр микән — бу мәсьәләдә И. Нуруллин белән килешүе авыр. Алар к а р ш ы л ы к л а р б е р д ә м л е г е н төзиләр. Дидактик әдәбиятның аерым иҗат принципларын, фикер поэзиясенең гасырлар буенча формалашкан аерым төрләрен һәм традицияләрен критик реализм шагыйрьләре үзләштереп, үстереп, дәвам итеп тә киталәр. Ул традицияләр социалистик реализм хәзинәсендә дә билгеле бер урык алып торалар. Алар бик яшәүчән традицияләр. Көчле һөҗүмнәргә карамастан, Тукай да, Гафури да,

Җәлил'дә дидактик, хикмәтле шигырьләр язудан туктамадылар.

И. Нуруллин үгет-нәсихәтчелек, рационализмның яшәүчәнлеген «искенең яшәүчәнлеге, тиз генә аренадан китәргә теләмәве, әдәби зәвыкларның яңарып өлгерә алмавы, каләмгә ябышкан бик күп яшьләрнең, әдәбиятта яңа юл салырга сәләтсез булып, үткәндәге әдәби эстетик принципларга ябышып ятуыннан килә», дип карый (шунда ук, 79 бит). Бу фикердә өлешчә дөреслек тә, шулай ук мәсьәләгә берьяклырак килү дә бар.

Борынгы яки урта гасыр татар әдәбияты турында сүз барганда, еш кына аның поэтикасының үзенчәлекләрен һәм чыганакларын гарәп яки фарсы әдәбияты йогынтысына кайтарып калдыралар. Без исә хикмәтле сүз әйтү, фәлсәфи лирика поэтикасының төрки халыкларның үзләрендә тууына, гасырлар буена формалашуына шикләнмибез. Хикмәтле сүз әйтү, җор әйтем, үткен фикерлелек халыкның характеры, табигате белән бәйләнгән. Бу традициянең бик борынгыдан ук бүгенге көнгә кадәр көчле агым булып килүе, бу агымның бер дә кипмәве аның үз җирлегенең ныклыгы белән — поэзиянең шул халыкның фикерләвен, дөнья, тормыш турында фәлсәфи фикер йөртүен чагылдыруы белән аерылгысыз.

М ә к а л ь сүзе үзе, мәсәлән, татар теленә гарәпчәдән кергән. Ул «урынлы сүз» дигәнне аңлата. Х и к м ә т тә тамыры белән татар сүзе түгел. Ләкин татар халкында мәкаль, әйтемнәрнең һәм «күчерелмә-фигураль әйләнмәләрнең», хикмәтләрнең тууы күп гасырлар элгәрәк булган. Андый хикмәтле сүзләр, мәкальләр ислам дине кабул ителгәнче үк яшәп килгәннәр. «Сүз күрке — мәкаль, ир күрке — сакал» ди халык. Н. Исәнбәт мәкальләрнең әнә шул әһәмиятен билгеләп, түбәндәгечә яза: «Беренче әһәмияте — мәкальләрнең авыз иҗаты буларак, аталар сүзе яки халык хикмәте булуы: мәкаль ул — тормышның һәртөрле җил-давыллары эчендә, безне аталарча кайгырткан өлкән һәм борынгы киңәшчебез, дөньяның ачы-сын-төчесен күп татыган, безгә дә аны ничек таныргә өйрәткән өлкән агабыз; безгә үзебезне һәм кешеләрне ничек сынарга өйрәткән сынаучыбыз; безне хатага төшүдән алдан кисәтүче көрәзәбез; хатага төшсәң, ачы иттереп, ләкин шул ук вакытта гадел һәм җылы рәвештә шелтә бирә белүче остазыбыз, ...безне эшкә, көрәшкә актив булырга, ничек уңышка ирешергә чакырып торучы тәҗрибәле хәкимебез; киңәшеп, белем-тәҗрибәсен һич түләүсез чын күңелдән гүзәл мисаллар һәм матур тел белән әйтүче шагыйребез...» (Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. 1 том. Казан, 1959 ел, 222 бит).

Мәхмүт Кашгариның «Диван логате әт-төрек» исемле китабында XI йөздә борынгы төрки кабиләләреннән язып алынган шигырьләрдә дә хикмәтле сүз әйтү җоласының булуы, шулай ук халыкның үз хикмәтле сүзләренең күп китерелүе — хикмәтле сүз әйтүнең халыкның үз тарихыннан, характерыннан чыгуын ачыклап тормыймыни?! XI йөздә Баласагунда яшәгән шагыйрь Йосыф Хаҗиның «Кодатку белик» исемле китабында да без шигырьнең әнә шундый халык хикмәтләренә гаять мул булуын һәм бу хикмәтләрнең фикергә тыгыз, сурәткә бай булуларын күрәбез.

«Кодатку белик» — дидактик характердагы поэма. Шагыйрь, ачыктан-ачык та, кинаялəп тә, патшаны дәүләт һәм халык белән идарә итәргә өйрәтә. Поэмада өйләнү, бала тәрбияләү, кунакка чакыру турында да киңәшләр бирелә. Бу поэмасы Йосыф Баласагунлыны бөтен төрки халыкларның борынгы дәвереннән атаклы хикмәтле шагыйре итеп танытты. Төрки халыкларның борынгы дәверләреннән сакланып калган шушы ике фундаменталь әсәр дә хикмәтле сүзнең халык авыз иҗатында һәм поэзиядә гаҗәп зур роль уйнавын күрсәтә.

Хикмәтле сүз әйтү традициясе бездә борынгы халык шагыйрьләре — чәчәннәрдән үк килә. Импровизаторлык, чәчәнлек йоласы татар халык авыз иҗатында да әлегә кадәр яшәп килә. Моны әрүча мәҗ-

лесләр үткәргәндә очратып була. Табында еш кына кыска җырлар белән үзара сүз көрәштерү, үткенрәк итеп әйтү буенча ярышлар кызып китүчән була. Бу җыр дуэле нигездә электән таныш җырларга нигезләнә. Ләкин нинди темага бәйле булуына карап, җырчы-импровизатор үзенә таныш булган йөзләрчә җырлар арасыннан шул темага карагаsuccessfully нын гына сайлап ала, кайвакыт үзе дә чыгара.

Н. Исәнбәт борынгы татар шагыйрьләренең һәм хәкимнәренең чәчән дип аталуларын һәм аларның кабилә-кавым тормышында зур роль уйнауларын борынгы дастаннардан, мәкальләрдән һәм тарихи чыганаклардан күп фактлар китереп дәлилли. Шундый оста җырчыларга һәм хәким-чәчәннәргә борынгылар тәҗрибә һәм хикмәтнең сихри көченә ия булган кеше дип караганнар. Хәтта алардан ханнар да куркып торган булалар. Халык аларга иярә, ихтирам итә, сүзләрен тыңлый торган була. Мәсәлән, тарихта Җамукай исемле чәчәннең найманнар күтәрелеше башында торуы һәм үзенең тел кылычын Чыңгыз кылычына каршы куеп, утыз еллар буе аңар баш бирмичә күтәрелеш алып баруы билгеле.

Чәчән мәкаль-әйтемнәрне гаҗәп күп белә торган була, үзе дә шундый хикмәтле сүзләр чыгара. Мәкаль-әйтемнәрне, хикмәтле сүзләрне бер-берсенә сарып, ул сарын (яки тулгау) иҗат итә. Сарын аерым рәвештә дә әйтелгән, дастанның бер өлеше буларак та сюжетта урын алган.

Радловның үткән йөзнең 70 елларында Себер татарларыннан язып алган дастан-эпосларында да хикмәтле сүзләр аз түгел. Шундый алым белән төзелгән, чәчәннәрнең иҗат җимеше булган мәкальләр тезмәсе хәтта хәзергә кадәр халык авыз иҗатында сакланып калганнар. Менә шулардан берсе:

> Агачның башын киссәң, төбе калыр,
> Икенең берсе үлсә, бере калыр,
> Ялгызның үзе үлсә, кеме калыр?
> Менгән аты, кигән киеме яуга калыр.

Хикмәтле шигырь әйтү юлысы төрки халыкларында әлегә кадәр бик актив яшәп килә. Бу җола, мәсәлән, казакъларда, кыргызларда көчле. Аларның Абай, Җамбул, Токтагол кебек акыннары атаклы халык шагыйрьләре булып күтәрелделәр. Сәсәнлек хезмәтендәге уңышлары өчен Фәррах Дәүләтшин һәм Сәет Исмәгыйловка Башкортстанның халык сәсәне исеме бирелде. Хәйрулла Ишмурзин, Гиндулла Усманов, Сәйфулла Сәгыйтов кебек импровизатор-сәсәннәрнең исеме дә башкорт халкына яхшы таныш. Н. Исәнбәт чәчән традициясенең татарлар арасында да шушы йөз башларына кадәр яшәвен яза һәм мисал итеп XIX йөз ахырларында гына казакъ арасына кереп, аларның акыннары белән тоткарсыз ярыша алган Казан артының Мәңгәр татары Сабирҗан акын һәм Лаеш янындагы Байчыга авылының Байчыгави акыннарны мисал итеп китерә.

Шигырь белән хикмәтнең аерылмас бердәмлеге, шигырь әйткәндә аны хикмәтле сүз белән күркәмләндерү җоласы — хәким-шагыйрьләр җоласы татар поэзиясенең үсешенә дә, аның поэтикасына да тирән эз салган, поэзиядә борынгы дәверләрдән үк традиция буларак урнашкан. Хикмәтле сүз әйтү җоласының поэзиягә үтеп керүе турында сөйләгәндә, бу традициянең, халык тормышындагы һәм идеологиядәге тарихи үсешкә бәйле, зур гына үзгәрешләргә очравын, хәтта язма поэзиядә үзенең эчтәлеген һәм функциясен үзгәртүен әйтмичә булмый. Ислам динен, фәлсәфәсен җырлаган китаби традиция белән халыкның үз фәлсәфәсен, үз дөньяга карашын ачкан хикмәтле сүз әйтү җоласы бәрелешә. Ислам халыкка үз идеологиясен, үз фәлсәфәсен, үз хикмәтен тагарга омтыла. Шагыйрьлек дини, патша кагыйдәләренә бәйле булып китә. Хикмәтле сүз әйтү язма поэзиядә нигездә дини рамкада бара. Шул юнәлеш беренче һәм төп планга чыга. Ислам шәригатен, аның фәлсәфәсен һәм моралең олылау, үгетләү киң урын ала. Шуңа да чәчәнлекнең төп иҗат сферасы, халык характеры чагылышы буларак табигый агыш булып, халыкның авыз иҗатында дәвам итә. Әмма исламчы

шагыйрьләр хикмәтле, тапкыр сүз әйтүнең поэтикасын — чәчәннәр традициясен бөтенләй үк читкә дә какмыйлар, аның функциясен үзгәртеп, шул чор — урта гасырчылык фәлсәфәсен ачарга җайлаштыралар. Утыз Имәни, Әбелмәних Каргали, Һибәтулла Салихов, Гали Чокрый кебек шагыйрьләрнең иҗатында бу омтылышны ачык күрергә мөмкин. Мәсәлән, Әбелмәнихның «Өммекамал» исемле китабында «Тәхрире әлхаҗҗел мәрхүм» дигән баш астында бирелгән шигырь чәчәнлекнең үткен, хикмәтле сүз әйтү рухындагы традициясенә нигезләнгән.

Чәчәнлек традициясе Габделҗәббар Кандалыйда тагы да көчлерәк, һәм ул исламчы шагыйрьләрдән нык кына аерылып тора. Аңарда бу җола тирән тамырлары белән халыктан килә. Халык рухы хикмәтле сүзнең эчтәлегендә дә, музыкасында да яңгырый: [1]

Якутлар табыладыр вакыт белән,
Вакытлар табылмыйдыр якут белән.

Яки:

Күл төбендә күп камышның
Аслы бердер, нәсле бер:
Бәгъзысыннан кандь алырлар,
Бәгъзысыннан бурия.
Һәм ушандак, адәминең
Аслы бердер, нәсле бер:
Бәгъзысы баш агрыкыйдыр,
Бәгъзы — күзгә тутия.

Бу шигырьләрдә турыдан-туры чәчәннәрдәге үткен акыллылык һәм бай образлылык күзгә ташлана. Әмма Кандалый шигырьнең функциясен хикмәтле сүз әйтү белән генә чикләми, аңарда шигырьне кешедәге тойгы-хисләрне ачу чарасы итеп тә карау бар. Суфый шагыйрьләрдәге шигырь нигездә фикергә, фикер үсешенә корыла, кешенең хисе читтә кала. Кандалый шигырьдә акылны гына түгел, хисне дә хуҗа итеп күтәрә. Берләрендә акыл хуҗа, икенчеләрендә исә акыл белән хис туганлашып хуҗалык итә башлый.

Чәчәнлек традициясен язма поэзиядә тагы да үстереп алып китүче шагыйрь XIX йөз чәчәне Акмулла булды. Акмулла талантлы шагыйрь дә, хакыйкать өчен көрәшүче хәким дә, халык өчен туры сүзле судья да булды. Исеме дә аның әнә шул үзенчәлегенә ишарә ясап тора. Акмулла — туры сүзле галим дигәнне аңлата. Байларга, түрәләргә карата туры һәм үткен сүзлелеге өчен ул төрмәдә дә утырып чыга. Аның үткен теллелеге хакында халыкта хәтта легендалар таралган. Шул чәчәнлек сыйфатлары белән ул татар халкында гына түгел, башкорт, казакъларда да танылган, алар да Акмулланы үз шагыйрьләре итеп саныйлар. Чәчәнлек Акмуллада халык интересларын чагылдыручы, искеләккә каршы көрәшүче шагыйрь буларак та, үз фикерләрен үткен, тапкыр, образлы итеп әйтә белүе ягыннан да чагыла. Менә аның Мәрҗанига багышлап язган шигырьләреннән берничә генә строфа: [1]

Яхшының сүккән белән аты китмәс,
Яман сүзнең күңелдән заты китмәс.
Сау алтынны нәҗескә буяу белән
Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс.
Кәкре ук аткан белән туры китмәс,
Күңелдән яман сүзнең куры китмәс.
Котырган эт күккә карап өргән белән,
Балкып торган тулы айның нуры китмәс!

Акмулланың чәчәнлек традициясе эзсез югалмый. Чәчәнлек алымнарыннан файдаланып язылган, хикмәтле сүз әйтүгә корылган шигырьләрне без Тукайда да, Дәрдемәндтә дә, Гафурида да очратабыз. М. Гафуриның баштагы чор шигырьләрендә казакъ акыннарының хикмәтшигырь йоласы аеруча нык күзгә ташлана (Мәсәлән, «Яшь гомерем» әсәре). Н. Исәнбәт бик хаклы рәвештә: «Гафуриның ул әсәрләре Акмулланыкы кебек үк мәкаль һәм афоризмнарга бай булулары, ничек итеп шигырь тезмәсендә хикмәтне файдаланып активлаштыруның, шагыйрьлек белән хәкимлекне бергә җыярга омтылуның үрнәге булып тора», дип яза. Ләкин Н. Исәнбәтнең «Гафури соңрак, белмим, Тукай тәэсире астына төшепме, ни өчендер, бу юлдан баш тарткан», дигән

[1] Г. Кандалый. Шигырьләр. Казан, 1960 ел, 78 бит.

[1] С. Кудашның «Яшьлек эзләре буйлап» (Казан, 1964, 35 бит) китабыннан алынды.

фикере белән тулысынча килешеп булмый (Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. 1 том, 70 бит). М. Гафури чәчәнлек алымнарын, традициясен файдалануны гомеренең ахырына кадәр дәвам итә. Аның, мәсәлән, 1922 елны язылган «Ир егеткә» яки «Шатлык белән хәсрәт» исемле шигырьләрен яки Әсәрләренең III томындагы күп санлы лирик-фәлсәфи парчаларын гына күздән кичергәндә дә хикмәтле сүз әйтү йоласының совет чоры поэзиясендә дә дәвам итүен ачык күрербез.

Туры юлны сөйгән ил күкрәге
Агыйделләрдән дә киң булыр,
Тапсыз, керсез булган пакъ йөрәге
Бриллиантлар белән тиң булыр.
Уңнан искән җилгә бөгелмәс ул,
Алдан искән җилгә какшамас,
Этләр тавышын түгел, арысланнар
Тавышын ишетсә дә, каушамас, —

дип яза ул «Ир егеткә» шигырендә.

Фикер тапкырлыгы, афористик үткенлек аның башка шигырь һәм поэмаларында да еш очрый. Димәк, Гафуриның үз якташы Акмулла юлыннан бөтенләй баш тартуы турында сөйләргә нигез юк. Әмма Гафури шигырьләренең поэтикасы, баштагы чор шигырьләре белән чагыштырганда, шактый гына үзгәрешкә дучар булуын да инкарь итеп булмый. Гафури поэзиягә Акмулла сукмагы белән керсә, әүвәлге нигездә дидактик һәм хикмәтле сүз әйтү шигырьләре поэтикасына таянса, иҗат юлында ул чәчәнлек традицияләре белән генә чикләнеп калмый, поэзиянең гаҗәп күп төрле сукмаклары барлыгын һәм аларның олы юл булып кушылуларын күрә. М. Гафури да, Тукай шикелле үк, поэзиянең шушы олы юлына чыга.

Тукай да, Гафури да тормышның күп төрлелеген һәм күп төслелеген сурәтләү өчен төрле төсләргә һәм төрле формаларга, алымнарга мөрәҗәгать итәләр. Тукайда, мәсәлән, баштагы иҗат чорында гына түгел, соңгы елларында да дидактик һәм хикмәтле сүз әйтүгә корылган шигырьләрне байтак очратып була. Нигә аны ачыктан-ачык әйтмәскә! Бу бит һич тә начар күренеш түгел. Аерым язучылар рационализм һәм дидактизмны «татар милли буржуазиясенең карашларын үткәрүгә хезмәт» иттерсәләр (И. Нуруллин, шунда ук, 81 бит), Г. Тукай кебек шагыйрьләр аны революцион-демократик карашларын үткәрү өчен файдаландылар.

Кешенең эчке рухи дөньясының катлаулылыгын һәм тирәнлеген ачу өчен хикмәтле сүз әйтү яки үгетләү алымы гына җитмәвен Тукай, Гафурилар ачык тоялар, эпик, лирик һәм драматик чараларны эзлиләр, төрле милләт шагыйрьләренең тәҗрибәләренә таяналар. Акмулланың шигыре нигездә чәчәнлек белән характерланса, Тукай һәм Гафурида инде күп төрле яңа сыйфатлар туа. Бу бигрәк тә шагыйрьнең хис һәм акыл бердәмлегенә ирешү юнәлешендә үсүендә күренә. Шагыйрь кеше күңеленең нечкәлекләренә, тирәнлекләренә үтеп керүнең юлларын эзли һәм таба. Шигырь акыл билгесе булып кына түгел, күңел көзгесе дә булып эверелә.

Тормыш шартларының, кеше акылының яңаруына бәйле рәвештә, чәчән традициясе дә яңара. XX гасыр башы кешесенең тормышка тәнкыйди карашы, җирнең вакытлы гына кунагы түгел, ә хуҗасы итеп тою Тукай һәм Гафурида ачык күзгә ташлана. Тукайның:

Чыкчы, и фикерем кояшы!
Китсен өстеңнән болыт,
Бу үлек вөҗданны җанландыр,
Җырың белән җылыт!

Яки:

Мин адаштым, тугры юлга ул торып күндермәсә,
Дүрт ягым гыйсьян уты, сүнмәс һич, ул сүндермәсә, —

кебек шигырьләрендә яңа кеше фикерендәге «каршылыклар бердәмлеген», эзләнүчән, тикшерүчән, хәрәкәттәге фикерне күрәбез. Менә шушы сыйфатлар Тукай поэзиясенең үзенчәлекле якларын билгелиләр. Тукайда акыл, фикер гаҗәп көчкә ия булган танып-белү коралына әйләнеп китә.

Бер яктан, акыл шәхеснең үз-үзен тикшерә, үзен индивид буларак анализлый, шәхеснең үзендә барган каршылыклар көрәшен, фикер диалектикасын ача. Фикернең шушы

аспектта ачылуы поэзиядә акыл шигъриятенең бөтенләй моңача булмаган яңа якларын китереп чыгара. Бу инде гомумән фикерләү түгел, ә конкрет шәхеснең үз язмышы, үз дөньясына бәйле уйланулары, хакыйкатьне белергә, ачарга омтылуы. Шигырьдә психологизм гаҗәп тирәнәя. Фикерләүдә конкретлык, индивидуальлек моңача күрелмәгән дәрәҗәдә арта. Фикерләүдәге үзенчәлек хәзер тасвир чараларының яки теманың аерымлыгында гына түгел, ә фикерләү процессының, танып-белүнең аерымлыгында да күренә. Хәтта аерым шигырьләр тасвир, сурәтләүләре белән элекке чор поэзиясеннән әллә ни аерылмасалар, үзләренең фикерләү барышындагы үзенчәлекләре белән, аерым шәхеснең фикерләве ягыннан бик нык аерылып торалар.

Икенче яктан, шагыйрь үзен камаган тирәлек, дөнья һәм чор турында да күп уйлана. Тышкы дөньяны хис белән генә кабул итми, ә үткен акылы белән тикшерә. Биредә дә өстенлек — акыл ягында. Биредә дә конкретлык көчле. Без чорның конкрет вакыйгаларын, күренешләрен тикшерүне, конкрет шәхеснең шушы тарихи фактларны бәяләвен күрәбез. Тикшерү тирәнлеге, әлбәттә, төрлечә. Кайбер күренешләрнең асылын ул тирән итеп ача, кайберләрендә хакыйкать өлешчә генә, кайберләрендә шул чор фикерләү дәрәҗәсенә хас йомшаклык сизелә. Суфый шагыйрьләр нигездә тормышны аңлатуга дин догмалары күзлегеннән якын килсәләр, Тукай, Гафури, Рәмиевләрдә бәяләү үлчәве үзгәрә. Аларда шәхес һәм акыл көченә, халык көченә, тарихи барышка ышаныч туа. Алар тарихи барышның, шәхес һәм халык язмышының сәбәпләрен хәзер күк кануннары белән аңлатмыйлар, ә җир законнарыннан, кешенең үз табигатеннән, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдән эзлиләр.

Ганасирны әсир иткән табигать,
Булып мөзтәр, гыйлемгә кылды бигать,

— дип язды Дәрдемәнд (Дәрдемәнд. Сайланма әсәрләр, 93 бит).

Шәхес һәм аның көчен олылау С. Рәмиев поэзиясенең дә нигезендә ята. Әмма аңарда шәхесне хис ягыннан ачу беренче урында тора. Хиснең шигырьгә хуҗа булуы аның үзенчәлекле поэтикасын да төзи. Шигырь композициясе хис хәрәкәтенә буйсына, шуны ачарга җайлаша.

Дәрдемәнд шигыре исә Тукайдан да, Рәмиевнекеннән дә аерыла. И. Нуруллин Дәрдемәнд, С. Рәмиев иҗатларының әһәмиятен «татар поэзиясендәге гасырлардан килә торган рационализм, дидактизм һәм үгет-нәсихәтчелекне кабергә җибәрүдә кирәкле эш эшләүдә» күрә (шунда ук, 105 бит). Дәрдемәнд өчен рационализмга кабер казучы роле килешми. Дәрдемәндтә чәчәннәр традициясе — хикмәтле, фәлсәфи, үткен сүз әйтү көчле бер агым булып дәвам итә. Күп шигырьләре аның сарын поэтикасына нигезләнгән. Мәсәлән:

Мөгезе бар куйның бары да кучкар
түгел.
Очкан кошның барысы да шонкар түгел.
Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берүк.
Чукаңлаган аксак ишәк тулпар түгел...

Яки:

Багып алдыңны күр армас борынрак,
Таяк сал юлыңа язмас борынрак.

Тик биредә үткен фикер берсе өстенә берсе сарылып үсә бармый, күп очракта бер хикмәтле сүзне, афоризмны әйтү белән шагыйрь туктый:

Илдә бер дус булмаса гәр,
Ил бөтен дошман түгел.

Дәрдемәндтә пейзаж лирикасы да, шигъри күренешләр иҗат итү дә зур гына урын ала. Сүзнең шигъри, сурәтле яңгырашына, детальләрне мәгънәле итеп куллануга ул бик нык игътибар итә һәм бу өлкәдә зур осталыкка ирешә.

Шулай да әйтергә кирәк, фикерләү методларында яңалык гаҗәп зур булса да, Тукайда да, Гафурида да сурәт бизәкләрендә, жанр, форма өлкәсендә традиционлык та шактый көчле иде.

С. Рәмиевтә хис патшалык итсә, Тукай поэзиясендә акыл, фикер өстенлек итә. Ләкин инде ул фикерне танып-белүнең үткен коралына әверелдерүе белән, күрүебезчә, үзеннән

алдагы шагыйрьләрдән бик нык аерылып тора. Тукай поэзиясендә акыл гомумән акыллылыктан кеше акылы көченә, фикер гомумән фикерләүдән индивидның фикерләү тирәнлеген һәм диалектикасын ачучы көчкә әверелә. Тукайга кадәр фикерләү нигездә әзер өлгеләргә таянып эш итсә, Тукайда фикерләү үзе яңа өлгеләр эзли һәм таба. Шушы диалектик фикерләү шул чор кешесенең фәлсәфи, политик һәм әхлакый фикерләү үзенчәлеген тирән итеп ачарга сәбәпче булган. Тукайда шигырь чын мәгънәсендә интеллектуаль шигырьгә әйләнә.

* * *

Интеллектуаль шигырь һәм хикмәтле сүз традициясен совет чорына М. Гафури, Ф. Бурнаш, Ш. Бабич, Н. Исәнбәт кебек шагыйрьләр алып чыкты. Аларга да фикерне, акылны танып-белү коралы итеп карау, фикер көченә таяну хас. Г. Тукай, М. Гафуриларда үзен тормышны тануның гаҗәп көчле коралы итеп күрсәткән акыл, фикер хәзер поэзиядә шушы функциясендә яшәвен, ачылуын дәвам итә. Һ. Такташ, Х. Туфан кебек шагыйрьләр Тукай, Гафури шигырьләрендәге акыл, фикер поэзиясен өйрәнгәндә иң әүвәле әнә шул ук моментларга игътибар итәләр. Марксизм эстетикасы акыл көчен яңа югарылыкка күтәрде.

Такташның «шигырьдә матур сүзләр уйнатудан мәгънәгә күчү дәвере килде, татар тормышы шулай ди», — дип язып чыгуында нигездә Тукайга аваздашлык, шигырь роленә яңача карау ята иде. Әмма яшь шагыйрь шул ук вакытта «Бакырган»нан алып, Тукай аркылы хәзергә кадәр биш йөзләрчә шагыйрьләр тарафыннан сузылып килгән татарның иске шигъри эслүбенә» принципиаль рәвештә каршы да чыкты. Такташның фикерләрен ул вакыттагы башка яшь шагыйрьләр дә куәтләделәр. «Шигырьдә үгет, нәсихәт, сафсата бетәргә тиешле. Яшь күңелләр тасвирый әсәрләр сорыйлар» — дип язды Такташ ачыктан-ачык. «Шигъри эслүб»нең җимерелергә тиешле иске традицияләре итеп ул нәкъ үгет, нәсихәт һәм хикмәтле сүз әйтү рухындагы шигырьләрне санады. Такташ кешенең хисе, хәләте рухиясе белән тирән бәйләнгән тасвирый шигырь поэтикасын күтәреп чыкты.

Егерменче һәм утызынчы елларда татар поэзиясендә үгет-нәсихәт рухындагы һәм жанрындагы әсәрләр дә, хикмәтле сүз, үткен фикерлеккә корылган шигырь композициясе дә кулланылыштан чыга, югалып кала. Ике юллы шигырьләрне дә, робагыйларны да бу елларда матбугатта очратуы гаять авыр. Күренеш, вакыйга яки хис агышына нигезләнгән шигырьләр патшалык итәләр хәзер. «Яңа шигырь» поэтикасы үгет-нәсихәткә, сафсатага, хикмәтле сүзләргә көрәш ачса да, бөтенләе белән бу традицияләрне чыгарып ташлый алмый. М. Гафури кебек олы буын шагыйрьләрдә ул инерция буенча дәвам итә, языла. Төрле елларда язылган ул шигырьләр үз вакытында басыла алмыйлар, тик соңгы елларда гына дөнья күрделәр. Бу елларда чәчәнлек традицияләрен актив кулланучы шагыйрьләрдән Н. Исәнбәт булды.

Хикмәтле сүз әйтү традициясенә киртә кору поэзиянең сурәтләү мәйданын һәм фикер тыгызлыгын, билгеле, нык кына киметте, халык иҗаты белән тыгыз бәйләнешне дә йомшартты.Ләкин хикмәтле сүз традициясен һәртөрле декларацияләр белән генә ябу мөмкин түгел иде. Чөнки ул, алда әйткәнебезчә, халыкның характеры, поэтик фикерләве белән бәйләнгән. Ә халыктагы үткен фикерлелекне һичничек юкка чыгарып, югалтып булмый. Х. Туфан, М. Җәлил кебек икенче бер төркем яшь шагыйрьләрдә дә бу традиция дәвам итә. Хәтта Такташның үзендә дә хикмәтле сүз әйтү традициясе бөтенләе белән югалмый, иҗатының соңгы елларында көчәеп китә. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә халыкча үткенлеккә, афористик, канатлы сүзләргә омтылуны күрмичә мөмкин түгел. Бу омтылыш аеруча аның соңгы елларындагы шигырьләрендә көчәя һәм ул шагыйрьнең элек әйткән үз фикер-

ләренә тәнкыйть белән карый башлавын раслый. Дөрес, хәзер бу традиция Кандалый, Акмулла, Дәрдемәндтәге шикелле үзенә хас калыплашкан шигъри формаларда һәм жанрларда яшәми инде. Фикер үткенлегенә яки сүз уйнатуга корылган махсус шигъри парчаларны яңа буын шагыйрьләрдә, бәлки, очратып та булмас, әмма фикер үткенлеген, хикмәтле сүзне без аларда еш ишетербез. Хикмәтле сүз әйтү — аларда шигырьнең төп максаты түгел. Хикмәтле сүз шигырьнең нинди дә булса өлешенә бик табигый рәвештә килеп керә һәм шагыйрь фикерен яки персонаж фикерен ачуда, укучыга җиткерүдә әһәмиятле роль уйный.

Егерменче елларның башында халыкның афористик сурәтле фикерләве белән якынлык, хикмәтле сүз әйтү омтылышы барлык шагыйрьләргә караганда Х. Туфанда көчлерәк. Туфанның сурәтле фикерләвендә Тукай, Акмулла, Дәрдемәндләр аша килгән чәчәнлек, хикмәтле сүз әйтү традициясе үзе бер агым булып бара һәм бу агым елдан-ел көчәя, яңа сыйфатларын ача. Шагыйрь, бер яктан, халыкның үз мәкаль-әйтемнәрен дә актив куллана, икенче яктан, үзе дә үткен акыл белән сугарылган шигырь юллары иҗат итә. Хикмәтле сүз шигырьдәге вакыйга, күренеш яки сурәтләнгән образ белән тыгыз кушылып китә, яңа чорны яки кешене ачу өчен хезмәт итә. Бу яктан «Башлана башлады»дагы түбәндәге юлларны мисалга китерергә мөмкин:

> Ана сөте белән кермәгәнне
> Тормыш үзе кертә күңелгә.
> Ана сөте белән кергәнне дә
> Үзгәртәләр безнең гомердә.

Егерменче елларның ахырларында Такташның үзендә дә халыкча афористик фикерләү үрнәкләре тууын югарыда әйтеп узган идек. Бу поэзия өчен бик гыйбрәтле билге булды. Шул елларда Такташ белән Туфан поэзиясе әлеге нигездә бик нык якынаеп китүе, Такташның үзендә дә үткен сүз, хикмәт әйтүгә омтылыш көчәюе очраклы түгел иде. Татар поэзиясе әнә шул юлдан инде читкә чыкмады. Халыкның фикер үткенлеген тирәнрәк чагылдыру юлыннан үсте һәм үсә.

30 елларның икенче яртысында халыкның афористик сурәте, фикерләве дә поэзиядә үз формасында, үз композициясендә иркенрәк ачыла башлады. Бу яктан аеруча Муса Җәлил иҗаты характерлы. «Алтынчәч» драматик поэмасында шагыйрь халыкның героик характер сыйфатларын ачуда хикмәтле сүзләрне бик мул куллана. Халык:

> Яз башында Идел ташыса,
> Яр буйларын басып китмәсме?
> Ир егетләр бергә кушылса,
> Ханнар явын туфрак итмәсме?

— дип җырласа, хатын-кызлар ирләренә:

> Куркакларга хатын булганчы,
> Батырдан тол калу яхшырак,

— диләр...

Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясендә хикмәтле сүз әйтүнең роле шигырьдә тагы да үсә. Бер яктан, ул шигырь эчендә яшәвен дәвам итә: нинди дә булса фикерне, күренешне үткен итеп әйтү яки гомумиләштерү өчен, хисне, фикерне шигъри итеп әйтү өчен кулланыла. М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗи, Ш. Маннур, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәйләрнең шигырьләрендә без моны ачык күрәбез. Икенче яктан, хәзер ул Дәрдемәндтагыча яки Тукайдагыча үз алдына аерым жанр буларак та яши алуын, шул яктан да тормышчанлыгын раслады. Биредә күренеш тә, эпизод та, вакыйга да юк, шигырь тик фикер агышына нигезләнгән. М. Җәлилнең «Ике йөзле кешегә», «Бер үгет», «Батырлык турында», Ф. Кәримнең «Сөйләр сүзләр бик күп алар...», «Иң матур кеше...» исемле шигырьләре нәкъ менә шушы хикмәтле сүз әйтү поэтикасына, чәчәннәрнең үткен сүзлелек йоласына нигезләнеп язылганнар. Дүрт юллы шигырь һәм сигез юллыкларның аерым шигырь буларак озын, тасвирый шигырьләр белән бер тигез хокуклы урын алулары һәм жанр буларак терелүләре, андый кыска шигырьнең яңа матурлыгы ачылуы аеруча Ватан сугышы поэзиясендә күренде.

Утта булган балчык кире кумпас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.

М. Җәлил биредә хикмәтле сүзләрне бер-берсенә сарып, сарын әйтү алымын куллана. Афористик җөмләләр берсе-берсенә сарылганнар. Бу шигырьләрдә метафорик куелык көчле. Һәр фикер, һәр җөмлә үз алдына мәкаль буларак та яңгырый. Һәрберсенең үз мөстәкыйльлеге бар. Әмма бу бер темага караган мәкальләр җыелмасы гына түгел. Алар арасында тыгыз бәйләнеш яши. Утта булган балчык, эштә булган тимер турындагы фикер биредә гомумән генә әйтелми, ә ил каршында эш күрсәткән иргә бәйләнештә алына. Биредә шагыйрь катлаулы ассоциациягә нигезләнеп эш итә. Мәкальнең үзендә дә шушы принцип ята. Ә биредә ассоциация тагы да киңәеп китә, дөресрәге, өсте-өстенә, параллель рәвештә тезелә бара. Шушы хикмәтле сүзләрнең, әйтемнәрнең янәшә китерелүләре яңа мәгънә белән байый. Шул рәвешчә, сурәтлелек гаҗәп киңәеп, тирәнәеп китә. Җәлил башка строфаларда чәчәннәр поэтикасындагы бүтән алымнардан да — кире чагыштырулардан (контрастлар, антитезалар), метонимия, киная, читләтем, гиперболалардан мул файдалана.

Ф. Кәримнең:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була,

— дигән канатлы сүзләрендә каршы кую алымын да, юл башы рифмаларының гаҗәп шигъри яңгырашын да, фикернең үстерелә баруын һәм сүзләр тезүдәге симметрияне дә ачык күрәбез. Дөресрәге, болар берсе дә күренми дә, сизелми дә, тик шушылар берлегендә туган гаҗәп самими шигъри фикер генә бар.

Сугыштан соңгы еллардагы татар поэзиясе, вакыт ягыннан үзенең борынгы дәвереннән ераклаша барса да, шигырьдә хикмәтле сүз әйтү традицияләрен терелтү ягыннан якыная төште. Бу традициянең активлашуы ике тармак буенча бара. Нинди дә булса хикмәтле сүзне, үткен фикерне лирик, публицистик яки фәлсәфи шигырьдә куллану хәзерге шагыйрьләрдә дә дәвам итә. Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Давыдов, С. Баттал, Г. Хуҗи, Х. Камал, И. Юзиев, Ә. Маликов кебек шагыйрьләрнең шигырь-поэмаларында уңышлы кулланылган, оста табылган хикмәтле сүзләр бик еш очрый. Бу — бер юнәлеш. Икенчесе — хикмәтле сүз, үткен фикер әйтергә корылган шигырьнең автономияләшүе, үз алдына аерым яшәве, мөстәкыйльлеге. Игътибарны шушы «автономия»гә юнәлтик әле.

* * *

Хикмәтле сүз әйтүгә корылган шигырь поэтикасы соңгы елларда аеруча активлашып китте. Бу исә дүрт юллык, хәтта, өч юллык, ике юллыкларның аерым шигырь булып яшәү мөмкинлегенә, хикмәтләрнең, робагыйларның кабат терелүенә китерде.

Хикмәтле сүз әйтүгә корылган кыска шигырь формасын иң әүвәл Шәйхи Маннур һәм Зыя Мансурлар активлаштырып җибәрде дисәк, ялгыш булмастыр. Дөрес, аларның робагыйлары басылып чыкканчы да, дүрт юллык шигырьләр Н. Арслановта да, Г. Афзалда да, Ә. Исхакта да күренгәли иделәр. Арада бик уңышлылары да бар иде. Ләкин, ничектер, шагыйрьләр озын һәм күп сүзле шигырьләр, поэмалар язу белән мавыккан елларда алар, әдәби күренеш буларак, күзгә ташланмадылар.

Ш. Маннур робагыйларны жанр буларак тергезүне максат итеп куя. «Гомәр Хәйям белән сөйләшү» исемле робагыйлар тупламында (Ш. Маннур. Кичке моңнар. Казан, 1959 ел) бу турыда ул үзе болай ди:

Гомәр Хәйям! Мең ел яткан сорнаеңны,
Янгыратмак булам, кушып җырларымны,
Көч житәрме робагыйны тергезергә?..
Эш чыкмаса, бор син минем колагымны!

Ш. Маннурда уңышлы гына робагыйлар бар. Аларда гомер юлының уртасына җиткән шагыйрь хисләре, аның кичерешләре, уйланулары ачыла. Ш. Маннур робагыйлар-

ның форма төрлелегенә, аларның сурәтлелегенә нык әһәмият итә. Бу яктан аның «Кыш», «Яз», «Җәй», «Көз» робагыйларын мисалга китерергә мөмкин. Менә бер-ике үрнәк:

### ҖӘЙ

Чәчәкләре җәйнең һәр сәгатьтә
Баш сузалар кояш утына,
Яшь күңел дә шулай: мәхәббәткә,
Көячәген белми омтыла.

### КӨЗ

Горур басып тора кысыр башак,
Тук арышлар түбән иелгәндә.
Буш башлар да йөри шуңар охшап,
Мең тыйнаклар эшкә күмелгәндә.

Ш. Маннур бер төркем робагыйларында Г. Хәйям рухында тормыш, яшәү, мәхәббәт, яшьлек һәм картлык турында фикер йөртә:

Син мактаган шәрап инде иске, Хәйям,
Безнең көндә нык тыела эчке, Хәйям,
Син җырлаган сөю ләкин һаман яңа!
Һәм шәраптан нык көйдерә эчне, Хәйям.

Шагыйрь робагыйларын Гомәр Хәйям белән сөйләшү рәвешендә төзи, шулай башлый. Ни дисең, отышлы алым. Ул Ш. Маннурга үткән чор белән сөйләшергә, бәхәсләшергә киң мөмкинлекләр ачкан. Ләкин шагыйрь, безнеңчә, алардан тулысынча файдаланмаган. Хәйям белән бәхәсләшүдән башланган сүз тиз арада туктый һәм шагыйрь Хәйямне оныта да, үз алдына сөйләшү рухында гына дәвам итә. Робагыйларны олы фәлсәфи яңгырашлы, тирән социаль эчтәлекле итеп тереләтсе урында, көндәлек тормыш һәм әхлак вакыйгаларына бәйләнешле шигырьләр бәйләме туа. Һәм бездә хәзерге робагыйлар башка шагыйрьләрдә дә шушы юнәлештәрәк үстерелә. Гомуми әхлак темасының робагыйларда төп урынны алуы хәзерге тормышта яңа кеше тәрбияләүнең әһәмияте артуы белән билгеләнә булса кирәк. Язу мәйданының кысан булуы исә фәлсәфәне гомумирәк төстә алып баруга да илтә. Икенчедән, фәлсәфи фикерләү хәзер тик бер кыска шигырь җилкәсенә генә салынмаган. Әгәр Хәйямда аны тик робагый күтәреп барса, хәзер ул төрле шигырь формалары, жанрлары аша укучыга җиткерелә (Х. Туфанның фәлсәфи шигырьләре, С. Хәким, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, Ә. Баянов, Роберт Әхмәтҗановның фәлсәфи-лирик поэмалары һ. б.).

З. Мансур элек тә эчтәлекле, хикмәтле сүз әйтүгә нигезләнгән уңышлы парчалар иҗат итә иде. «Җир сөрмисең», «Хуҗа һәм Нәкый Исәнбәт», «Әҗәт мәсьәләсе», «Шәп яшибез», «Дуңгыз ите һәм дуңгыз турында» шикелле парчаларын әнә шундый үткен эчтәлекле хикмәтләргә мисал итеп китерергә мөмкин. Соңгы елларда ул бу өлкәдәге эшчәнлеген бермә-бер үстереп җибәрде. «Ак розалар» исемле җыентыгы шагыйрь иҗатында хикмәтле сүз әйтү тенденциясенең шактый тирән тамыр җибәрүен раслый. «Шагыйрь дустыма» шигырендә З. Мансур болай ди:

Көчле булсын дисәң җырда сүзне әгәр,
Тикшер аны энәсеннән җебенә кадәр.
Алып кара, борып кара, җуеп кара,
Бер чүп үлән түгелме ул, йөзе кара.

Шагыйрь дустына биргән киңәше, үгете З. Мансурның үз иҗатында да чагыла. Ул да сүзнең мәгънәлелегенә, төгәллегенә, фикер ачыклыгына һәм аның сурәтле гәүдәләнешенә нык игътибар итә, сүзне «энәсеннән җебенә кадәр» тикшерә башлады. Менә бу үзе үгет-нәсихәт шигыре. Ләкин аны үгет-нәсихәт рухында язылган өчен генә һич тә үги бала шикелле кимсетеп карап булмый. Үзенең шигъри гәүдәләнешен тапса, үгет-нәсихәт рухындагы шигырь дә чын поэзия энҗесе булып яңгырый. Ә шигъри гәүдәләндерү юллары гаҗәп күп. З. Мансур фикерне «ялангач» калдырмый: я хис белән тыгыз үремтәдә бирә, я һәртөрле бизәкләү чаралары аша — сурәт контекстында, аваз яңгырашында аны укучыга якынайта. «Борын» шигырендә ул, мәсәлән, борынгы чәчәннәр поэтикасында кулланылган тоек алымын уңышлы куллана:

Байроннарга таба, дисең,
Алып бара мине юлым!..
Әйбәт булыр иде дә бит,
Артык текә карый борын, —
Әрәм итеп куяр кебек,
Морадыңа җитмәс борын.

Башка парчаларында («Ак диләр», «Юксыну») ул эчке рифма яңгырашын эшкә җигә.

Н. Дәүлинең дә уңышлы гына эшләнгән робагыйлары бар. («Бөркет турында», «Шагыйрьләргә», «Тәнкыйтькә минем карашым» һ. б.). Ш. Галиев, З. Нури, Ә. Исхак, Г. Афзалда хикмәтле сүз әйтү еш кына юмористик яки сатирик төс ала. Аларның хикмәтләре нинди дә булса күренештән, яки кешенең нинди дә булса кимчелекле якларыннан көлүче үткен коралга әверелеп китәләр. Менә, мәсәлән, Г. Афзалның «Ата белән бала» шигыре:

Бала:

Калынымы, юкасымы,
Кайсы китап яхшы, әттә?

Ата:

Кенәгәнең иң асылы
Сберкнижке, әлбәттә.

Әхмәт Исхак дингә каршы язылган сатирик парчаларын «Динсез дүрт юллыклар» дип атады.

Ш. Галиевның да үткен итеп язылган ике юллыклары, дүрт юллыклары байтак. Менә берничә мисал:

**ВОКЗАЛ**

Вокзал кебек синең йөрәк —
Керен чыкмаганнар сирәк...

**БЕЛ...**

Үлгәннәрнең каберен бел,
Исәннәрнең кадерен бел.

**КИРЕ КАГУ**

«Сөткә су кушалар» диеп,
Яла якма, куш авыз.
Сөткә суны кушмыйбыз без,
Суны сөткә кушабыз!

Ш. Галиев хикмәтле сүз композициясендә борынгы шагыйрьләрдән үк килгән сүз уйнату алымын активлаштырып җибәрде. Сүз уйнату йоласына З. Нури, Ә. Исхак та еш мөрәҗәгать итәләр. Менә З. Нуридан чәнечкеле бер парча:

**ТӘНКЫЙТЬЧЕГӘ...**

— Җырларымны тәнкыйть итте кичә,
Ләкин ник соң икейөзле ул.
Шуларны ук тетеп мактап китте
Салып алгач ике йөзне ул?!

Соңгы елларда З. Нури кыска шигырьләр язу белән аеруча мавыгып китте. Шундый хикмәтле сүзләре аның «Туры карап күзегезгә» җыентыгына тупланып, аерым китап булып та басылып чыкты. Җыентыкта шагыйрь хикмәтле сүзләрен «Ярату», «Елмаю», «Киная», «Уклар», «Киңәш-табыш» кебек бүлекләргә төркемләгән. Шагыйрь үзенең «Киная»сен һәм «Уклар»ын бүгенге тормышта очрый торган һәртөрле кимчелекләргә, гарип күренешләргә юнәлтә. Байтак кына хикмәтләрен шагыйрь әхлак темасына багышлаган.

Тормыш, көнкүреш, кешеләр турындагы уйланулар, үгет-киңәш рухындагы парчалар Ә. Ерикәй, Н. Арсланов, Ш. Галиев, Г. Афзал, Г. Латыйпларда да соңгы елларда үсеп китте. Аларда да үткен итеп әйтелгән хикмәтләрне очратабыз. Н. Арслановның «Үзгәреш», «Шагыйрьгә», «Ач тәрәзәң, иптәш», Н. Дәүлинең «Шагыйрь үлеменә», Ә. Ерикәйнең «Гомер җиле шаулап искән чакта», «Яшьлектән дә зур байлык юк», «Пыскып янган учак — учак түгел» кебек парчаларына үткен акыллылык һәм аның сурәтле-эмоциональ гәүдәләнеше хас.

Хәзерге татар поэзиясендә хикмәтле сүзнең киң урын алуын, аның кыска шигырь төрләрен активлаштыруын билгеләү белән бергә, бу өлкәдәге кимчелекләрне дә әйтергә кирәк. Кимчелекләрнең берсе һәм олысы — хикмәтле сүз әйтүнең үгет-нәсихәт төрендә иске традицияләрдән, дөресрәге, искергән традицияләрдән арына алмау.

Бүгенге поэзиядә фикерләүдә бернинди үткенлеге, шигърияте булмаган, хәзерге чор һәм шәхеснең үзенчәлекләрен ачмаган, коры үгет сатуга корылган парчалар күренә башлады. Хикмәтләрдә, робагыйларда шагыйрь шәхесе мәсьәләсе — ул кечкенә мәсьәлә түгел. Шигырь кечкенә булуга карап шагыйрь шәхесе юкка чыкмаска тиеш. Әйтик, Хәйям шушы кыска форма белән үз чорының фәлсәфәсен ничек тирән итеп ачкан, ул робагыйларда шагыйрьнең дөньяга карашы ничек үзенчәлекле гәүдәләнә!

Эш һәртөрле бизәк чараларының уңышлы сайлануында гына түгел. Иң әһәмиятлесе — фикернең шагыйрь җаны белән тыгыз бәйләнүендә, шигырьнең тирән кичерешләр һәм уйланулар нәтиҗәсе буларак туган фикер булуында. Соңгы вакытларда хикмәтле сүз үзмаксат булып китте, күпкенәләрендә шагыйрьнең йөзе юкка чыкты.

Яхшы эш эшләсәң кешегә син
Исеңдә тотма.
Кеше сиңа яхшы эш эшләсә
Һич тә онытма.

Бусы — Ә. Ерикәйдән.

Н. Арслановның «Үгет» шигыре дә шундый ялангач үгет рәвешендә язылган:

Яхшы сүз әйтә белмәгән —
Дөньяда иң начар бәндә,
Сак бул, ямьсез сүзләр сөйләп,
Тәмсезләнмә, тәмсезләнмә.

Бүгенге заман шагыйренең фикерләвен танып алуы бик тә авыр бу шигырьдән. Бүгенге совет кешесенә бу үгет белән генә яшәве мөмкин дә түгелдер әле: тормыштагы искелек, начарлык белән очрашканда ямьсезләнмичә дә, тәмсезләнмичә дә ярамый. Әлеге шигырьгә туктालуның сәбәбе — мондый гомум фәлсәфәгә корылган абстракт парчаларның башка шагыйрьләрдә дә очравы һәм күбәюе булды. З. Нури, Г. Афзал, Ә. Исхакның да кайбер шигырьләрендә шушы кимчелек очрый.

Еш кына хикмәтле сүз әйтүдә фикер яңалыгы, фикернең олылыгы яисә иске фикерне яңача яңарту җитми. Кайбер хикмәтле сүзләр халык мәкальләрен, әйтемнәрен яки мәзәк һәм мәзәкчәләрен рифмалаштыру һәм иҗек калыбына салу белән чикләнәләр, андыйларда шагыйрьнең үз сурәтле фикерләвендәге үткенлек һәм яңалык күренми.

З. Нуриның уңышлы гына дүрт юллыклары арасында әнә шундый «Тотылды һәм котылды», «Имтиханга йөрү», «Алдый алмады», «Үзеңчә атла» кебек халык телендәге төрле әйтем һәм мәзәкләрне шигырь калыбына салу белән чикләнгән хикмәтләрне очратып була:

Күркә кебек йөрмәк булды карга
Адымнарның атлап эресен.
Күперенеп ләкин бераз баргач,
Онытты ул үзенең йөрешен.

Кайбер хикмәтле сүзләр кайсыдыр шагыйрь тарафыннан кайчандыр әйтелгән хикмәтләрнең вариантлары буларак кына яңгырый. Әйтик, Г. Латыйпның бер парчасы түбәндәгечә:

Кесәм тулы акчам бар чагында
Тирәм тулы иде танышлар.
Акчам беткәч, сүз куешкан кебек,
Бөтенесе миннән таймышлар.

Тукай бу фикерне 1907 елда ук «Теләнче» дигән шигырендә:

Ә шулаймы? Акча барда, бар да дус шул, бар да яр;
Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!

— дип, капиталистик чынбарлыкны фаш итәрлек бик тирән мәгънәле шигъри юлларда әйтеп салган иде. Хәзер аның мәгънәсен көнкүреш ваклыгына кадәр тарайтып кабатлауның һич тә мохтаҗлыгы юк. Х. Туфан әйткәнчә, «робагый — шигъри фикерләр, хисләр аккумуляторы булырга тиеш ул».

З. Мансур «Чор һәм җыр» исемле мәкаләсендә («Социалистик Татарстан», 13 октябрь, 1963 ел) кайбер шагыйрьләрнең фәлсәфи һәм сатирик парчаларында үткенлекнең, тапкырлыкның җитмәвен, фикернең ваклануын хаклы рәвештә билгеләп үтә:

«Күрәсең, без Гомәр Хәйямнар тарафыннан тирән философик фикерләр әйтү өчен файдаланылган бу классик форманың, ягъни дүрт юллык шигырьләрнең кайда, кайчан, нәрсәгә юнәлтелергә тиешлеген аңлап җиткермибез», — ди ул, нәтиҗә ясап. Бу фикердә хаклык бар. Әмма бәхәсле ягы да бар. Сүз фәлсәфи лирика турында барганда, һичшиксез, без фикернең тирәнлеген, әһәмиятлелеген һәм яңалыгын яклыйбыз. Әмма һәр дүрт юллыкны — робагый формасын тик фәлсәфи фикер әйтү өчен генә файдалану рәвешендә аңлауга һәм аңлатуга без каршы. Һәр дүрт юллыкны

Гомәр Хәйямнар шикелле «гаҗәеп дәрәҗәдә тирән философик фикерләр» белән сугару мәҗбүри түгел. Фәлсәфи фикер бөтенләй булмаган, нинди дә булса тормышның теге яки бу гыйбрәтле күренеше, чынбарлыкның, чорның, кешенең берәр штрихы чагылган, көлке, сүз уйнатуга корылган дүрт юллыклар да яшәүгә хаклылар. Аларның да поэзиядә үз урыннары бар. Г. Афзалның мәкаләдә уңышсыз шигырьгә мисал итеп китерелгән «Дару» парчасы, фәлсәфи фикерне эченә алмаса да, карчык кешенең фикерләвендәге үзенчәлекне бик нечкә тотып алуы белән әһәмиятле.

Хикмәтле сүз әйткән парчаларның формаларын, үз эчендәге жанр төрләрен баету турында да уйларга кирәк. Дөрес, бу юнәлештә Ш. Галиев, Ш. Маннур, Ә. Исхак, З. Мансурларда актив һәм уңышлы эзләнүләр бар. Хикмәтле сүзне бүгенге кешенең уйларына, бүгенге тормышка якынайтып сурәтләү аларны бу өлкәдә сизелерлек шигъри табышларга китерде. Шулай да шигырьләрнең үз эчләрендә формалары ягыннан бертөслелек сизелә әле. Менә бу яктан Рәсул Гамзатовның ике юллык яки дүрт юллык хикмәтле сүзләре гыйбрәтле. Шагыйрь үз халкының характерын, үткен акыллылыгын нинди үзенчәлекле калыпларда яңарта! Бер өлеше хикмәтле сүзләрне үл «Кабер ташларындагы язмалар» исеме астында берләштерә. Икенче бер төрләре «Хәнҗәргә язылган сүзләр» булып оешканнар. «Ишектәге һәм капкалардагы сүзләр», «Мөгез җамга язылган сүзләр», «Пандур һәм чаганадагы язулар», «Кыялардагы язмалар», «Буркага язылган сүзләр», «Ияргә язылган сүзләр» — шагыйрь хикмәтләрне әнә шулай үз халкының фикерләве, халкының көнкүреше, гореф-гадәтләре белән тыгыз бәйләп, күп төрле формада ача, фикерен укучыга шигъри итеп җиткерү өчен күп төрле яңа алымнар эзли һәм таба.

Тормыш, әхлак фәлсәфәсе турындагы парчаларның күбәюендә бүгенге әдәбият үсешенең үзенчәлекле һәм әһәмиятле бер тенденциясен күрмичә мөмкин түгел. Бу — XX съезддан соң илдә туган атмосфера белән, шәхеснең фикерләргә, тормышны танып-белергә омтылышының тирәнәюе белән бәйләнгән. Үгет-киңәш шигырьләренең язылуы тормышта мораль, әхлакның гомуми роле үсүе белән дә бәйле. Иҗади фикерләүдә туган шушы фәлсәфи һәм дидактик омтылыш Көнчыгыш һәм борынгы татар поэзиясенә хас әдәби формаларның да терелүенә, активлашуына һәм «шигъри суд»та чын мәгънәсендә аларга өлешчә «амнистия» үткәрелүенә, поэзиядә яңа формалар, яңа байлыклар тууына китерде.

# *Ян Райнисның тууына 100 ел*

## Ялкын һәм герой

Утлар янса — бөтен җирдә нурлар балкый,
Утлар сүнсә — җирне караңгылык каплый.
Геройны да була җиңеп — гомерен алып,
Мәңге балкый ләкин аның даны калып.

1906.

## Крестьян түземе

Бәхетсез мужик басуда чәчте арыш,
Сокланырлык уңыш бирде һәрбер карыш.
Барин килеп әйтте: җир хакын түлисең!
«Тәртип саклаучы» даулады үз өлешен.
Моны күргәч пастор да карап калмады,
Ә причетчик пастордан һич ким алмады.
Судья күрде — алды үзенә кирәкне,
Чиновникка шактый мул ришвәт эләкте...
Бар да килде, бөтенесе пичәт сукты,
Һәммәсенә кирәк кадәр өлеш чыкты.
Калганын карга чүпләде... Мужик шунда
Күтәрелде һәм дәү күсәк алды кулга.

1905—1922.

## Яңадан килер

Геройлар көне яңадан килер,
Төтенли инде туган-як җире.
Тимер билбавын буды көн кабат.
Өрмәгез, этләр, упкынга карап.
Юк, булмас, булмас кан тәмен татып,
Вакыт агышын булмас туктатып!
Әзерме яуга син, минем халкым?
Калканың ныкмы, зурмы дәрт-ялкын?
Күзләрең үткен карыймы алга?
Син, минем халкым, әзерме яуга?
Геройлар көне яңадан килер,
Төтенли инде туган-як җире.

1920.

## Кыюлык турында җыр

Кага-суга бу тормыш,
Ялвар да син, баш и, —
Билең һаман бөгелгән,
Ыңгыраш та яшь кой...

Изүчеләр алдында
Яшисең тез чүгеп —
Авыр язмыш булырмы
Мондый язмыш кебек?

Кемнәр синең хезмәтне,
Эшләреңне таптый,
Кемнәр хурлый җаныңны,
Һәм тәнеңне таплый,

Ялварасың шуларга,
Дисең: «Яшәү бир син».
Сине һичкем кызганмый,
Кол ителгән ир син.

Үз хакың, үз хокукың
Дошман белән бүлеш,
Хәзинә бир, ясмык ал! —
Шул да тормыш, имеш.

Шәфкать кирәк куркакка,
Ә без кыю булыйк,
Ялкынланыйк көрәштә,
Кирәк икән — үлик!

1903.

## Куркыныч хөкем көне

Кайнар йөрәкләр
Бик күп сүнәрләр,
Бик күп кыюны
Җиргә күмәрләр.

Караңгы төннәр
Күпләрне буар...
Очкыннан янгын
Тик шулай туар.

Халыкның бик күп
Коелыр каны
Беткәнгә кадәр
Колларның зары.

Дулкын бер ярсыр,
Бер кире ятыр,
Давыл чыгар да —
Тагын уятыр.

Көрәштә күпләр
Җаннарын бирер,
Алар урынына
Күп меңнәр килер.

Әгәр дә тынса
Шунда бер тавыш,
Күтәреп алыр
Аны ун тавыш.

Калкыныр шул чак
Кыр, тау һәм ташлар, —
Һәр тавыш белән
Җир улый башлар.

Һәр урын шаулар,
Зур дәһшәт явар,
Кинәт сискәнеп
Биналар авар.

Көтмә, пан, сиңа
Посар урын юк:
Аяк астыңда
Булыр бары ут.

Саклый алмассыз
Сез диварларны,
Кыюлар кулы
Ишәр аларны.

Сыеныр урын
Бирмәс таулар да:
Һәр сукмак яный
Сезгә тауларда.

Нинди суда соң
Урын бар сезгә?
Йотар, батырыр
Сезне диңгез дә.

Саз баткагы да
Яшермәс сезне:
Сез баткактан да
Карарак йөзле.

Дәшми торган җир
Бугазын киерер,
Утта янарсыз, —
Шундый көн килер.

1903.

Зәки Нури тәрҗемәләре.

## Сынган наратлар

Давыл һәлак итте диңгез ярындагы
Комда үсеп торган биек наратларны, —
Еракларга төбәп алар карашларын
Мәгъруp тора иде, имичә башларын.

«Син сындырып киттең безне, әй, дошман көч,
Тик бетмәде сиңа каршы көрәш һәм үч,
Иң ахыргы сулышта да ирек теләп
Һәр ботакта изүчегә кайный нәфрәт!»

Давыл бәла китерсә дә наратларга,
Әйләнделәр алар көчле корабларга,
Ул кораблар давылларга каршы бара,
Өнди бөек көрәшләргә, дулкын яра:

«Актарыл син, әй, дошман көч, безнең өскә,
Без чыгарбыз йөзеп ирек-бәхтебезгә!
Әйдә сындыр, йомычка ит безне, дошман, —
Алдыбызда чиксез киңлек, кояшлы таң!»

1899—1901 (?)

## Римнан өстен

Бөек бурыч беләп бергә
Үсә җанда көч тә, рух та.
Римлыларның киң колачы
Кабатланмаган тарихта.

Ләкин узып китәр менә
Пролетарийлар Римнан да:
Анда бар дөнья кол булган,
Монда — азат бөтен дөнья.

1908 (?)

## Сулда

„Йөрәк — шәфкатьле кояш,
Кылыч — яклаучы, юлдаш!

Әйтегез шул хакта сез:
Кайсыгыз кай якта сез?»

«Безнең урын тик Сулда,
Халык бәхете тик шунда!»

1908

## Идеал

„Әйт әле, либерал,
Нәрсә синең идеал?..» —
«Минем идеал шулар:
Яктылык, хакыйкать һәм...
Арзанлы эшче куллар!..»

1908

## Бюрократ һәм орденнар

Булдыра алганча урладың, таладың,
Шымчы да, куштан да булдың, гел алдадың,
Хурлыклы эшләрдән һич читтә калмадың.

Шуңарга өстеңдә күп пычрак тапларың.
Зарарсыз! Орденнар күп синдә, капларсың.

1907.

## Партиясез политик

Юк! Сиңа ярамый,
Җаныңны сакла:
Сугышмый калалмый
Басканнар сафка.

Шаша да омтыла
Дуамал гына,
Ә син шыпырт кына
Пос почмагыңа.

Кем дә булса җиңәр,
Көн килер, шунда —
Капкаң ачып җибәр
Кычкырып «Ура!»

1905—1907.

## Шаян кызый

„Тапсаң да син бүтән кызны —
Тыңгы булмас, ышан сүземә:
Куармын ул вафасызны,
Барыбер булырсың үземә!

Булса булсын куллары ак,
Шәлләре дә затлы булсын,
Аларда юк алсу яңак,
Миндәгедәй алтын толым.

Табалмассың миңа тиңне —
Миндә — сөю учаклары!
Аңламыйлар алар сине:
Оныт син ул курчакларны.

Шиксез өстен өстенлеккә
Мин алардан, мин — иң якын.
Яшь алмас мескенлектә
Буйсынмаучан синең акыл.

Очкын сибеп күзләремнән
Узып киткәндә бер мәлне,
Син аларны йөрәгеңнән
Алып ташлаячак мәңге!»

1899—1901 (?)

Нури Арсланов тәрҗемәләре.

* * *

Үземне мин үзем иҗат иттем.
Бала чактан бирле, хис сибеп,
Ялгыз камыш сыман күңелемне
Олы бакча итеп үстердем.

Көчсез сабый, күңелем белән һаман
Сөйләштем мин ялгыз. Булмады
Тыңлаучы да. Шунда тудырдым мин
Үземә кирәк бүтән дөньяны.

Ә бу дөнья — рәхәт, җиңел дөнья! —
Нигезләре зәңгәр хыялдан,
Күк түбәле сарай, яшел киңлек
Нур чигәннәр белән уралган.

Янаса да изелү кысанлыгы,
Һәм караңгы көннәр җәфасы,
Мин тудырган җирдә узган көннең
Кабатланмас бәхет һәр кайсы...

Җанымны мин шунда калдым саклап,
Юлымны да үзем сайладым.
Текә ярлар, урман, яшерен сукмак,
Упкын, диңгез аша барамын.

Һавам чиста... Күңел көч җыйнады,
Тончыктырып юллар тузаны
Үтерә алмас аны...

Киләчәктә ләкин
Җитәрме көч?
Мин һаман да ялгыз шул әле...

Мин бар иткән шушы үземне соң
Хәзер ничек, кая куярга?
Килсен яшьләр
Нур чигәннәр белән
Уратылган гүзәл дөньяга.

Белсен яңа буын: бу сарайга
Упкын, ярлар узып барасы.
Каушамасын — гайрәт юлда керер,
Монда чиста, диңгез һавасы.

Килсен яшьлек, тончыктырмас аны,
Җиңә алмас
Урам тузаны.

1905.

## Хатыннар йөрәге

Үлын стенага терәп,
Төзәсәң мылтык,
Булырмы анадан йомшак,
Юаш сүз көтеп?

Куйсалар бикләп төрмәгә,
Сөйгәнен тотып,
Кем гаепләр: кыз йөзендә
Елмаю юк дип?

Туган абыйсын әгәр ул
Соңгы кат күрсә,
Әйт, ничек түзсен сеңлесе
Күз яшь түкмичә?

Иркәли генә беләме
Кызлар йөрәге?
Кузгата да ул арганны,
Боек йөргәнне.

Хатыннар йөрәгендә бар
Соклану һәм көч,
Һич кимеми сыйган тагы
Гаделлек һәм үч.

Үлсә дә ирләр буйсынмый,
Тукталмый һич тә:
Сөйгән йөрәкләрдә терелеп,
Һөҗүмгә китә!

1908

## Романс

Йөзе — кырыс, каты корыч ул,
Күзләрендә — сөю кайгысы,
Иркәләү күк йомшак тавышы:

«Канатларың — сынган шикелле,
Алар шундый көчсез тоела...
Сиздереп соң шуны ни була?!
Күз яшьләре түгеп юлыма,
Тайгак итмә басар җиремне,
Кыен итмә барыр юлымны.
Я, аерылыйк, җибәр кулымны.

Юлым — авыр, беләм үзем дә.
Ул — куркыныч, беләм үзем дә.
Авырайтма ләкин тагын да —
Кызгануың, бәгырем, сиздермә.

Көтсә мине егылу, һәлакәт,
Егылыйм мин таудан, биектән.
Гарип булсам, нигә мең тору? —
Кадерлерәк үлеп онтылу.
Андый түгел, бәгырем, мин — бүтән».

1908

Әхсән Баянов тәрҗемәләре.

# Таҗи Гыйззәтнең тууына 70 ел

## «Уйларым һәм хисләрем — халык белән»

*Театрларыбыз сәхнәләрендә аның пьесалары, драмалары, либреттолары әле бүген дә уңыш белән бара. Таҗи Гыйззәт драматургиябезнең зур мастерларыннан иде. Алай гына да түгел, ул татар совет драматургиясен яңа сыйфатлар белән баеткан, театр сәнгатебезгә үз өлешен керткән новатор драматург иде. Ул безгә дистәләрчә әйбәт сәхнә әсәрләре, күп санлы әдәби образлар калдырды. Тормышның барлык якларын иңләргә омтылган, зур иҗтимагый каршылыкларны гәүдәләндерүгә багышланган Таҗи Гыйззәт драматургиясе әдәбиятыбыз үсеше тарихында матур бер сәхифә булып тора. Таҗи Гыйззәт зур хисләр һәм зур проблемалар, монументаль полотнолар авторы иде. Соңыннан аның иҗатының бу көчле яклары бөтен татар драматургиясенең төп, асыл сыйфатларына әйләнде.*



*Быел, сентябрь аенда, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, артист һәм драматург Таҗи Гыйззәтнең тууына 70 ел тула. Шул уңай белән, журналыбызның бу санында язучының киң катлау укучыларга моңарчы таныш булмаган кайбер язмаларын, Башкорт дәүләт академия театрының артисты һәм режиссеры Имашов Б. исеменә язган зур күләмле хатын урнаштырабыз. Бу документларның кыйммәте «Ташкыннар» драмасының һәм шул исемдәге трилогиянең язылу тарихын ачыклау белән генә чикләнми. Алар күренекле драматургның әдәби-эстетик карашларын өйрәнү өчен дә әһәмиятле чыганак булачаклар.*

*Материалларны журнал редакциясенә язучының улы Казбек Гыйззәтов әзерләп бирде.*

## «Ташкыннар»

...«Ташкыннар»[1] әсәре өстендә елга якын эшләргә туры килде... Авылның ярлы батрак, урта хәлле крестьяннарының империалистик сугыш, буржуаз февраль революциясе аша бөек Октябрь социалистик революциясенә килүләрен художество образлары белән бирү өчен бик күп укырга, шул заманны бик нык өйрәнергә, тормышта булып узган күренешләрне, аерым кешеләрне халык арасыннан тупларга туры килде.

«Ташкыннар» әсәре минем иҗатымда иң күренекле урынны алырга тиеш. Чөнки мин аны халыклар азатлыгының егерме еллык бөек Октябрь бәйрәменә багышлап яздым һәм мин аның уңышлы әсәр булуына, тамашачылар тарафыннан зур алкышлар белән каршы алыначагына ышанам.

Таҗи Гыйззәт.

1937 ел, октябрь.

[1] «Ташкыннар» драмасын тәмамлау уңае белән язылган бу документ язучының шәхси архивында саклана.

Иптәш Имашов!

Мин сезнең хатыгызны алдым. Бөтен сорауларыгызга шушы хатым белән тулы җавап бирергә уйлыйм. Мин көз көне Галимовның[1] җибәргән хатына каршы җавап хаты язган идем. Шуннан соң минем белән хәбәрләшүче, хат язучы булмады. «Кызыл Татарстан»да чыккан рецензия турысында мәсьәлә болай. Мин сезгә рецензиягә кадәр үк анда күрсәтелгән кимчелекләрне төзәтеп җибәргән идем. Мәсәлән, Айсылу, Мирзахан, Артамоновлар турындагы соңгы төзәтмәләрне укыгансыз. Газетта күрсәтелгән кайбер моментларны тәнкыйть белән укырга кирәк.

...«Ташкыннар» әсәре театрда зур борылыш ясады. Шулай ук актерлар коллективының да күз өстендә торкан әсәре булып тора. Ике ай эчендә 31 тапкыр куелып, шыгрым тулы тамашачы белән бара. Тамашачы караганда рәхәтләнеп көлә, рәхәтләнеп җылый, соңгы пәрдәләрдә үзенең эчке шатлыкларын аплодисментка биреп артистларга уйнарга уңайсызлый. Без хәзер ничек кенә булса да шул аплодисментларны киметүгә чаралар күреп ятабыз. Әсәр турындагы шау-шу Мәскәүгә дә ирешкән. Ашыгыч рәвештә тәрҗемә ителеп, Малый театрның филиалы режиссеры Каверинскийга җибәрелде. Ярый, мәсьәләгә күчик.

«Ташкыннар»га бездә музыканы Җәүдәт Фәйзи иптәш язды. Музыкасы бик яхшы. Әсәрдәге образларны, шул эпоханы күрсәтүдә мастерларча башкарып чыкты. Анын язган көйләре тирән эмоциональ хисләр белән бирелгән. Бигрәк тә Гөлчирә, Гайнавал белән Наһар солдаткалар җыры. Айсылу, рекрутлар көе тамашачыны үзенә җәлеп итеп, хәзерге көндә халык арасына таралып бара. Мин Мәсәлим абзый Вәлиевне начар композитор димим. Шулай да мин Җәүдәт Фәйзи музыкасы белән куюны теләр идем. Мин бүген, Сезнең хатны алгач, Җәүдәт белән сөйләштем. Ул, әлбәттә, бик шатланды, ике арада килешү булгач һичбер тоткарсыз җибәрергә вәгъдә бирде. ...Минем Уфага бару мәсьәләсенә килгәндә берничә көнгә куелу көннәрендә булырга мөмкин дип саныйм. Кайчан куелуы турында алданрак хәбәр итәрсез.

Хәзер конкрет рәвештә бирелгән сорауларга җавап биреп китәргә уйлыйм. «Әсәрнең төп идеясе?» дигән сорауга болай дияр идем. ...Мин «Ташкыннар» әсәрендә крестьян арасында Шәүлихан старшина семьясы, Әхтәри староста, Твардовский, Лашманов кебек эксплуататорлар булу белән бергә, крестьян арасыннан чыккан тотнаклы, аң-белемгә ия булган, революция чорларында крестьян арасында җитәкчелек иткән Мирвәли, Артамонов кебек көчле большевик образлары бирергә һәм крестьян арасында төрле социаль катлауларның барлыгын һәм аларның сыйнфый көрәшләрдә нинди юллар белән революциягә килүләрен күрсәтергә теләдем. Кыскача әйткәндә, «Ташкыннар» әсәре крестьяннарның империалистик сугыш, буржуаз февраль революциясе аша бөек Октябрь социалистик революциясенә килүләрен күрсәтә. Дөрес, әсәр күләм ягыннан озын. Ләкин спектакльне ун-унбиш, егерме минут алдан бетерү теләге белән әсәрнең эчтәлегенә, образларның тулылыгына һәм аның политик ягына кимчелек китерерлек кыскартуга барырга ярамый. Без үзебез дә беренче унбиш-егерме минутларда бетерәбез. Ләкин бездә (минемчә) урынсыз паузалар, озын антрактлар бар. Баштагы I—II пәрдәләр һәм соңгы ике картинаны антрактсыз алып барганда әсәр һичшиксез унике тулганчы бетә торган әсәр. Шәүлихан пәрдәсендәге Биктимер һәм «сату» турындагы күренешләр бик кечкенә, алар әсәр өчен, әсәрдәге образларны ачу өчен кирәкле моментлар булып торалар.

Мирзахан хәзер ачык образ бит. «Кызыл Татарстан»да чыккан рецензия аның баштагы постановкаларына карата язылган иде. Чөнки баштагы берничә спектакльдә аны аңламыйча кул чабулар булгалады. Шуның өчен без аны ачыклату теләге белән икенче пәрдәдә спиртны аңардан бирдерү, өченче пәрдәдә Гөлчирә артыннан «ярый синдәй үч алучыларны минем күргәнем бар», дип кычкырып калуы һәм атасы белән булган талашында, үзе әйткәнчә, «строеннан риза булмыйча» түгел, ә бәлки «туып килә торган революциядән котылырга, үз сыйныфының интересларын саклап калырга» теләүче либераль буржуа вәкиле икәнлеген бик ачык аңлата.

Мирзахан, Ходаяр типлары... буржуаз милләтчеләрнең бер вәкиле бит. Шушы Мирзаханнар, Ходаярлар үзләренең кара теләкләрен тормышка ашыру теләге белән вакы-

[1] В. Галимов — Башкорт дәүләт академия театрының баш режиссеры.

тында кайбер ташламалар ясап, уңай эшләр эшләгән булып, халык алдында, партия, совет власте каршында үзләренә ышаныч тудырдылар. Шул ышанычларына таянып, корткычлык, шпионлык эшләре алып бардылар.

Мирзаханның ярлыларга бурычка товар бирү моментын төшерүгә каршы килмим.

Айсылу образы хәзерге вариант буенча ачык: заводта торучы гади бер татар кызы булган, ләкин сирәк кешеләргә хас булган аңардагы тотнаклылык, акыллылык, аңлылык «Ташкыннар» әсәрендәге хатын-кызларның берсендә дә юк. Аның Мирвәли өстеннән Биктимер картка әйтә торган сүзләре бар икән, беренчедән, ул Мирвәлине ярата, аңардан аерылмау теләге белән әйтә. Икенчедән, ул аны үзенең якынына — атасына сөйли бит. Өченчедән, кешеләр анадан туганда революционер-большевик булып тумыйлар. Алар тормыш кушуы буенча әкренләп үсәләр, үзгәрәләр. Һәрбер ярлы батрак, һәрбер эшче революционер булырга тиеш дигән сүз юк. Революционер-большевик булу өчен аң-белем, сәяси тәрбия кирәк. Сәясәт ул бөек бер фән, аны үзләштерү өчен хәзерләнергә, тәрбияләнергә, аерым чынығу кирәк. Айсылу образы минә шулай әкренлек белән үсә торган бер образ. Соңгы вариант буенча ул хәзер кооперациядә эшли, авылларга собраниеләр уздырырга йөри. Бу, әлбәттә, гади бер татар хатыны өчен зур үсеш. Бездә ул бик матур бара һәм актрисасы да яхшы уйный (Ильская). Ул сәхнәдә сөйләгәндә тамаша залында чебен дә очмый. Язылган рецензия баштагы вариантка карата иде.

Артамонов кем?

Артамонов крестьян арасыннан чыккан, бераз белемгә ия булган крестьян революционеры. Соңгы пәрдәдә волость большевикларының җитәкчесе. Авылда Октябрь революциясен хәзерләүче төп көчләрнең берсе. Мирвәли җир комитетының председателе булса, Артамонов волком секретаре, элемтә мөдире һәм крестьян арасында зур авторитеты булган организатор. Мирвәли белән алар бер пландагы кешеләр. Аның образы Биктимерләр тормышына... бәйләнмәгәнлектән шулай йомшаграк тоела. Ләкин революционер-организатор булу ягыннан караганда, әсәрдә бик зур фигура булып чагыла. Япон сугышы вакытында бишенче елгы революциядә катнаша, урманда кассир булып эшләгәндә байлар белән урман кисүчеләр арасында көрәшне оештыра, сәяси яктан ышанычсыз кеше булуы өчен патша жандармасының поднадзорасында тора, паспорт алып читкә китү правосыннан мәхрүм ителә. Кантужен булып сугыштан кайткач сөйләгән монологында солдат арасында эшләгәне, бу сугышта рус монархиясенең җиңеләчәген, ләкин Россия халкының җиңәчәген ачык итеп күз алдына китереп бастыра. Шулай ук революциягә кадәр аның крестьян арасында революцион эш алып барганы күренә. Мәсәлән, Мирвәли Гайнавалга акча биргәндә «минә бу хатны почтада эшләүче Артамоновка тапшыр. Ул сиңа ярдәм итәр, гомумән, сиңа аның белән бик нык бәйләнештә булырга кирәк», ди. Лашмановның старшинага Артамонов өстеннән сөйләгән сүзләрендә аның кандрашныйлар (ягъни алпавытта контракт белән ялланып эшләүче авыл хуҗалыгы эшчеләре), солдаткалар белән яшерен собраниеләр ясавы, алар арасында тәрбия эшләрен алып барганы (билгеле була). Шулай ук Февраль көннәрендә фронттан кайткан солдатлар, ярлы крестьяннарны оештырып, Шәүлиханнарны, земский начальникларны арестовать итә.

«Ташкыннар» кебек 27 образ катнаша торган әсәрдә бер кешегә шул кадәр урын бирү җитсә кирәк дип уйлыйм. Аны эшче итүнең икенче куркыныч ягы бар, ул вакытта без татар крестьяннарында Биктимер, Гайнавал кебек көчле типлар күрсәтеп тә, рус крестьяннарының революционлыгын смазывать итүгә барган булыр идек. Безнең әсәрдә эшче вәкиле булып Мирвәли тора. Артамоновны да эшче ясасак, бер-берләрен дублировать итә торган параллель образлар булып чыгарлар иде. Мирвәли турында газетта «ул атасы белән генә сөйләшә, крестьяннар арасында эш алып бармый», диелә. Бу дөрес түгел. Мирвәлинең бөтен тормышы революциягә, халык арасында эшләүгә корбан ителгән. Ул Лена вакыйгасы уңае белән булган демонстрацияне оештыра, партиянең кушуы буенча татар-башкорт эшчеләре арасында тәрбия эшләре алып бара. Беренче пәрдәнең башында Айсылу кереп: «Мирвәли сине бер хатын чакыра. Түбән очның Бәдернисасы», дип хәбәр итә. Атасы Биктимер болай ди: «Ә, Аблайныкылар җирен алдап алганнар иде, шул турыда киңәш-фәлән сорап килгәндер». Күрәсез, Мирвәлинең бу авылга кайтканына икенче генә көн булса да, ул инде халык арасына оеткы салып өлгергән. Кулак кабаласыннан котылырга ярдәм сорап аңа киләләр. Атасы белән

булган бөтен күренешләрендә, энеләре белән объездчик турында сөйләшкәндә, хәтта Гөлчирәнең алпавыт урманыннан җыеп кайткан җиләге турында да агитация алып бара бит. Шулай ук ул чәкчәк ашарга килгән Ходаярларга халыкара хәл турында сөйләп, аның милләтчелек фикерләренә отпор бирә. Дүртенче пәрдәдә аның кайтканына бер генә көн. Шулай булуга карамастан, ул үзенә кирәкле кешеләрнең өенә кереп йөргән. Каравыл өенә барып, җыйналган халыкка патша һәм начальстволар турында сөйләгән. ..Дүртенче пәрдәдә атасы белән сөйләшкәндә берничә кеше кертүгә каршы түгел. Ләкин сәхнәгә кергән кеше сөйләргә тиеш дип саныйм. «Мирвәли Гайнавалга акча бирә, аталарына бирми», дисез. Аларга да ярдәм иткән дип аңларга кирәк. Әгәр дә шунсыз мөмкин түгел дисез икән, Айсылуның: «Аларның тормышлары бик начар, актык куәсләрен изеләр», дигән сүзләреннән соң: «Ярый, әле син кайтып бераз ярдәм күрсәттең», дип өстәргә була.

Хөрмәтулла һичшиксез кирәкле тип. Ул кулакка үсеп бара торган зажиточный катлауның бер вәкиле булып әсәрдә күренә. Кулак, бай балалары ришвәт биреп сугышка бармый авылда калсалар, Хөрмәтулла кебекләр дә офицерларын, начальстволарын сыйлап денщиклыкта калалар. Ул гына да түгел, Хөрмәтулла шул сыйлаулары аркасында «батырлык» күрсәтүче геройга әйләнеп, георгиевский тәресе белән бүләкләнә. Соңгы пәрдәдәге аның Мирвәли белән сөйләшү күренеше, туган кардәшлеген читкә ташлап, үз сыйныфы интересын яклаучы дошман вәкил икәнлеген күрсәтә. Халыкча әйткәндә, «җан кардәш булса да, мал кардәш түгел бит». Икенчедән, бу күренештә Мирвәли, кияү, кардәш булуына карамастан, Хөрмәтулланың битлеген ертып ташлый. Аннан «Биктимер бик культуралы итеп сөйли» диелә. Аның «ләкин» дигән җөмлә башлары бар (дигәнсез). Аларны, әлбәттә, сызарсыз. Биктимерне эш өстендә күрсәтү мәсьәләсендә без үзебездә икенче пәрдәдә Мөршидә килү алдыннан дугалар сырлау эше белән шөгыльләнүен, өйдә берничә яңа дугалар күрсәтәбез. Сезгә дә аны кулланырга мөмкин. Ишек янында бер кечкенә станок кисәге һәм шунда столяр кораллары куя торган шүрлек бирергә була. Кызына кунакка бармыйча башка авылга эшкә җибәрү мәсьәләсе болай: ул бит кунакка бармый, Мөршидә аны, атасы булуына карамастан, эксплуатировать итү теләге белән алдап алып китә.

Гөлчирә образының соңгы пәрдәдә йомшак булуы турында сүзегез белән килешә алмыйм. Чөнки Гөлчирә гади бер кыздан агитаторша булу дәрәҗәсенә үсә. Әгәр дә Айсылу очрап Мирзаханнан физик үч алу теләгеннән кайтармаган булса, ул, һичшиксез, Мирзаханның йөзенә кислота сипкән булыр иде. Ләкин аны җиңгәсе Айсылу белән абыйсы Мирвәлиләр бу фикердән кайтарып заводка алып китәләр. Кислота сибеп үч алуга караганда, Мирзаханнарның сыйныфыннан үч алу эшенә этәрүләре безнең өчен кыйммәтрәк.

Мин үзем асылда башкорт, Алабуга өязендәге Асабар башкортлары дигән нәселдән. Әтиләр үзләрен башкорт дип йөртәләр иде. Бабай белән бертуган абыем 1871 елларда башкортлардан беренче солдат алу наборында солдатка алына. Ләкин безнең әйләнә тирәбез татар авыллары булганга, башкортның теле һәм гореф-гадәтләре бездә калмаган. «Ташкыннар»дагы өй Казан татарларында да күренми. Әмма безнең хәзерге Алабуга, Красный бор, Әгерҗе районнарында мин бала чакларда шушындагыча иде. Кыз алу, егет өйләндерү түбәндәгечә була иде: (моны әлбәттә, ярлы-батрак өе итеп аңларга ярамый, хәлле кешеләр өе) башта кызны кодалар аңлашалар — ярәшәләр. Аңлашу мәҗлесендә тарту, бирнә, калым условияләре ясалып, туйның көне билгеләнә. Шуннан айлар буе ике якның туйга хәзерлеге башлана. Туй көне җиткәч кыз йорты, кыз нәселе (кыз торган авыл) кунак-кодаларга хәзинәсендә булган барлык байлыгын сарыф итә. Шул көнгә башка авыллардан кунаклар чакырыла. Бер көнне туй башлана. Егет ягы бөтен нәселе белән пар атлар җигеп, терлек, дирбияларын бизәп, кыңгыраулар тагып, биш-алты чанада кыз йортына туйга киләләр. Ашау-эчү башлана, никах укыла. Шул көнне кич белән кодаларны кыз як кодалары үз йортларына кунакка алалар. Шулай итеп кодалар, биш-алты төн өйдән-өйгә кунып, өйдән-өйгә йөреп, кунак булалар. Туй китә. Ике-өч көннән кызның атасы берничә ышанычлы батыр егетләрне атына утыртып кияү алдырырга җибәрә. Кияү йортында зур хәзерлек белән кияү алуга килүче егетләрне көтә, һәм шул мәҗлескә егет үз авылының фәкать егетләрен генә ашка җыя. Бу аштагы төп максат кыз йорты тарафыннан кияүгә җибәрелгән чәкчәкне ашау. Ашка килгән егетләр чәкчәкне авыз иткәннән соң, һәркем хәле хәленчә, чәкчәк

котлап, табынга алдан ук куелган җиз подноска яисә зур тарелкага, чалтыр-чолтыр итеп, көмеш тәнкәләр салалар. Шушы мәҗлес үткәннән соң, кияү егетләре кияүне кыз янына алып китәләр. «Ташкыннар»дагы Хәйбул менә шуларның берсе. Яшь чагында Мирвәли дә бик күп кияүләрне кыз белән кавыштырырга катнашкан егет. Шуның өчен дә гореф-гадәтләрне бик яхшы белә.

Соңгы пәрдәләрне һич кыскартырга ярамый. Үзегез беләсез, бу бик җитди, бик җаваплы пәрдәләр. Бу текст установить ителгән, безнең коллектив белән эшләнгән текст. Кайбер вак-төяк кыскартулар үткәрергә, кабатлана торган җөмләләрне сызарга да мөмкин. Ләкин гомумән алганда көрәшнешләрне төшерү эшенә барырга ярамый.

Мин иртәгә фотокарточкаларны җибәрү турында дирекция белән сөйләшәм. Ничек тә күндерергә тырышырмын.

Без быел «Төшемле урын», «Ташкыннар», «Фигароның туе», «Чик сакчылары» исемле нәрсәләр чыгардык. Тиздән Әблеев дигән иптәшнең «Шәмсекамәр» дигән әсәре әзер була. Аннан «Корыч ничек чыныкты», аннан минем «Бишбүләк» исемле әсәремне куярга уйлыйлар. Шушылар белән быелгы эш планы чикләнә.

...Быел безнең эшләр шәп. Халыкның театрга йөреше елдагыга караганда гаҗәеп рәвештә югары. Мәскәүдән чакырылган Фрид дигән зур режиссер «Фигаро» постановкасын куйды. Зур уңышлар белән бара. «Шәмсекамәр» дә яхшы, «икмәкле» әсәр булыр дип торабыз.

Хәзергә шуның белән сүзне бетереп эшегездә зур уңышлар телим. Бөтен иптәшләргә миннән сәлам диярсез. Хат язып торыгыз. Аңлашылмаган нәрсәләр булса сорагыз. Тагын бер үтенеч: «Ташкыннар» әсәрен уйнаганда, артык кайгы, хәсрәт якларга басым ясап, әсәрдәге батырлык пафосын җуюга барылмасын. Бигрәк тә Биктимер карт образында сак булырга кирәк. Соңгы пәрдәләрдә көрәшкә сәләхиятле булган көчле крестьян картын китереп бастырырга кирәк. Шушы хат белән Шәүлихан пәрдәсенә кечкенә генә бер төзәтмә дә җибәрәм.

Шәүлихан. Унбиш ел старшина булып, берничә медальләр алган атаң шундый сүзләр әйтергә как син имеешь право.

Мирзахан. Бу сүзләрне, эткәй, мин генә түгел, илебезнең һәлакәттән, революциядән саклап калырга теләүче һәрбер укыган, аңлы кешеләребез шулай дип әйтәләр. Әгәр дә без тизлек белән чара күрмәсәк, тиздән өстебезгә кара халык талпасы ябырылып киләчәк тә, һәммәбезне җир өстеннән себереп түгәчәк. Үзең уйлап кара, эткәй, дәүләт аппаратларында эшсезлек һ. б.

Сәлам белән: Таҗи Гыйззәт.

8 февраль, 1938 ел.

## АВТОРДАН

«Ташкыннар» драмасының беренче варианты 1936—1937 елларда язылып, бөек Октябрь социалистик революциясенең XX еллыгына багышланып, Татар дәүләт академия театрында куелды.

Заманында бу әсәр һәм аның постановкасы киң җәмәгатьчелек һәм тамашачылар тарафыннан зур алкышлар белән каршы алынды. 1941 елга кадәр өзлексез рәвештә татар һәм башкорт театрларында уйналып килде.

1941 елның ноябрь аенда Мәскәүдә булачак татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы өчен дә махсус рәвештә әзерләнгән иде. Ләкин немец фашистлары илебезгә искәрмәстән һөҗүм итү сәбәпле тәгаен ителгән ул декада булмый калды.

Автор бу әсәрен язганда бөтен крестьян катлауларының 1914 елгы беренче империалистик сугыш, февраль буржуаз демократик революциясе аша бөек Октябрь социалистик революциясенә нинди юл белән килүләрен күрсәтүне максат итеп куйган иде. Ләкин илебездә булып узган бу өч зур вакыйганың бер драма әсәрендә бирелүе авторны канәгатьләндермәде. Шуның өчен ул 1942 елны «Ташкыннар» драмасын өч кисәккә бүлеп «Шомлы көннәр», «Даулы көннәр», «Данлы көннәр» исемнәре белән атап, трилогия язу эшенә кереште. Трилогиянең беренче һәм икенче серияләре 1943 елда язылып, журналда басылды. 1947—1948 елларда ике сериясе Татар дәүләт академия театрында яңадан куелды. Өченче сериясен язу озаккарак сузылса да, автор аны быел тәмам итеп театрга һәм издательствога тапшырды.

1952 ел. Автор Таҗи Гыйззәт.

*Сәрвәр Әдһәмова*

# ГАЛИМҖАН АБЫЙ ҺӘМ АНЫҢ БЕЛӘН УЗГАН КӨННӘР ТУРЫНДА

1923 елның көзендә, Томскидан Казанга килеп, өлкә юридический курсларга укырга кергәндә, минем үземнең дә балалар өчен пьесалар язып, язучы булырга хыялланып йөргән чагым иде. Шуңа күрә, ул чорда әле Татрабфакта, әле Комклубта еш кына уздырылган әдәби кичә һәм диспутларга бик кызыксынып йөри идем. Гадәттә, ул кичәләрдә күбрәк Шамил Усманов, Һади Такташ, Кави Нәҗми, Гадел Кутуй кебек яшь язучылар була торган иде. Бер тапкыр Комклубта оештырылган кичәләрнең берсенә, ничектер, Галимҗан Ибраһимов та килде. Беренче мәртәбә шунда күрдем мин танылган язучыбызны. Ул, төсе-бите беләнме, кай ягы беләндер, миңа портретлары буенча таныш Максим Горькийны хәтерләткәндәй булды. Игътибарымны, барыннан да бигрәк, Галимҗан Ибраһимовның бераз кырыс, шул ук вакытта бик акыллы күз карашы җәлеп итте.

Ә танышуын соңрак (1924 елның язында булса кирәк), «Безнең юл» журналы редакциясенә эш илткәндә таныштым. Эш дигәч тә, әллә ни эш кыйрату түгел иде инде. Ул елларда, татарча язу машинкалары булмаганлыктан, наборщиклар танымаслык кульъязмаларны күчертеп яздыралар иде. Һәм мин дә редакцияләрдән шундый эшләр алгалый идем.

Бара-тора, бигрәк тә, мин Кави Нәҗмигә тормышка чыкканнан соң, бу танышлык көннән-көн тирәнәя барды. Галимҗан Ибраһимов безнең күңелдә абыебыз, якын дусыбыз һәм киңәшчебез урынын алды.

Галимҗан абый, авырып, Казаннан Ялтага күчкәннән соң да арадагы бәйләнеш өзелмәде. Өзелмәде генә түгел, хәтта тагы да ныгый төште. Бу бәйләнеш, бердән, хатлар аша дәвам итте. Икенчедән, Кара диңгез якларына юл төшкән саен, ә кайчакта, ерак юлны якын итеп дигәндәй, Галимҗан абыйның хәлен белер өчен, махсус Ялтага бара торган булдык. 1929 елның җәй ахырында Кавказ, Кырым якларындагы тугандаш республикалар буйлап сәяхәткә чыккан бер төркем татар язучылары да (композитор Салих Сәйдәшев, артист Шакир Шамильский һәм бер-ике журналист та бар иде безнең арада), Кырымга житү белән үк, Галимҗан Ибраһимов белән күрешергә, аның хәлен белергә бардылар. Каты авыру, хәлсез булуына да карамастан, Галимҗан абый безне бик шатланып, ачык чырай белән каршы алды һәм сәяхәтебезнең ничек үтүе, кайларда кемнәр белән очрашу, ниләр күрүебез турында төпченеп сораштырды.

Ә 1930 елның җәендә Кави белән Сочига ял итәргә баргач, һич уйламаганда, Уфа язучылары Сәйфи Кудаш һәм Булат Ишемгуловны очраттык. Нәкъ шул көннәрдә Галимҗан абыйның Кавига 13 августта язган җавап хатын алган идек. (Ул хат «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 санында басылды.) «Сочидан Ялта аркылы кайтып, безгә керсәгез күңелле булыр» дигән юллар да бар иде ул хатта. Бу безгә житә калды, озак уйлап тормый, җилкенеп, Сәйфи Кудаш, Булат Ишемгуловлар белән бергә дүртәүләп пароходка утырып, Ялтага киттек. Галимҗан абый белән бу очрашуны Сәйфи Кудаш «Онытылмас минутлар» исемле истәлекләр китабында шактый тулы искә төшереп үтә...

Ялтага 1932 ел бару хәтердә аеруча яхшы сакланган. Хәер, ул баруда бер-ике сәгать яисә бер-ике көн генә түгел, бер айга якын торылды шул анда. Ул елның апрелендә мин, Мисхордагы «Коммунарлар» санаториясендә дәваландым да, путевка срогы тулгач, Ялтага Галимҗан абый квартирына күчеп килдем. Берничә көннән, отпуск вакыты җитеп, Казаннан Кави дә килеп төште. Безнең гостиницага күчәргә уйлаганны белгәч, Галимҗан абый:

— Ник анда күченеп маташырга? Минем бер бүлмә буш бит әнә, тора бирегез шунда, чирем йогудан курыкмасагыз. Сезнең белән миңа да күңеллерәк булыр, — диде.

Бер ел гына элек Галимҗан абыйның бердәнбер баласы — яраткан Рөстәме үлгән иде. Аның ялгызлыгын һәм күңеле әле дә шактый төшенке булуын искә алып, без Галимҗан абый квартирында торып калдык. Ул һаман шул Халтурин урамындагы 5 нче йортның икенче катында, ике бүлмә һәм верандалы квартирда тора иде. Дәвалану режимын элеккечә нык саклый һәм сәламәтлеге дә элекке еллардагыга караганда бераз яхшыра төшкән иде ул чакта (Без Казанга кайтып киткәч, бер-ике айдан соң (30. VII) язган хатында: «Үзем тазарам, үлчәү һаман арта бара» дип әйтеп үтә ул.)

Галимҗан абыйның йорт эшләрен шактый олы яшьтәге, былкылдап торган тулы гәүдәле бер украин карчыгы (исеме хәтердә калмаган) башкара. Ул иртә килеп кич китә. Болай үзе шат күңелле, бертуктаусыз сөйләнә, ләкин еш кына, кәефе кырылып, мыгырданырга ярата. Галимҗан абый, аның холкын һәм шапшаклыгын өнәмәсә дә, түзәргә мәҗбүр, чөнки яраклы кеше табуы җиңел түгел.

Гадәттә, көн шул карчык килүдән башлана. Мин барып ишек ачуга, ул, һәркөнне диярлек, көр күңел һәм шактый калын тавыш белән: «Тетя Соня, тетя Соня! Вам посылка из Херсона! А в посылке три миллиона, аяй, яй», дип такмаклап (ул чорда андый такмаклар модада иде) килеп керә. Аннары коридор буйлап туп-туры верандага уза да, уң як почмактагы (иске ак киндер чаршау белән бүленгән ул почмак кухня хезмәтен үти иде) өстәл өстенә кулындагы кәрзинен куеп: «У вашего чабана хлеба-соли нема, а у нашего чабана всего-всего полно», дип сөйләнә-сөйләнә, базардан алган әйберләрне бушатырга тотына. Ә кайбер көннәрдә ул тантаналы тавыш белән:

— Вот и птички,— дип, кәрзиннән бер-ике бүдәнәне алып, кулында бераз селкеп торганнан соң, өстәл өстендәге яшелчәләр янына куя (Ит, азык-төлек мәсьәләсе Ялта кебек зур курорт шәһәрендә аеруча читен иде ул елларда. Шуңа күрә Галимҗан абыйга, Ялта партия, совет оешмалары тарафыннан бирелгән паегы беткән чакларда, еш кына шул йодрык хәтле бүдәнәләр белән ризыкланырга туры килә. Ләкин яз көне ул бүдәнә дә бик сирәк, җитмәсә тагы үтә ябык була торган иде.)

Шунда әбинең тавышын ишетеп, күгелҗем халатын иңбашына гына салып, үз бүлмәсеннән Галимҗан абый да килеп чыга һәм бераз вакыт кухня өстәле өстендәге «натюрморт»ка карап тора. Ул арада әби базардан нәрсә алганын, ул әйберләрнең һәркайсына күпме түләгәнен бер-бер артлы тезеп, хисап бирергә тотына. Карчык аңа гадәттә «хозяин!» дип эндәшә. Бу сүзне Галимҗан абыйның җене сөйми иде. Исәп-хисабын бетергәннән соң, әби, керосинка ягып, иртәнге аш әзерләргә керешә. Иртәнге аш өлгергәнче, Галимҗан абый белән Кави я верандада, я ишек алдындагы бакчада сөйләшеп утыралар. Ашап-эчкәннән соң, яңа килгән газеталар белән танышалар. Аннан Галимҗан абый, үз бүлмәсенә кереп, бераз ял итә дә, караватында аркасын мендәргә терәп утырган килеш, китап укый, ә кәефе яхшы булган көннәрдә язарга утыра. Ничек өлгерә иде икән ул, белмим. Ләкин шул авыру хәлендә дә матур әдәбият өлкәсендә яңа чыккан китапларның һәркайсын диярлек укып, яисә һич югы күздән кичереп барырга вакыт таба иде.

Ул, гомумән, китап җыярга яратса да, үзенең Ялтада яшәвен вакытлы бер хәл дип караганлыктан булса кирәк, анда үзенә аеруча кирәкле китапларны гына сатып алып, гадәттә шәһәр китапханәсеннән файдалана. Хәер, бу чорда аның акча ягы да шактый кысан һәм квартирында артык шкаф куярлык урыны да юк иде. Ялта шәһәр китапханәсенең архивы сакланган булса, ул еллардагы картотекалар буенча, Галимҗан Ибраһимовның ул китапханәдән даими рәвештә файдалануын һәм нинди китаплар алып укыганлыгын белергә булыр иде.

Китап дигәннән, шул 1932 елны, Ялтада торганда, күңелсез хәлгә тарыдым мин бер тапкыр. Көннәрдән бер көнне Галимҗан абый миңа:

— Укымаган булсаң, Николай Тихоновның бу китабын укып чык әле син, Сәрвәр, — дип, «Сугыш» исемле повестьны бирде.

Ул минутта мин, ниндидер йомыш белән, Набережная урамына барырга җыена идем. Кайтышлый шәһәр бакчасында ял иткәндә укырмын дип, китапны үзем белән алып киттем. Һәм бакчада утырып укый да башлаган идем мин аны. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, әле күптән түгел санаторийдә бергә дәваланган хатын очрады да, аның белән сөйләшә-сөйләшә эскәмиядән торып киткән чакта, китапны онытып калдырганмын. Ярты юлга җиткәч, исемә төшеп, кире йөгереп бардым баруын, ләкин китаптан җилләр искән иде инде...

Галимҗан абыйга шунда ук әйтергә курыктым, билгеле. Иртәгесен китап кибетенә дә барып карадым, булса сатып алырмын диган идем. Ләкин анда да юлым уңмады. Галимҗан абыйның китапларга карашын, аларны шундый кадерләп тотуын белмәсәм, ул дәрәҗәдә борчылмас та идем. Китапханә китабы бит әле җитмәсә! Шулай эчемнән генә ут йотып йөргәндә, Галимҗан абый:

— Я ничек «Сугыш»? Ошадымы? — димәсенме.

— Ярыйсы кебек. Укып бетермәдем әле, — дидем дә, каушавымны сиздермәс өчен, чаршау артына кереп киттем.

Ә икенче көнне инде ул:

— Китапханәгә төшеп менмәссеңме, Сәрвәр? Аннан алган китапларның срогы тулды бит. Менә тагын боларын алып кайтырсың, — дип, кулыма берничә китап исеме язылган кәгазь кисәге тоттыргач, мин, җир ярылса, җир тишегенә керердәй булып, «Сугыш» повесте белән казага калуымны сөйләп бирергә мәҗбүр булдым.

Галимҗан абыйның чырае кинәт әллә ничек кырысланып китте.

— Их, исәр! Оятлы иттең син мине. Моннан соң ул китапханәгә барганда ни битем белән күренермен, — диде дә борчулы уйга талгандай булып тынды.

— Сез гаепле түгел бит, Галимҗан абый, үзем барып сөйләрмен, аңлатырмын. Бөтенесе рәтләнер, борчылмагыз, зинһар, — дип, аны тынычландырырга тырыштым мин.

Сүзгә Кави дә кушылды. Ул китапны, ничек тә, Мәскәүдән табып җибәрергә вәгъдә иткәч, Галимҗан абый бераз тынычлангандай булды-булуын, ләкин чырае бөтенләй үк ачылып җитмәгән иде әле. Шуңа күрә китапханәдән кайтуыма верандада Шакир Даутовны[1] күргәч, бик шатландым. Үтә тыйнак, тыныч табигатьле, бик сөйкемле бу иптәшне Галимҗан абый ифрат ихтирам итә һәм, бертуган энесе кебек күреп, ярата иде. Даутов иптәш үзе дә, Галимҗан Ибраһимовка тирән ихтирам белән карап, кирәкле даруларны табу, азык-төлек паегы белән тәэмин итү кебек эшләрдә бик күп ярдәм итеп, аның турында еллар буе өзлексез кайгыртып торды. Шундый җаваплы урында эшләвенә, үзенең төп эше дә муеннан булуга да карамастан, Даутов иптәш, әледән-әле Галимҗан абый янына килеп, аның хәлен белергә, озаклап сөйләшеп утырырга да вакыт таба иде.

Аның турында Галимҗан абыйның:

— Чын ленинчыл большевик ул безнең Шакир! Татар әдәбиятын да укый әле үзе! — дип, шатланган да, гаҗәпләнгән дә кебек әйткән сүзләре хәтеремдә калган.

Инде кояш баеп килә. Галимҗан абый, Кави, Шакир Даутов өчесе верандада бик иркенләп сөйләшеп утыралар. Әби кайтып киткән иде, мин чәй әзерләргә керештем. Чәйдән соң Галимҗан абый:

— Карта уйнап алабызмы әллә, егетләр, әй? Шакир, синең вакыт ягың ничек, ашыкмыйсыңмы? — диде.

Кәефе аеруча күтәренке чакларда ул ара-тирә алтмыш алты уйнарга ярата. «Карта уйнаганда баш ял итә, бүтән бернәрсә турында да уйламыйсың», ди торган иде.

Өстәлне бушатыр өчен, тиз генә табынны җыярга керештем. Галимҗан абый үз бүлмәсенә карталар алырга кереп киткән арада, Кавине бер читкәрәк алып китеп:

— Синең белән без бер яклы булыйк яме? Отарга тырышмыйк, — дидем (Үзе сер бирмәскә тырышса да, отылган очракта Галимҗан абыйның чын-чыннан кәефе кырыл-

[1] Шакир Даутов ул елларда ВКП(б)ның Ялта шәһәр комитеты секретаре булып эшләде. Хәзерге көндә Казанда яши. Персональ пенсионер. Аның Галимҗан Ибраһимов турындагы истәлекләре «Совет әдәбияты» журналының 1962 ел, 3 санында басылды.

ганын белә идек.). Ләкин андый чакта, үч иткәндәй, яхшы карта кирә бит әле. Кави белән узара сүз куешуга да карамастан, бер-ике тапкыр отмый да булмады. Шулай да шаулашып, көлешеп бик күңелле утырдык. Һәм мин теге повесть турында артык сүз кузгалмас дип уйлаган идем инде. Ялгышканмын икән. Даутов кайтып киткәч, Галимҗан абый тыныч кына:

— Я, ничек? Эшне җайладыңмы, Сәрвәр? Җайласаң ярый. Хәзер минем сиңа бер тәкъдимем бар. Тихоновның ул повестен Кави Мәскәүдән табарга булды бит. Сез аны ике данә алыгыз. Берсен миңа җибәрерсез. Берсен син үзең ал да, Казанга кайткач, татарчага тәрҗемә ит. Әсәре дә бик үзенчәлекле, кирәкле әсәр... — диде дә, бераз тынып калганнан соң, көлемсерәп, — Ялтада уздырган көннәрнең дә истәлеге булыр, — дип өстәде. «Синең өчен гыйбрәтле истәлек булыр. Китап кадерен белергә кирәклекне исеңә төшереп торыр ул», дип әйтергә дә теләгәндер, бәлки, эченнән генә.

Һәрхәлдә, ул вакыйга минем өчен онытылмаслык бер сабак кебегрәк булды. Ә «Сугыш» повестен Казанга кайту белән үк тәрҗемә итәргә тотындым. 1933 елда ул басылып та чыкты. Һәм әле хәзер дә китаплар актарганда шул повестьне күрсәм, 1932 елның язы, Ялта, Галимҗан абый үзе һәм аның белән бергә үткәргән көннәр җанланып күз алдыма килеп баса.

*

* *

Ялтага шул баруыбызда ук Галимҗан абый алдында тагын бер тапкыр һәм элеккесеннән дә битәр адәм көлкесе булдым әле. Шулай беркөнне әби, базардан гөрләп, шаулап кайтып керде дә, черешня өлгерүен әйтте. Чәй эчәргә утыргач, Галимҗан абый, сүз арасында гына:

— Вареньесы тәмле була торган иде ул черешняның. Ләкин әлеге шул шикәр... — дип куйды.

— Кайнатырбыз. Кави шикәр алып килде бит, — дидем мин аның сүзен куәтләп. Кави Казаннан үзебезнең паек шикәрен алып килгәч тә, аның бер-ике килосын шул ният белән җыеп куйган идем. Шунда ук базарга да йөгермәкче идем инде, ләкин Галимҗан абый:

— Тукта әле, ашыкма. Беренче көннәрдә әле рәтләп тәм дә кереп җитмәгән була аңа, бәясен дә яхшы каералар... — дип, бераз сабыр итәргә кушты.

Ике-өч көннән соң, бик олыдан кубып, черешня алып кайткан идем дә, изелә торган сорт булып чыкты. Әби мондый черешнядан варенье кайнатырга киңәш бирмәде. Ара шактый ерак булса да, икенче тапкыр барырга туры килде. «Булгач булгач, ботка булсын» дим инде, үземчә. Нинди ботка буласын белмим әле...

Шулай, базар белән ике арада килеп сарып йөри торгач, ярты көн үтеп тә китте. Ниһаять, аш пешеп, чәй кайнап, керосинка бушаганнан соң гына, вареньены кайнатырга тотынырга туры килде.

Ул көнне кич Ялта шәһәр театры бинасында, нинди уңай беләндер, бер җыелыш булырга тиеш, һәм анда Галимҗан абый белән бергә без дә чакырылган идек. Җыелыш башланырга бер сәгатькә якын бар иде бугай әле, Галимҗан абый верандага чыгып:

— Әйдә киен инде, Сәрвәр! — дип, мине ашыктыра башлады.

— Иртә бит әле, Галимҗан абый, — дим, вареньеның күбеген ала-ала.

— Минем кичегеп йөрергә яратмавымны беләсең бит. Минем йөреш белән анда барып җиткәнче дә байтак вакыт кирәк. Әйдә җыен. Көзге алдында озак маташма тик! — дигәч, керосинканың утын баса төшеп, бүлмәгә кереп киттем. Үзем киенгән арада варенье җай гына кайный торсын, янәсе. Ләкин мин өсбашымны да алыштырып өлгермәдем, Галимҗан абый бүлмә ишеген шакып:

— Булдыңмы, Сәрвәр! Киттек, — диде.

Коридорга чыксам, ул инде пальтосын да, эшләпәсен дә кигән, бер кулына таягын, икенче кулына өй ачкычын тоткан килеш, ишекне бикләп чыгып китәргә әзер тора.

Өчәүләп театрга таба киттек. Без барып җитүгә озакламый җыелыш башланды. Галимҗан абый президиумда иде. Җыелышның рәсми өлеше беткәннән соң, ул безнең янга партерга күчеп утырды. Исеме хәтеремдә калмаган, ниндидер ике пәрдәлек пьеса

да әзерләгәннәр икән. Аны да карарга булдык. Галимҗан абыйның кәефе күтәренке иде.

Шулай тыныч кына театр карап утырганда, кинәт яшен суккандай булды. Керосинкам янган килеш калган бит! Шул вакытта ук кайтып китәргә генә иде миңа. Галимҗан абыйга дөресен әйтсәм, кинәт курку, борчылудан аңа, авыру кешегә, бер-бер хәл булмагае дим. Нинди дә булса бүтән сылтау эзләп табарга башым эшләмәде. Пьесаны карап бетергәнче, инә очында утыргандай, боргаланып утырдым. Ниһаять, спектакль тәмам булуга, сабырсызланып урынымнан сикереп тордым да:

— Өй ачкычын бирегез, Галимҗан абый. Сез җай гына атлап кайтканчы мин чәй кайната торырмын, — дигән булдым. Чәй кайнатудан бигрәк, алдан үзем кайтып күрәсем килде өйдәге хәлне.

Пальто кесәсеннән ачкычны алып биргән чакта, ул:

— Әйе шул. Вареньe белән чәй эчәрбез, әле әйбәтләп, — дип, эчтә янган утны тагын да дөрләтеп җибәрде.

Мин, бер сүз дәшмәстән, күземә ак-кара күренми, театрдан чыгып чаптым. Ул чагындагы кичерешләремне тулысынча тасвир итеп бирү дә читен хәтта. Вареньe турында уйламыйм да инде. Шикәре бик кадерле булса да, аннан да ваз кичкәнмен. Өйгә якынлашкан саен берсеннән берсе куркыныч күренешләр күз алдыма килә башлады. Керосинкадан чаршауга ут кабынган булуы бик ихтимал бит. Кухня өстәленнән ерак түгел ич ул чаршау. Хәзер йорт дөрләп янадыр. Йорт, андагы бөтен әйберләр... һәм шунда кинәт кылт итеп, Галимҗан абыйның кулъязмалары искә төште дә, әллә ничек башым миңгерәүләнеп китте, тез буыннарым калтырый башлады. Керосинканың янган килеш калуы исемә төшкәч үк кайтып китмәвем өчен үз-үземне әрли-әрли йөгердем.

Ниһаять, Халтурин урамы чатына да җиттем. Янгын машиналары күренмәгәч, эчемә аз гына җылы кергәндәй булды. Тәмам эштән чыгып, әлсерәп кайтып җитеп, мәтәлә-кадала баскычтан менеп ишекне ачып җибәрсәм... коридор, веранда җирдән төтен. Бәхеткә каршы, ярый әле мае янып бетеп, керосинка үзе сүнгән булган. Ә вареньe... ташкүмергә әйләнгән диярлек. Ансы, ансы! Эмальле кастрюль бөтенләй эштән чыккан, адәм карарлык түгел. Төтен таралсын өчен, тиз генә веранда тәрәзәләрен ачып җибәрдем. Керосинкага яңадан керосин салып, чәйнекне утыртуга, Галимҗан абый белән Кави кайтып керделәр. Өйдәге хәлне аларга озаклап аңлатып торырга туры килмәде. Төтен таралып бетмәгән иде әле.

Шунда Галимҗан абый минем хәлне чыраемнан аңладымы, белмим, ләкин бер генә авыр сүз дә әйтмәде, шелтәләмәде.

— Ашаттың вареньe! — дип көнә куйды. Аннан бераздан, мине юатырга теләпме: — Миндә дә гаеп бар. Мин ашыктырдым шул. Ярый, хәерле каза булсын, — диде.

Аның каравы, иртәгесен әби бирде кирәкне... Нибар байлыгы ике кастрюльдән торган йортта шуның берсе эшкә яраксыз булып калу бик сизелерлек каза иде шул. Хәзер, безнең кибетләрнең киштәләре генә түгел, хәтта идәннәре дә савыт-саба белән тулган заманда, бу бик әһәмиятсез һәм, бәлки, көлке бернәрсә булып тоелыр. Ләкин ул елларда көнкүреш әйберләрен җитәрлек эшләп чыгару мөмкинлеге юк иде шул әле. Шуңа күрә әбинең, ике кулсыз калгандай булып, мине Ялтадан киткәнче һәркөнне диярлек табалавы бик табигый иде. Соңыннан, Казанга кайтышлый, Мәскәүдән бер кастрюль табып җибәреп, Галимҗан абыйдан бигрәк әбине ризалатканбыздыр дип уйлыйм. Ялтада исә торгсин магазинында туры китерә алмаган идек аны.

* *
*

Торгсин дигәч [1], искә төште әле. Бер тапкыр мин Галимҗан абый өчен дә файдалы, үзебезгә дә тансык ризык дип, Ялтаның торгсин магазинынннан берәр банка куе сөт белән какао алып кайткан идем. Шуны кайнатып табынга куйгач, Галимҗан абый, миңа күтәрелеп карады да:

[1] Ул елларда Торгсин магазиннарында алтын, көмеш тапшыручыларга товар алыр өчен бона бирәләр һәм кайберәүләр, үзләре кибеттән әйбер алмый, боналарын шунда магазин ишек төбендә үк сатып тора торганнар иде.

— Каян алдың моны? Паекка бирмәгәннәрдер ич? — дип сорады.

— Юк, — мин әйтәм. — Торгсиннан алдым.

— Нәрсә? Йөзегеңне бирепме әллә?

— Юк ла. Үзебезнең совет акчасына.

— Бернәрсә дә аңламыйм. Ә-ә! Бона сатып алыпмы? Ул хакта, ничектер, колагыма кергән иде бугай бер. Күпме тора соң ул бона дигәннәре?

— Төрлечә була, — мин әйтәм, — алтын исәбе белән бер сумлык бонаны бүген 37 сумнан саталар иде.

— Чеп-чи спекуляция бит бу! — диде Галимҗан абый ачуланып. — Күрәсеңме, Кави, спекуляциянең баш тыкмаган җире юк. Ә сиңа андый паразитлар белән алышбиреш итмәскә киңәш бирәм, Сәрвәр.

Аннан ул, бераз уйга чумгандай булып утырды да, тагын сүз башлады:

— Карап-карап торам да, акчаны бик абайсыз туздырасыз сез икегез дә. Кирәккә дә, кирәкмәскә дә... Бер дә алдын-артын уйламыйсыз. Ай саен аз-азлап экономия ясап, саклык кассасына сала барырга кирәк. Русларның «на черный день» дигән гыйбарәсе бар бит. (Бу сүзләрне ул шулай русча әйтте.)

Аңа каршы Кави:

— Безнең заманда нинди кара көн булуы мөмкин, — дигәч, Галимҗан абый:

— Мин дә туры мәгънәсендә әйтмим аны, ләкин дөнья булгач, ни булмас! Аннан тагын берәр нәрсәгә тоташ акча кирәк булып куюы да бар бит. Хәер, мин күргән хәтле нужа күрмәгәнсез шул сез. Акча кадерен белмисез. Бер шырпыны дүрткә ярырга туры килгән чакларым булды минем заманында, — дип сүзен очлады.

Шул көнне микән, әллә иртәгесен микән, ансын ачык хәтерләмим, аштан соңгы чәйне эчкәч, Галимҗан абый:

— Көн бик әйбәт. Набережнаяга төшеп, диңгез буенда йөреп кайтмыйбызмы? — дигән тәкъдим кертте.

Аның кәефе яхшы көннәрдә без, ара-тирә, шулай йөрергә чыгып керә идек. Башта яр буенда, тын диңгез өстенә карап, сөйләшә-сөйләшә, озак кына ял итеп утырдык. Шунда диңгез буе аллеясында рәсемгә төшереп торучы бер фотограф бәйләнде үзебезгә. Ул көнне рәтләп төшеме булмаган, күрәсең. «Ярый әйдә, бер истәлек булыр» дип, өчәүләп рәсемгә төштек. Мине урындыкка утыртып, Галимҗан абый белән Кави икесе ике якка басып төшкәннәр иде. 5—10 минутта эшләп тә бирде аны фотограф. Ләкин, кызганычка каршы, ул рәсем миндә, ничектер, сакланмаган. Берәр сәгать чамасы ял иткәннән соң, кичке ашны да ашап чыгарга булып, юл өстендәге кафе-ресторанга кердек. Кечерәк кенә, бик чиста бу ресторанда гадәттә кеше аз була һәм без, йөрергә чыкканда, һәркайчан диярлек шунда кереп ашый торган идек.

Ишектән керүгә швейцар, Галимҗан абый белән исәнләшеп, аның хәлен сорашырга тотынды. Алар икесе сөйләшкән арада, Кави белән без, эчкә үтеп, официантка заказ бирә тордык. Ашыкмыйча, озаклап утырып, кичке ашны ашаганнан соң, кайтырга киенгәндә, Галимҗан абый, гадәтенчә, швейцар картка күпмедер, һәрхәлдә шактый мул, чәйлек бирде.

Урамга чыккач:

— Сезнең эшләпәгез белән таягыгыз бик кыйбатка төшә болай булса, Галимҗан абый. Кави белән мине юкка-барга акча туздырган өчен шелтәлисез. Ә үзегез ашарга кергән саен шул картка әллә нихәтле чәйлек бирәсез, — дигән идем, ул:

— Анысы бөтенләй икенче эш. Ул татар язучылары ярлы икән дип уйламасын дим. Мин — бай, шайтан — ярлы дигән сүз бар бит. Чәйлек бирүне гомумән хупламыйм да мин үзем. Ләкин гасырлар буе килгән ул йоланы бетерер өчен байтак көрәшергә туры киләчәк әле. Аннан соң тормышы да бик авыр ул картның, — дип җавап бирде.

Бер тапкыр Галимҗан абый белән икебезне Кави утка-суга салды әле. Май ае. Виноградның искесе беткән, яңасы өлгермәгән чак. Врачлар Галимҗан абыйга виноград суы эчәргә киңәш биргәннәр иде. Аны, күбесенчә, Массандра шәраб подвалының Ялтадагы магазинында табарга була. Ул магазинның директоры Рәхмәтуллин (Татарстанныкы иде бугай ул үзе) Галимҗан абыйны белә, бик ихтирам итә, кайчакта:

— Менә монысы Галимҗан Ибраһимовка минем күчтәнәч. Үзе эчмәсә дә, читтән килүче кунаклары булгалый бит аның. Чын Кырым шәрабын татып күрсеннәр, — дип,

сатуга сирәк чыга торган, әллә ничәшәр еллык шәрабларның берәрсен биреп җибәрә иде.

Беркөнне Кавинең Набережная урамына төшәргә җыенуын күреп, Галимҗан абый:

— Рәхмәтуллин янына да кереп чык әле син, Кави. Юл өсте ич. Бер-ике шешә виноград суы алып кайтырсың, — диде.

— Ярый. Була ул, Галимҗан абый! — дип, Кави чыгып китте.

Китте дә югалды бу. Ике-өч сәгатькә якын вакыт үтте. Һаман кайтмый да кайтмый. Без инде моңа ни булды икән, дип борчыла башладык. Галимҗан абый:

— Йөзә белә бит ул Кави?! — дигәч, куркынып киттем. «Диңгезгә коеныргя төшеп, суга батмадымы икән» дигән уй бер минем башыма гына килмәгән, Галимҗан абый белән икебезнең дә күңелгә бер үк тәшвиш төшкән икән. Инде көн кичкә таба авыша башлады. Берничә тапкыр урамга да чыгып карадым. Галимҗан абый да веранда тәрәзәсеннән күзен алмый. Шулай, без тәмам аптырашып, нишләргә белми торганда, ниһаять, тирләп-пешеп, Кави кайтып керде бер заман! Ләкин кыяфәтенә әдәм карарлык түгел. Өстендәге ак кителенең иңбашлары, бигрәк тә күкрәк турысы, ермач-ермач булып пычранган.

Аны күрүгә:

— Сиңа ни булды? — дип, икебез берьюлы кычкырып җибәрдек.

Кави, туктагыз, сулу алырга ирек бирегез дигән сыман, бер-ике минут дәшми утырганнан соң, портфеленнән ике шешә виноград суы чыгарып өстәлгә утыртты.

— Менә булды, Галимҗан абый! Тик бу юлы шактый кыйбатка төште бу шифалы су! — дип, көлемсерәп куйды.

Һәм шуннан соң инде, үзенең нинди хәлгә тарыган булуын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Рәхмәтуллинны кибетендә туры китерә алмагач, Кави, өенә ашарга киткәндер ул, мөгаен, дип, аның квартирына барган икән (Магазиннан ерак түгел иде аның торган җире.). Анда ишек шар ачык булгач, Кави, «керүеңнән элек чыгуыңны уйла» дигән сүзне онытып, аны-моны уйламый, өйгә керә. Караса, беркем дә юк. Хуҗалар ишек алдындадыр, ахрысы, хәзер керерләр дип, биш-ун минут көтеп утырып та карый. Аннан инде, бер дә кергән-чыккан кеше булмагач, китәргә булып, ишек янына баруга, әллә каян бозау чаклы овчарка килеп чыга да, үрә баскан хәлдә «һав!» дип, алгы аякларын Кавинең иңбашына терәп, аны артка чигендерә. Бу көтелмәгән хәлдән Кавинең коты алына, билгеле. Ләкин нишләмәк кирәк? Ул, диванга утырып, төрлечә план корырга тотына. Сикереп төшеп булмасмы дип, тәрәзә янына да барып карый. Ләкин ул утырып торганда, йокымсырагандай булып, тыныч кына идән уртасында сузылып яткан эт, Кави кузгалып, янындагы портфеленә кулын сузуга, бер күзен генә ачып карый да, ди, ул урыныннан торды исә, дәррәү, зобанойдай булып, каршысына килеп баса икән. Кави бер торып, бер утыра. Утыра торгач диванда бераз черем итеп тә ала. Чарасыздан хуҗаларның берәрсе кайтканны көтәргә мәҗбүр була.

Бу мажараны, мин шул вакытта безгә Кави үзе сөйләгән төсле, оста тасвир итә алмыйм, билгеле. Ул аны, бөтенесен аермачык күз алдына китерерлек, җанлы итеп һәм үзенә хас юмор белән сөйләде. Ул сөйли, без тыела алмый көләбез. Бер-ике тапкыр Галимҗан абый да:

— Тукта, Кави! Көлдереп үтерәсең бит инде! — дип куйды хәтта.

Кави исә, Рәхмәтуллин өендә шулай «әсир» булып утырганда башыннан кичкән хәлне сөйләп бетергәннән соң:

— Кителем китель генә түгел иде! Кардан ак, сөттән пакъ иде. Харап итте, каһәр! Күрегез инде моны! — дип, урындык артына элгән кителен, кулына алып, җәеп күрсәтте.

Шуннан соң, Рәхмәтуллинны телгә алган саен, Кави белән булган шул мажараны искә төшереп, тагын бер рәхәтләнеп көлә торган идек. Һәм без виноград суына барырга җыенган саен, Галимҗан абый:

— Озак йөрмәгез. Теге зобаный янына кермәгез тагы! — дип, көлеп озатып кала иде.

(Байтак еллардан соң, Бөек Ватан сугышы вакытында, Казанда очраштык әле без иптәш Рәхмәтуллин белән. Кырымга немец гаскәрләре керер алдыннан, хөкүмәт

кушуы буенча, Массандра подвалларындагы аеруча кадерле, кыйбатлы шәрабларны үзләренең ничек итеп самолетларда тылга озатуларын һәм калган өлешен диңгезгә түгүләрен сөйләде ул безгә. Казаннан Бөгелмәгә киткән иде, хәзер кайдадыр, исәнмедер — белмим.)

* * *

Кичен, йөрергә чыкмаган көннәрдә, Галимҗан абый верандада ял итеп, гәпләшеп утырырга ярата. Ара-тирә аның хәлен белергә килүче иптәшләр дә була шунда. Кеше булмаганда өчебез генә сөйләшеп утыра торган идек.

Кичке эңгер-меңгер чак. Веранданың ачык тәрәзәләреннән диңгез сулышы керә. Төрле-төрле хуш исләр бөркелә. Магнолияләр, розалар чәчәк аткан. Күңелгә рәхәт тә, шул ук вакытта бераз ямансу да. Чөнки безнең, Галимҗан абыйдан аерылып, Казанга кайтып китәр көннәр дә якынлашып килә иде инде. Шундый кичләрнең берсе хәтердә аеруча яхшы сакланган. Бер тапкыр шулай, җай гына гәпләшеп утырганда, Галимҗан абый ничектер Троицкий, кайчандыр мин укыган Дарелмогаллимәт турында, аның кайбер укытучылары турында сүз башланды. Безнең уртак танышлар байтак булып чыкты. Шәехзадә Бабичның Троицкида яшәгән чагы белән дә кызыксынып сораштырды ул.

Шунда Кави дә сүзгә кушылып:

— Мәҗит ага Гафури да байтак торган ул Троицкида. Берничә көн генә булса да Тукай да булган анда. Дәрдемәнд, Бабич... Менә шулар турында «Дүрт шагыйрьнең Троицк чоры» дипме, ничек тә бернәрсә язарга кулым кычытып йөри әле, Галимҗан абый. Сез ничек карыйсыз моңа? — дип сораган иде.

Галимҗан абый:

— Гомумән, кызык идея бу үзе. Ләкин сиңа, күңеленне чуарлатмый, беренче чиратта «Гарнизон»ны очлап чыгарга кирәк. Башка нәрсәләр белән мавыкмый тор хәзергә. Ул «Дүрт шагыйрь...»гә дә өлгерерсең әле. Исәнлек кенә кирәк, — диде дә, тирән көрсенеп куйды.

* * *

Шулай көн артыннан көн туып, бер ай вакытның үткәне сизелми дә калды. Без, Казанга кайтырга җыенып, извозчикка утырып чыгып киткәндә, Галимҗан абый:

— Хәерле юл, туганнар! Тагын килегез. Казанга, андагы иптәшләргә сәлам әйтерсез. Кайтып җиткәч тә, хат язып салырга онытмагыз! — дип, капка төбендә моңаеп озатып калды. Аның бу кыяфәте әле бүген дә күз алдымда.

Озак вакыт бергә булу безнең араны тагы да якынайткан иде. Галимҗан абыйны ялгыз калдырып китү күңелгә авыр, ямансу булды. Һәм озакламый Ялтага абыйсы килгәнен белгәч, без дә шатландык. («Миндә хәзер абый кунак булып ята. Ай булачак», дип язган иде ул, югарыда телгә алынган хатында.)

Аннан соң, Кави белән 1933 ел башында тагын Ялтада булдык. Бу баруда да шактый озак тордык. Ләкин Галимҗан абыйның кәефе, элекке елдагыга караганда, начарлана төшкән иде һәм, хәтерем ялгышмаса, без баргач та санаториягә керде бугай ул. Шуңа күрәдер, бәлки, ул көннәр турында әллә ни телгә алып сөйләрлек истәлекләр калмаган. Хәер, ул вакыт мин үзем дә авырый идем. Ялтага барганнан кайтканчы врачларга һәм төрле процедураларга йөрүдән бушамадым диярлек.

Галимҗан абыйны, шул 1933 елны күргәннән соң, яңадан күрү насыйп булмады миңа. Олы йөрәкле чын кеше иде Галимҗан абый! Һәм аның турында хәтердә бары тик якты истәлекләр генә сакланган.

●

# Китап күзәтү

## КИРӘКЛЕ ҺӘМ ФАЙДАЛЫ КИТАП

Татарстан язучыларының VI нчы съезды ачылган бинада съезд истәлеге итеп китаплар сайлаганда, күзем «Ике тел хәзинәсе»[1] исемле китапка төште. Китапны кулыма алып, гадәтем буенча, элек эчтәлеге белән таныштым, аннары кайбер битләренә күз йөртеп чыктым. Шушы кыска гына арада китапта әдәби тел мәсьәләләре һәм тәрҗемә эше буенча шактый әйбәт фикерләр әйтелгәнлеге күренде. Бу мине магнит кебек үзенә тартты. Китапны алып кайттым һәм зур дикъкать белән укып та чыктым. Китап чыннан да укучының күнелен биләрлек итеп язылган.

Бу хезмәтнең шундый көчкә ия булуы нәрсәдә соң?

Минемчә, моның сәбәбе, беренчедән, авторның китапта яктыртылган мәсьәләләрне теоретик һәм практик яктан гаять тирән һәм этрафлы бәлүендә; икенчедән, әсәрдә кузгатылган һәр мәсьәлә турында әйтелгән фикерләрнең кыска, ачык, тәмам ышандырырлык итеп, логик эзлеклелек белән бәян ителүендә һәм дәлилләнүендә; өченчедән, татар теленә тәрҗемә итү өлкәсендә ирешелгән уңышларны һәм кимчелекләрне, тәрҗемә принципларыннан һәм әдәби телебезнең үзенчәлекләреннән чыгып, объектив билгеләвендә, кимчелекләрне киләчәктә төзәтү өчен файдалы тәкъдимнәр ясавында, киңәшләр бирүендә. Менә шул яклары белән бу хезмәт укучыны ышандыра һәм ихтыярсыз үзенә буйсындыра. Минемчә, китапны укучылар да бу бәя белән килешерләр.

«Ике тел хәзинәсе» тәрҗемә итү эшенә гомереңнең 45 елдан артык өлешен биргән (ул тәрҗемә эшен 1918 елдан башлаган), бу өлкәдә бай тәҗрибә һәм материал туплаган һәм аны гыйльми эшкәрткән, марксизм-ленинизм әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү буенча алгы сафта торып армый-талмый эшләгән, коры тәрҗемәче булып кына түгел, бәлки тәрҗемә кадрлары әзерләү юлында зур эш башкарган Сәгыйт иптәш Фәйзуллин тарафыннан язылган.

Китап алты бүлектән тора: 1) Әдәби телебезнең үсеше юлына карата; 2) Ике тел ачкычы; 3) Сүз һәм аның мәгънә күләме турында; 4) Алынмалар турында; 5) Тезмәҗөмлә — контекст; 6) Дөрес булсын, матур булсын. Аннан соң Г. Ахунҗанов тарафыннан язылган «Мәкальләр тәрҗемәсе турында» исемле мәкалә бирелгән.

Бүлек исемнәреннән дә күренгәнчә, китап башлыча көндәлек хезмәтләрендә ике тел белән эш итүче профессиональ тәрҗемәчеләр өчен язылган. Бу хезмәт гомумән тәрҗемәчеләр, матбугат работниклары, тәрҗемә эшенә әзерләнүче яшьләр өчен билгеле дәрәҗәдә кулланма булачак. Алар бу китапта көндәлек эш процессында очрый торган кыенлыкларны чишү, эшләрендә дөрес юл алу өчен кирәкле материал, кыйммәтле күрсәтүләр таба алачаклар. Алай гына түгел, «Ике тел хә-

[1] С. Фәйзуллин. Ике тел хәзинәсе. Казан, 1964 ел.

зинәсе» хәтта телчеләр, тел укытучылары өчен дә файдалы чыганак булачак дип әйтәсе килә.

Китапның кереш өлешендә автор тәрҗемә эшенең әһәмиятенә тукталган. Өстән караганда, тәрҗемә эшенең әһәмияте һәркем өчен ачык һәм билгеле шикелле. Ләкин аның әһәмиятен төрлечә һәм төрле күләмдә аңларга мөмкин. Әнә шушы яктан караганда, авторның бу мәсьәләгә карашы киңлеге һәм тулылыгы белән игътибарны үзенә тарта. Шуңа күрә бу турыда китаптан кечкенә генә бер өземтә бирү һич тә артык булмастыр дип уйлыйм. «Әгәр әдәби тәрҗемәләр булмаса, без үз илебездәге һәм чит илләрдәге төрле халыкларның әдәбияты һәм сәнгате, фәне-техникасы һәм, гомумән, тормышы белән ничек таныша алыр идек? Үзләре дә, телләре дә югалган борынгы халыкларның рухи иҗат хәзинәләрен ничек белә алыр идек? Кешелек белеменең иң беренче баскычларыннан хәзерге югарылыкка үсүен җанлы күренеш итеп ничек күз алдына китерә алыр идек? Тәрҗемә безне шул бөек мирас белән дә, хәзерге заманның искиткеч казанышлары белән дә таныштыра. Шулай итеп, һәр халыкның рухи дөньясын киңәйтә, башка халыкларны ихтирам итәргә, дус күрергә өйрәтә. Татар укучысы Ленинның бөек тәгълиматын, Ленин партиясенең тирән акылын тәрҗемә аша үзләштерә, рус һәм башка халыкларның фән һәм иҗат казанышларын тәрҗемә аша үзенә кабул итә» (6 бит).

Бу турыда сүз алып барганда, автор тәрҗемә эшенең әдәби телебезне лексик, стилистик яклардан үстерүгә ярдәм итүен фактлар нигезендә күрсәтә.

Китапның алдагы бүлекләрендә тәрҗемәчеләр, вакытлы матбугат работниклары өчен гаять әһәмиятле мәсьәләләр яктыртыла. Анда әдәби телебезнең үсешендә, тәрҗемә эшенең барышында ирешелгән зур казанышлар һәм ул өлкәдәге кимчелекләр, бигрәк тә шәхес культы елларында тәрҗемә практикасының, әдәби тел нормаларыннан читкә китеп, сүзгә сүз яки механик тәрҗемә юлына басуы, шуның аркасында әллә нинди ясалма «тәрҗемә теле» барлыкка килүе турында гаять кызыклы фикерләр әйтелә. Бу бүлекләрдә сүз һәм аның мәгънә күләме, алынмалар мәсьәләсе буенча да тел өстендә һәм тәрҗемә өлкәсендә эшләүчеләр өчен гаять кыйммәтле фикерләр бар. Кыскасы, китапның эчтәлегенә салынган төп мәсьәләләргә карата әйтелгән фикер һәм карашлар тәрҗемә эшләре буенча якын киләчәктә язылырга һәм матбугат мәйданына чыгарылырга тиешле кулланма яки кагыйдәләр китабының нигезенә салынырлык принципиаль фикерләр булып яңгырыйлар. Без ышанабыз ки, Татарстан китап нәшрияты якын киләчәктә китапның авторы Сәгыйт иптәш Фәйзуллин җитәкчелегендә бер группа оештырып, әнә шушы «Ике тел хәзинәсе» нигезендә гомумән тәрҗемәчеләр һәм тәрҗемә эшенә мөстәкыйль рәвештә яки махсус курслар аркылы әзерләнүче яшьләр өчен бер кулланма төзү эшенә керешер, шулай итеп, бу өлкәдәге зур бушлыкны каплар. Мондый бер китапның булмавы, ә булырга тиешлеге турында автор үзе дә бу хезмәтендә берничә урында телгә ала һәм бу кимчелекнең яшәвендә нәшриятны гаепли. Ул болай ди:

«Бу нәрсә... бездә тел һәм тәрҗемә мәсьәләләренә игътибар җитәрлек булмаудан килә. Телчеләребезнең гыйльми эшләре күбесенчә көндәлек әдәбият һәм матбугат практикасыннан шактый ерак тора әле. Тәрҗемәнең принциплары ничек булырга тиешлеге бөтен тирәнлеге белән тикшерелмәгән. Һәр елны йөзләрчә тәрҗемә китап чыгаручы нәшриятның тәрҗемә турында әлегә чаклы бер генә китап та биргәне юк. Ә практикларга килгән чагында, бу эшкә гыйльми күзәтү һәм җәмәгать контроле җитәрлек булмагач, төрле буталчыклыкка киң мәйдан кала. Һәр эштәге шикелле, биредә дә үзләренең кимчелекләрен «принципиаль» нигезләр белән акларга тырышучылар табылып тора» (9 бит).

Авторның бу зарлануы гаять урынлы. Тик Тел, әдәбият һәм тарих институтының телгә алынмавы гына аңлашылып бетми. Билгеле

булганча, әдәби телебезнең үсеше һәм әдәби телнең үсешенә бик тыгыз бәйләнгән тәрҗемә эшенең барышы һәм торышы бик күп яклары белән шушы институтның эшчәнлегенә бәйләнгән. Шунлыктан тәрҗемә эшләре буенча хәзергәчә бер кулланма да булмау өчен җаваплылык, Татарстан китап нәшрияты белән беррәттән, институт өстенә дә төшсә кирәк.

Китапта автор әдәби телебезнең терминологиясе мәсьәләләренә дә туктала һәм бу өлкәдә күп кенә уңышлы эшләр эшләнгәнлекне канәгатьләнү белән билгеләп үтә. Шуның белән бергә бу мөһим өлкәдә кимчелек һәм чуарлыкларның да аз булмавын күрсәтә. Матбугатта икенче телләрдән кергән кайбер сүз һәм терминнарның төрлечә кулланылуын тәнкыйтьли. Мәсәлән, дәреслекләрдә **Һиндстан, Мисыр** дип, ә газеталарда, русчалатып, **Индия** һәм **Египет** дип язалар. Бу — әдәби тел дисциплинасын какшата, ди. Бу чуарлыктан котылу өчен автор акыллы чара да күрсәтә: газета һәм дәреслекләр арасында мондый аерма булганда, дәреслеккә өстенлек бирелергә тиешлеген, моның формаль яктан да, методологик яктан да дөрес, практик яктан уңайлы булачагын әйтә һәм бу тәкъдимен дәреслекләрнең мәгариф министрлыгы тарафыннан расланулары белән дәлилли. Безнеңчә, авторның мәсьәләне болай куюы, һичшиксез, игътибарга лаек.

Китапта вакытлы матбугат теле турында да кискен фикерләр әйтелә. Газеталарның теле шактый авыр, кытыршы һәм коры булу өстенә, анда алынма сүзләр кирәгеннән артык еш кулланыла, шулар арасында халыкка авыр аңлаешлы яки бөтенләй аңлаешсыз ялтыравыклы сүзләр һәм тәгъбирләр, мәсәлән, **кичерешләр палитрасы, көрәш патетикасы, мәхәббәт линиясе** кебек тезмәләр еш очрый, ди автор (14 бит).

Вакытлы матбугат телендәге мондый кытыршылыклар турында газета битләрендә язылгаласа да, аларның һаман кабатланып торуларын, редакцияләрнең тәнкыйтькә игътибар биреп җиткермәүләрен әйтә.

Шул ук 14 нче биттә публицистика теленә карата да күп кенә дөрес күрсәтүләр бар. Автор бу өлкәдәге уңышларны дөрес күрә. Ләкин шуның белән бергә, анда сугышчан публицистика жанры телен үтмәсләндерә, аны чуплəндерә торган фактларның еш кына күзгә ташлануын, бу мәйданны андый чүпләрдән арындырырга бик күптән вакыт житкәнлеген ачыктан-ачык әйтә.

Автор, гомумән матбугат, аеруча публицистика телләрендә булган кимчелекләрне тудырган сәбәпләрнең берсе һәм иң зурысы итеп үз вакытында махсус рәвештә матбугат, тәрҗемә кадрлары әзерләү чаралары күрелмәүне, шуның аркасында бу эшкә, еш кына, кем очраса шуны тарту юлы тотылганлыгын күрсәтеп, болай ди:

«Тәҗрибәнең әле аз булуы, тәрҗемә теориясе мәсьәләләренә әһәмият бирелмәү, бу эштә җәмәгать контроле җитмәү аркасында тәрҗемә өлкәсендә уңышсызлыклар шактый булгалады. Болар арасында иң зурысы — сүзгә сүз тәрҗемә бәласе. Яңа гына эшкә керешкән тәрҗемәче өчен бу әле бердәнбер юл булса, тәҗрибәле тәрҗемәчеләрнең байтагысы өчен бу иң тиз, иң ансат юл булды. Әгәр срогы да ашыгыч булса, гонорар да мул «тамса», нигә баш ватып торырга — тотарга да сүзнең беренче булып уйга килгән мәгънәсен язарга яки сүзлектә әйтелгән берничә мәгънәсе арасыннан беренче туры килгәнен алып куярга» (15 бит).

63 нче биттә: «Бездә үзара сөйләшкәндә генә түгел, газета һәм китап битләрендә дә тел сафлыгына тиешле игътибар бирелеп җитми»,— дигән җөмлә бар. Бик урынлы әйтелгән. «Ике тел хәзинәсе» авторы тел сафлыгы турында сөйләгәндә марксизм классиклары карашларыннан чыгып эш итә. Марксизм классиклары киң катлау укучыларга төбәлгән әсәрләрендә чит сүзләр белән бик сак эш итәләр, аларны иң зарур булганда гына кулланалар, матбугатта чит сүзләрне күп

кулланугa каршы сугыш игълан итәләр, ди.

Автор, әдәби тел мәсьәләләрендә тар милли чикләнгәнлеккә принципиаль каршы булганы, кирәк булганда икенче телләрдән сүзләр, хәтта тәгъбирләр алуны яклаганы хәлдә, гомумән тел белән эш иткәндә, аеруча тәрҗемә эшендә, милли әдәби телнең үз байлыгыннан, аның үз мөмкинлекләреннән һәм нечкә үзенчәлекләреннән киң файдалану тиешлеген хезмәтнең башыннан ахырынача хаклы рәвештә яклый. Мәсәлән, телебездә халыкка бик аңлаешлы булган **буа** сүзе урынына **плотина** сүзен; **югары** сүзе урынына **верховный** сүзен; **музыка кораллары, террор акты, оппортунистларча лыгырдау, симпатияле тон, сарказм төсмере, иронияле мөнәсәбәт** формасындагы тезмәләр урынына **музыкаль инструментлар, террористик акт, оппортунистик лыгырдау, симпатик тон, саркастик төсмер, иронистик мөнәсәбәт...** шикелле формалар алуны уңышсыз күренеш, формализм белән мавыгу яки морфологик фетишизм дип бәяли. Алынма сүз һәм формаларны куллануда эзлеклелек сакланмавын каты гаепли. Тәрҗемә эшендәге әнә шундый тискәре күренешләр турындагы сүзләрен автор болай дип тәмамлый: «Гомумән, морфологик фетишизмга бирелмичә, тел чараларын һәр конкрет очракта дөрес кулланарга кирәк... Сүзгә сүз тәрҗемә безнең бер зур кимчелек булса, морфологик фетишизм тагын да зуррак кимчелек. Чөнки иң матур, иң дөрес сүзләрне дә, кушымчаларын дөрес сайламаганда, күңел биздергеч формага кертеп була. Күп хәлләрдә бу — мәгънәгә дә зыян китерә» (59—60 битләр).

Автор телебездәге кушымчаларны икенче телләрнең грамматикалары тәэсиренә бирелеп куллануны уңышсыз алым, әдәби телебезнең матурлыгын, аның үзенчәлекләрен җимерә торган күренеш дип бәяли. Вакытлы матбугат битләрендә еш очрый торган **тегү фабрикасы кызлары хоры, Мөслим совхозы партоешмасы секретаре** шикелле тезмәләрне, татар теленә туры килә торган итеп, **тегү фабрикасының кызлар хоры, Мөслим совхозының партком секретаре** формасында куллануны матуррак та, дөресрәк тә, ди. **Гарәп көнчыгышы, крестьян хәрәкәте, партизан сугышы** тибындагы тезмәләрне **гарәпләр көнчыгышы, крестьяннар хәрәкәте, партизаннар сугышы** формасында йөртүне дә автор уңышсыз үрнәкләр дип атый, мондый формаларның матур әдәбиятта да күренүе аеруча кызганыч икәнен әйтә (30 бит).

Тәрҗемә телендә әнә шундый уңышсыз үрнәкләр, татар әдәби теленең үз нормаларына туры килми торган кытыршы формалар булмасын өчен, автор тәрҗемәчеләр алдына телләрне белү мәсьәләсе буенча зур һәм гадел таләпләр куя. Тәрҗемәче оригинал телен дә, тәрҗемә телен дә нык үзләштергән булырга, оригиналдагы сүз һәм формаларга тәрҗемәдә нинди сүзләр һәм формалар туры килгәнлеген тирән аңларга тиеш, ди һәм моңа ике телнең дә лексик, грамматик һәм стилистик нормаларын яхшы белгәндә генә ирешеп булганлыгын ышандырырлык мисаллар өстендә аңлата. Шуңа бәйле рәвештә, тәрҗемәченең сүзлек белән генә тәрҗемә итү юлын да тәнкыйтьли. Бу юл тәрҗемә эшен механик процесска әйләндерә, ә тәрҗемә эше — ул иҗади эш, шуңа күрә телләрне яхшы белүче тәрҗемәчеләр сүзлеккә сирәк мөрәҗәгать итәләр, ди. Бу турыда В. Ганиевнең «Совет әдәбияты»ның 1963 нче елгы 12 нче санында «Тәрҗемәдә төгәллек һәм нәфислек» исеме астында басылган мәкаләсен искә төшерү урынлы булыр. Ул мәкаләдә Г. Тукай поэзиясен рус теленә тәрҗемә итүчеләрнең оригинал телен җитәрлек белмәүләре, күбесенчә подстрочник яки сүзлек ярдәмендә эшләүләре аркасында тәрҗемәнең һич тә канәгатьләнерлек булып чыкмавы көчле дәлилләр белән исбатлана.

Фикер һәм фактларга бай булган бу китапның эчтәлеген кыска газета яки журнал мәкаләсендә бөтен киңлегендә ачып бирү мөмкин түгел. Моның кирәге дә юктыр. Андагы фикер һәм фактлар байлыгы

белән тулы танышу тик әсәрнең үзен уку яки өйрәнү аркылы гына мөмкин. Шуңа күрә без китапның эчтәлегенә караган кайбер фикерләребезне югарыда әйтелгәннәр белән чикләргә булдык.

Югарыда әйтелгәнчә, китап бездә, гомумән, уңай тәэсир калдырды. Анда без төп мәсьәләләр буенча зур кимчелекләр күрә алмадык. Шулай да кайбер мәсьәләләрдә автор белән килешеп бетмәгән моментлар бар. Хәзер шулар турында берничә генә сүз әйтәсе кала.

Беренчедән, авторның газета теле турында: «Ләкин газеталарның теле шактый авыр, кытыршы һәм коры булып чыга», — дигән сүзләрен өлешчә генә кабул итәргә мөмкин. Автор, ихтимал, бу карашын газета теленең үткән этапларына карабрак әйткән булыр. Соңгы елларда бу өлкәдәге алга китешне инкарь итеп булмастыр. Ләкин бу, билгеле, газета телендә җитешсезлекләр бөтенләй юк яки бик аз дигән сүз түгел. Алар, әлбәттә, бар.

Икенчедән, китапның 57 нче битендә, алынмалар мәсьәләсенә бәйләп, грамматик род турында сүз кузгатыла. Автор татар телендә аның булмавын кискен рәвештә раслап үтсә дә, сүз барышында рус теленнән кергән женский родтагы кайбер исемнәр алдында килгән сыйфатларны исем белән родта яраштыру фикерен алга сөрә. Моңа мисал итеп **массовый партия, массовый кампания** тезмәләре алына һәм аларның бу формада кулланылуларын автор килешсез саный; ә менә **генеральный линия** тезмәсендә инде ярашу ипсез тоела, ди. Димәк, авторча **массовая партия, массовая кампания** формалары килешле яңгырый, ә **генеральная линия** формасы исә килешсез яңгырый булып чыга.

Югарыда китерелгән өч тезмәнең икесенең «килешле яңгыравын», ә соңгысының «ипсез тоелуын» билгеләгәндә автор нинди критерийдан чыгып эш итә соң? Монысы укучыга һич тә аңлашылмый. Мәсьәләнең эченә тирәнрәк кереп карасаң, монда бит сүз ике-өч тезмә турында түгел, бәлки татар теленә грамматик род категориясе кертү турында бара. Мондый җитди бер мәсьәлә турында сүз алып барганда «килешле яңгырый», «ипсез тоела» шикелле саф субъектив карашлардан чыгып кына эш итү килешеп бетәрме икән? Чөнки берәүләргә тезмәләрнең родта ярашкан формасы, ә икенчеләргә ярашмаган формасы «матур яңгырый» булып күренергә мөмкин. Билгеле нормаларга ия булган мөстәкыйль бер телгә аның грамматик төзелешенә бөтенләй туры килмәгән род категориясен өстерәп кертү аның үзенә хас булган закончалыклар нигезендә яшәвенә орыну булмыймы? Безнеңчә, югарыда китерелгән өч тезмәне моңарчы кулланылып килгән **массовый партия, массовый кампания, генеральный линия** формаларында куллану телнең үзенчәлегенә нәкъ туры килә һәм начар яңгырамый. Аннары аларны **масса партиясе, масса кампаниясе, генераль линия** формаларында куллану да телебез өчен бер дә чит булмаячак, һәм мәгънә дә бозылмый шикелле. Автор үзе дә китабының бик күп урыннарында мондый формадагы бәйләнешне яратып алга сөрә.

Өченчедән, «Алынмалар...» бүлегендә автор, А. М. Горькийның: «Алынма сүз алучы телнең фонетик калыбына якынрак торса, ансатрак үзләшә», — дигән сүзләрен китерә дә, аңа үзеннән: «Бездә сүзләргә күп кушымчалар ялганганга күрә, кыскарак сүзләрне алынма итеп үзләштерү җайлырак чыга, шуның белән бергә биредә сүзләрдә басымның соңгы иҗектә булуы кебек бер үзенчәлек белән дә хисаплашырга туры килә», — дигән сүзләрен өстәп, Горький фикерен хуплый (56 бит). Горький сүзләре дә, автор өстәмәсе дә, безнеңчә, каршылыкка очрарлык нәрсәләр түгел. Боларны телебезгә икенче теллэрдән сүзләр алганда истә тоту зарарлы булмастыр. Ләкин авторның шул ук 56 нчы биттә: «Соңгырак заманнарда бездә, рус теле мәктәпләрдә һәм тормышта киң урын алгач, русчадан кергән яңа алынмалар күбесенчә русча формаларында үзләшәләр», — дигән сүзләре сәеррәк тоела. Берен-

чедән, тормышта башланып кына киткән бер күренешкә таянып, халыкның бер өлешенең алынма сүзләрне ул халыкның үз телендәгечә әйтә алуларына карап кына, мөстәкыйль яшәештә булган телнең фонетик һәм морфологик нормаларын исәпкә алмыйча, аның сингармонизм һәм басым системасы үзенчәлекләре белән санашмыйча, ул сүзләрне алучы телнең лексик составына шул килеш алу — әдәби телнең мөстәкыйльлеген, аның йөзләрчә еллар буена дәвам итеп килгән яшәү законын бозу яки җимерү булмыймы? Югарыда китерелгән мотивлар гына бөтен телләр өчен уртак булган тел законын юк итү өчен нигез була алалармы? Икенчедән, башка теллардән, шул җөмләдән рус теленнән, алынган сүзләрне алучы телнең фонетик-морфологик нормалары таләпләренә зарур күләмдә буйсындырмыйча, аның аһәңенә килешмәгән яңгырашта алырга көчәнүнең нинди әһәмияте бар, һәм ул нәрсәгә кирәк? Алынманы алучы тел үзенчәлекләренә зарур күләмдә буйсындырып алу барлык очракларда да алынманың морфологик структурасына һәм мәгънә ягына аз гына да зыян китерми ләбаса. Мәсәлән, **кирпич, кукуруза, минута...** сүзләре телебездә **кирпеч, кукуруз, минут...** формасында үзләшкәннәр икән, моның мәгънә күләменә аз гына да тәэсире юк бит. Шулай булгач, хәзерге шартларда бу турыда артык киңәеп китү табигый юл белән үсеп бара торган әдәби телнең законлы юнәлешенә киртә генә булыр иде. Аннары, икенче телләрдән сүзләр алу безнең телебезгә генә хас нәрсә түгел. Һәрбер тел — рус теле дә, немец теле дә, шулай ук башка бик күп телләр дә икенче телләрдән сүзләр алалар, чөнки моны телләрнең үсеш законы таләп итә. Ләкин аларның һәркайсы алынма сүзләрне үз таләпләренә зарур үлчәүдә буйсындырып ала. Бу хәл тел белемендә дә бер хакыйкать яки гомуми бер факт булып танылган. Билгеле, моны һәрбер алынма сүзгә карата мәҗбүри төстә кую дөрес булмас иде.

Алынмалар һәм алар белән эш итү турында күп кенә яхшы фикерләр әйткән автор, ни өчендер, бу мәсьәлә буенча кискен һәм ачык бер фикер әйтеп үтүне кирәксенмәгән, урынсыз саранлык яки саклык күрсәткән. Ә тел үсеше, алынмалар турында сөйләгән китапта алынмаларны алучы тел үзенчәлекләренә буйсындыруның кирәк яки кирәк түгеллеген, кирәк булганда, ни дәрәҗәдә кирәклеге турында хәзерге тел белеме куелышыннан чыгып кискен бер караш әйтеп китү һәм урынлы, һәм файдалы булган булыр иде диясе килә.

Сүз ахырында бер генә тәкъдим: китапта «Ике тел ачкычы» исемле бүлек бар. Монда, татар теленә тәрҗемә итү эшенең кайчан башланып китүе турында беркадәр тарихи материал бирелгән. Бик әйбәт. Ләкин бу мәсьәләгә махсус бүлек биреп аны киңрәк яктыртырга иде. Бездә Бөек Октябрь революциясенә чаклы ук рус теленнән тыш, гарәп һәм башка көнчыгыш халыклары телләреннән татар теленә тәрҗемәләр бар иде. Алар дини китаплар тәрҗемәсе түгел. Мәсәлән, гарәп теленнән «Кәлилә вә Димнә» исемле әдәби китап тәрҗемә ителгән. Тәрҗемәчесе — Габделгалләм Фәезханов. Һинд шагыйре Рабиндранат Тагор шигырьләренең татарчага тәрҗемәсе дә бар (Г. Рәхим тәрҗемәсендә). Гарәп теленнән «Тәхрирелмәрьә» исемле китап тәрҗемәсенең барлыгы да мәгълүм. Соңгысы гарәп көнчыгышында хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләсенә багышланган. Аннары «Шура» журналы битләрендә турыдан-туры гарәп теленнән татар теленә тәрҗемә ителеп басылган мәкаләләр барлыгы да билгеле. Болар барысы да безнең тәрҗемә тарихыбызны баета торган материаллар булып торалар.

Татарстан китап нәшриятының «Ике тел хәзинәсе»н бастырып чыгаруы бик вакытлы һәм бик күңелле факт. Бу китап татар теленә тәрҗемә итү өстендә эшләүче кадрларның белем дәрәҗәсен күтәрүгә, шуның аркылы тәрҗемә эшенең сыйфатын яхшыртуга уңай этәреш ясар дип ышанырга кирәк.

*Ф. ХӘМИДУЛЛИН*

# ХАТЛАРДАН ЮЛЛАР...

*Журналыбызда Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» исемле яңа романының әле беренче бүлекләре генә басылган иде. Редакциягә һәм авторга илебезнең барлык почмакларыннан хатлар килә башлады: Урта Азиядән һәм Кавказдан, Ерак Көнчыгыштан һәм Уралдан, Мәскәүдән һәм Курган өлкәсеннән...*

*Кемнәр, нинди генә профессия кешеләре юк алар арасында?! Мәктәп балалары һәм студентлар, эшчеләр һәм колхозчылар, солдатлар, врачлар... Арада, Ш. Мөхәммәдъяров кебек, Г. Тукай, Ф. Әмирханнарны якыннан күреп белгән өлкәннәребез дә бар.*

*Роман басылып беткәннән соң, хатлар тагын да күбәйде. Ул хатларда «Ак чәчәкләр» турында бик күп җылы сүзләр язылган, аларда укучылар әсәрне укыганнан соң туган фикерләре, тәэсирләре белән уртаклашалар. Хатлар белән танышканнан соң, бер нәрсә ачыклана: матур әдәбият сөючеләр Габдрахман Әпсәләмовның бу яңа романын да яратып укыганнар.*

*Без, никадәр генә теләсәк тә, ул хатларның барысын да журналыбызда бастырып бетерә алмас идек, билгеле. Алар йөзләрчә, алар бик күп. «Казан утлары»ның бу санында әнә шул күп санлы хатлардан кайбер өзекләрне һәм аерым юлларны сайлап укучыларыбызга тәкъдим итәргә булдык.*

*Күп кенә иптәшләр бездән «Ак чәчәкләр» романындагы Гөлшаһидә җырының ноталарын җибәрүне сораганнар. Без аларны да шатландыра алабыз. Күптән түгел РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Җәүдәт Фәйзи Габдрахман Әпсәләмовның ул җырына көй язды. Журналыбызда композиторның яңа көен дә урнаштырабыз.*

...Спорт теле белән әйтсәк, мин «Казан утлары» журналының иң хәтәр болельщигы. Журналның һәр санын түземсезлек белән, зарыгып көтеп алам. «Казан утлары»ның 1965 елда чыккан саннары исә аеруча кадерле булды. Чөнки ул саннарда яраткан язучыбызның «Ак чәчәкләр» романы басылды. Белмим, тәнкыйтьчеләргә ничектер, әмма безгә Габдрахман Әпсәләмовның, башка әсәрләре шикелле үк, «Ак чәчәкләр»е дә бик-бик ошады.

З. Сәүбәнова.

Казан.

Сезнең барлык әсәрләрегезне дә яратып укып барам. Әмма берсе дә «Ак чәчәкләр» кадәр үк тәэсир итмәде, бугай. Романдагы кешеләрне — образларны бөтенесен дә йөрәгемнән кичереп укыдым. Кайбер урыннарын елый-елый укыдым. Әсәрдәге геройлар белән бергә шатландым, кайгырдым, яндым, көйдем. Тормыш! Әйе, аның юллары безнең заманда да шактый сикәлтәле шул әле. Кемгә дә бәхетне алдан әзерләп куймаганнар. Бәхет өчен көрәшергә кирәк. Мин журналда Р. Мостафинның Сезнең турыда язган мәкаләсен («Совет әдәбияты» журналы, 1964 ел, 11 сан) укып шаккаткан идем. Язу өстәле артыннан купмыйча, 10—14 сәгать эшли аласыз, дип яза ул Сезнең хакта. Шулай да, исәнлегегезне сакларга, яңадан ул каһәр төшкән чир белән авырмаска тырышыгыз инде. Сезнең яшәү халык өчен кирәк бит.

Т. Заманова.

Аксубай районы.

Мин «Искра» колхозында бозау тәрбияләүче булып эшлим. Буш вакытларда матур әдәбият китаплары укырга яратам. Шушы көннәрдә өлкән язучыбыз Габдрахман ага Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»ен укып чыктым. Роман миндә зур тәэсир калдырды. Анда кеше гомерен саклау өчен үз-үзләрен аямыйча эшләүче совет врачлары турында сөйләнелә.

Барлык укучыларга да бу әсәрне укырга тәкъдим итәм.

Х. Мозаффарова.
Әгерҗе районы.

Күп еллар буена больницаларда дәваланырга, врачлар, авырулар белән күп очрашырга туры килде миңа. Минем гомеремне саклап калу өчен дә врачлар зур көч куйдылар. Бу романда Габдрахман Әпсәләмов әнә шул хөрмәткә лаеклы әйбәт кешеләрнең образларын тудырган.

В. Минабетдинов.
Чистай районы.

1964 елда беренче мәртәбә Татарстанда булдым. Казаныбыз белән, Әлмәт белән таныштым, театрларда, музейларда йөрдем. Мин ул кадәрдер дип уйламаган идем: культурабызның, сәнгатебезнең дәрәҗәсе мине таң калдырды. Хәзер «Чаян», «Азат хатын», «Казан утлары» журналларын даими рәвештә укып барам. Журналның 1—5 саннарында басылган «Ак чәчәкләр» романы мине аеруча дулкынландырды. Халкыбызның Габдрахман Әпсәләмов кебек язучылары булуына горурланам мин.

Р. Иблаева.
Дүшәнбе.

Бүгенге көн темасына язылган бу роман миңа бик ошады, башкалар да яратыр дип уйлыйм. Профессор Әбүзәр Таһиров романның көзгесе дияр идем. Гөлшаһидәне дә, Мансурны да олы юлга чыгаручы кеше шул бит.

Ә. Мөлеков,
Башкортстан.

Әсәр эчтәлек ягыннан да бик кызыклы. Врачлар, больница шартларындагы кешеләр турында язылган әсәрләр күп түгел иде. Әбүзәр Таһиров — безгә таныш Әбүбәкер Терегуловтыр инде?. Зур хөрмәткә лаек кеше ул. Татарның элеккеге интеллигенциясенә караган әсәрләребез дә моңарчы юк иде. Алар турында язып, Габдрахман Әпсәләмов дөрес эшләгән.

Ш. Мөхәммәдъяров.
Ташкент.

«Ак чәчәкләр» романындагы Гөлшаһидә Сафина, Әбүзәр һәм Мансур Таһировлар кебек образлар хезмәт сөючән булулары, намуслы эшләре белән безне чиксез сокландырдылар. Алар белән без горурланабыз.

А. Гәрәева, Ф. Мухаметова,
С. Мингазова.
Туймазы.

Романдагы Әбүзәр Таһиров, Гөлшаһидә, Мансур, Асия, Юматша, Диләфрүз кебек образларга сокланмаска мөмкин түгел. Якын көннәрдә «Ак чәчәкләр» романы буенча укучылар конференциясе уздырабыз.

Ф. Корбанаев.
Башкортстан, Янаул районы.

«Ак чәчәкләр»егезне бик дулкынланып укыдым. Ифрат матур әсәр булган бу. Сезнең романыгызны укыгач, мин терелеп сәламәтләнеп киттем. Мең-мең рәхмәт Сезгә. Сез миңа яшәргә көч бирдегез.

Х. Мәхмүдова.
Казан.

«Ак чәчәкләр» романыгызны укыганнан соң туган хисләремне ничек аңлатырга да белмим. Сусаганда эчкән су кебек, йотлыгып укыдым мин аны.

Н. Краснова.
Чаллы районы.

Ышандырырлык, тормышчан итеп язылган әсәр — үзе бер дөнья. Ул яшәргә көч бирә, тормышка ямь өсти. Сезнең «Ак чәчәкләр» исемле яңа романыгыз да — әнә шундый әсәрләрнең берсе. Аны укыган саен укыйсы килә, андагы һәр вакыйга — үзенә бер тарих...

Хөрмәтле Габдрахман абый!

Әбүзәр абый, Габделкәрим кебек намуслы, халык өчен яшәгән кешеләребез, яхшы квартиралар күрмичә, үлеп тә киткәлиләр шул. Янгура кебек әшәке, мәкерле кешеләр бер яхшыдан икенчегә күчәргә тырышалар. Нинди кызганыч!

Тагын шуны әйтәсем килә: Гөлшаһидә белән бергә тора башлаганнан соң да, Мансур тоныкланып кала. Ничектер, бәхетле булуын, шатланганын күрмибез без аның. Китап итеп чыгарганда, бәлки, минем фикерне дә искә алырсыз.

Т. Гомәрова.
Балтач районы.

Тәрбияви образлар бирүегез өчен шатланабыз. Бүгенге чорыбызны чагылдырган әсәрләрегез безгә коммунизм төзүче совет кешеләрен тәрбияләүдә бик күп ярдәм итә. Без Сез иҗат иткән образларны әдәбият дәресләрендә файдаланабыз.

Юсупова, Каһирова, Акмалетдинов,
Сабиров, Солтанова, Борхаева.
Башкортстан, Янаул районы.

Менә ике көн инде палатада Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романын укыйбыз. Дөресрәге, мин укыйм, башка апалар тыңлый. Укып бетергәч, барыбыз да сүзсез генә үз уйларыбызга чумып утырдык. Соңыннан инде фикер алышулар башланды. Гөлшаһидә, Мансур, Юматша, Диләфрүз кебек образларны без бик яраттык. Тормышта Әбүзәр абый шикелле кешеләр күбрәк булсын иде! Янгура, Салахише врачларга һәм капризланырга яратучы авыруларга карата бездә ачу хисләре туды.

Без барыбыз да «Ак чәчәкләр» романының русчага тәрҗемә ителүен сорыйбыз. Русчасы чыгу белән үк, мин аны үзебезнең Җитен комбинаты врачларына бүләк итәр идем. Үзләре турында язылган әсәрне укысыннар иде.

Күпләгән авырулар исеменнән
А. Азизова.
Казан.

Романда Әбүзәр абый, Гөлшаһидә, Мансурлар искиткеч матур сыйфатлары белән бирелгәннәр. Гөлшаһидәнең яраткан кешесенә тормышка чыгуына мин чиксез шатландым. Тормышта бөтен хатын-кызлар да Гөлшаһидә кебек бәхетле булсыннар иде. Мин шуны телим...

Мансурның Гөлшаһидәне ратканлыгын күңел белән, йөрәк белән тоеп, сизеп торасың. Шулай да, язучы Мансурны тагын да ача төшсә, яхшы булыр иде.

З. Сабитова.
Зеленодольск районы.

Ни өчен Мансур хатын-кызга карата шулай салкын, игътибарсыз икән?..

Н. Корбанова.
Башкортстан.

Күп кенә уңай образлар белән бергә, романда Янгура, Салах кебек әшәке типлар да бар. Аларны күрсәтеп, язучы бик дөрес эшли. Кызганычка каршы, андый әшәке, ялагай врачлар байтак әле, бигрәк тә район больницаларында. 1960 елда, балам авырып киткәч, миңа больницада ятарга туры килде. Без бер палатада 13 кеше идек. Кысан иде, әлбәттә. Әмма моңа берәү дә зарланмады, түздек.

Шулай бер көнне больницага райком секретаре хатынын салдылар. Аның да баласы авырган икән. Карыйбыз, аңа бөтенләй башка караш, бөтенләй башка мөнәсәбәт. Аңа читен, тар булмасын дип, ул урнашкан палатадан авыруларны күчерергә тотындылар. Кайберләрен башка палаталарга, икенчеләрен исә, турыдан-туры, коридорга урнаштырдылар. Врачларның шулай ялагайлануларын күреп, безнең никадәр нәфрәтләнгәнебезне белсәгез иде!.. Аңа гына ошамый, аңа гына кысан, имеш.

Әсәр турында тагын бер искәрмәм бар. Романда укучыларга аңлашылмый торган сүзләр байтак. Сүз дәру исемнәре, медицина терминнары турында бармый, билгеле. Алардан башка да, мәгънәсен аңламаслык сүзләр очрый. Мин үзем, мәсәлән, сәхтиян, әгъләә, өрфия кебек сүзләрне, никадәр тырышсам да, аңлый алмадым...

М. Сөнгатуллина.
Татарстан.

Бүген, 22 майда, «Ак чәчәкләр» романын укып бетердем. Романыгызны үзебезнең врачларга да укырга тәкъдим итәргә уйлап торам әле. Укысыннар, белсеннәр, гыйбрәт алсыннар, дим. Чөнки безнең больница врачлары авыруларга игътибарсыз карыйлар, жанны әрнеткеч сүзләр әйтергә дә күп сорамыйлар. Шулай бер елны, кинәт авырып киттем дә, больницага барырга туры килде. Килсәм, эш сәгате бетеп килә икән. Врач, зарымны игътибарсыз гына тыңлап торды да, миңа туп-туры карап, тыныч кына тавыш белән:

— Нигә иртәнге яктарак чирләмәдең соң? Эш сәгате бетте бит инде,— диде.

Әгәр безнең больницада да Әбүзәр абый кебек врачлар күбрәк булса, бәлки, мин дә болай озак авырып йөрмәс идем, дип уйландым әле.

С. Җиһангирова.
Татарстан.

Ничек Сез, Габдрахман абый, Салах Саматовны һич тә көтмәгәндә әсәрдән төшереп калдырдыгыз? Мин үзем һәм иптәшләрем андый әшәке кеше тиешле җәзасын алыр дип көткән идек. Шулай ук профессор Янгураны да болай буш кына калдырмаска иде.

Солдатлар исеменнән
Ф. Гыйләҗев.

«Ак чәчәкләр» романында медицина терминнары һәр очракта да дөрес, татарча язылмаган. Әсәрдә «инфаркт миокардо» диелгән, аның татарчасы «миокарда инфаркты» буладыр инде? Анда шулай ук «кордиалин уколы ясады» дигән фраза бар. Бу — шулай ук хата. Беренчедән, «кордиалин» түгел, ә «кордиамин». Икенчедән, врачлар «укол» терминын кулланырга тиеш түгелләр, чөнки ул медицина сүзе түгел.

М. Шаммасов, врач.
Әгерҗе районы.

Романның геройлары белән бергә, миңа Гөлшаһидәнең «Акъярым» исемле җыры, ул җырның сүзләре дә бик ошады. Сагыш та, әрнү дә, өмет тә бар бу җырда. Аның көе дә, сүзләре кебек үк, әйбәттер тоела.

Кадерле редакция!

Мөмкин булса, журналның берәр санында бу җырның көен дә чыгаруыгызны үтенәм.

Ә. Фазлиәхмәтова.
Бәләбәй педучилищесы.

Без, Кызылбай сигезьеллык мәктәбе укытучылары, Сезнең «Ак чәчәкләр» исемле яңа романыгызны бик яратып укыдык. Тагын шундый яхшы романнар иҗат итегез, озак яшәгез!

Нуретдинова, Уразаева,
Ниязова, Ишмухаметова.
Курган өлкәсе.

# ЛЕОН НЕБЕНЦАЛЬ КАЗАНДА

Татарстан язучылары союзы чакыруы буенча Казанга немец язучысы һәм журналисты Леон Небенцаль килде. Аның исеме совет укучыларына күптән таныш.

1945 елдан алып Небенцаль немец һәм совет халыклары дуслыгын үстерү юлында эшли. Башта ул Совет хәрби администрациясендә хезмәт итә, Германия Демократик Республикасы оешкач, яшь хөкүмәтнең матбугат ведомствосына эшкә күчә, аның Советлар Союзы һәм халык демократиясе илләре бүлегенә җитәкчелек итә. Советлар Союзының яңа җәмгыять төзүдәге бай тәҗрибәсе белән немец халкын таныштыру максатын куеп, Леон Небенцаль «Советлар Союзы матбугаты» исемле журнал оештыра һәм сигез ел буе шул журналның редакторы була. Ул журнал Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнә. Бу — журналның максатына ирешүе турында сөйли торган матур факт.

1957 елдагы коммунистлар һәм эшчеләр партияләренең Мәскәү Киңәшмәсеннән соң, шул партияләрнең органы буларак, «Тынычлык һәм социализм проблемалары» журналы чыга башлый. Хәзер бу журнал 22 телдә чыга. Германиянең Социалистик Бердәм партиясе Үзәк Комитеты бу журналның немец телендә чыга торган басмаларына баш редактор итеп Леон Небенцальне билгели. Небенцаль хәзер дә шунда эшли.

Бик күп еллардан бирле Германия — Совет дуслыгы җәмгыятенең Үзәк правлениесе члены буларак, Леон Небенцаль немец һәм совет халыклары арасындагы дуслык багланышларын үстерүдә нәтиҗәле хезмәт күрсәтә. Рус теленнән немец теленә ул бик күп политик һәм әдәби әсәрләр тәрҗемә итә. Аның немецчага тәрҗемә иткән әсәрләре арасында В. Гроссманның «Степан Колчугин» романы, Нагишкинның «Бонивур йөрәге», Кремлевның «Революция солдатлары», Е. Дробкинаның «Кара сохарилар»ы, Авдеенконың «Кара чаңнар»ы һ. б. бар. Хәзер ул Майскийның «Совет дипломатының истәлекләреннән» дигән китабын тәрҗемә итә.

Леон Небенцаль Муса Җәлилнең немец фашистлары тылында алып барган көрәш тарихын ачыклауда да күп эшләде. Герой шагыйрьнең көрәш биографиясен өйрәнүдә, Муса белән очрашкан немец һ. б. көнбатыш халыклары вәкилләрен эзләп табуда ла гаять күп көч куеп эшләде һәм шул юлда эзләнү эшен дәвам итә. Муса Җәлил белән бер камерада утырган бельгияле Андре Тиммермансны, Шпандау төрмәсендә Муса һәм аның сугышчан көрәштәшләре белән бер камерада утырган һәм батырларны эшафотка озатып калган италияле Рениеро Ланфрединины эзләп табуда күп көч куя. Алар белән язышу материалларын Небенцаль Язучылар союзына тапшырды. Анда Тиммерманс һәм Ланфредининың үз куллары белән язган хатлары бар. Бу хатлар Муса, Алишларның батырлыкларын күз алдына бастыра торган оригиналь документлар.

Муса Җәлил һәм аның яшерен оешмасы турында өйрәнү нәтиҗәсендә Леон Небенцаль Германия Фәннәр Академиясендә «Муса Җәлил — шагыйрь һәм көрәшче» дигән гыйльми доклад белән чыга. Бу доклад бездә рус телендә һәм татар телендә басылып чыкты. Аның «Җәлилнең соңгы көннәре» исемле икенче мәкаләсе дә «Литературная газета»да русча һәм бездә татарча басылды. Бу мәкаләләр «Муса турында истәлекләр» китабында урнаштырылган.

Леон Небенцаль Муса Җәлилнең тормышы һәм көрәшенә багышлап диапозитивлар эшли һәм аның аннотациясен бастыра, газета-журналларда публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясый. Боларның барысын да автор Татарстан язучылар союзына тапшырды. Казанга килгәндә дә ул Муса Җәлилнең 60 еллык юбилеена әзерлекне истә тоткан, Муса турында яңа материаллар туплау, аның истәлегенә бәйле урыннарны күрү максатын куйган.



Татарстан язучылары
Казан аэропортында *Л. Небенцальне* каршыладылар.
Сулдан уңга — *М. Әмир, Г. Кашшаф, Л. Небенцаль* һәм *Ш. Маннур.*

**Леон Небенцаль, Казанга килгәч, Мусаның дуслары — язучылар белән очрашты. Муса яшәгән, эшләгән урыннарда булды. 26 нчы мәктәптә Мусага салынган һәйкәлне ул бик кызыксынып карады. Дәүләт музеендагы Муса Җәлилгә багышланган күргәзмә фондлары анда яхшы тәэсир калдырды. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры да аның игътибар үзәгендә булды.**

**Кунак В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында Ленин бүлмәсен карады.**

**Герой шагыйрь яшәгән шәһәрдә байтак урыннарда булганнан соң, Леон Небенцаль Муса Җәлилнең туган илендәге яңалыклар белән танышырга теләвен әйтте. Шул уңай белән Идел һәм Кама буйлап Чаллыга барды һәм Түбән Кама шәһәрендә химия комбинаты төзелешендә булды. Әлбәттә, «Дружба» нефтепроводы белән кызыксынды. Германия Демократик Республикасына барып җиткән «Дружба»ның башланган җирендә — Әлмәттә булды, инженерлар белән сөйләште.**

**Җәлил шәһәре Л. Небенцальнең игътибарын аеруча нык тарта иде. Кунак яңа типта салына торган, шагыйрьгә мәңгелек һәйкәл булачак ул шәһәрдә дә булды һәм үзенең аннан канәгать булып кайтуын әйтте.**

**Казаннан китәр алдыннан Леон Небенцаль телевидениедән чыгыш ясады. Үзенең чыгышында, Татарстанга килү һәм Татарстанның районнары белән танышырга мөмкинлек биргән өчен, Татарстан язучылар союзына рәхмәт әйтте һәм Муса Җәлил эзләре белән йөрүе турында кызыклы вакыйгалар сөйләде. Соңыннан ул Муса Җәлил юбилеена карата:**

**— Без, немец язучылары, Германия Демократик Республикасында бу датага нык-лап әзерләнәбез. Без Муса Җәлилне фашизмга каршы көрәштә үзебезнең союзнигыбыз итеп таныйбыз. Мин радио һәм матбугатта чыгышлар ясау өчен шактый бай материал җыйнадым, — диде.**

*Г. КАШШАФ.*

## В. И. ЛЕНИНГА һӘЙКӘЛ

Шушы елның июль аенда Казанда, «Теплоконтроль» заводы каршында, даһи юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинга һәйкәл салынды. һәйкәлне ачу тантанасына завод коллективы һәм киң җәмәгатьчелек җыелган иде.

— Без, — диде, митингны ачып, завод парткомы секретаре урынбасары И. М. Галиев, — завод территориясендә Владимир Ильич Ленинга салынган һәйкәлне ачу шатлыгын кичерү бәхетенә ирештек. Бу һәйкәл һәрберебезгә ленинча яшәргә, эшләргә һәм укырга кирәклеген хәтерләтеп торыр.

## МУСА ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕНА

1966 елның 15 февралендә атаклы шагыйребез, Ленин премиясе лауреаты, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең тууына 60 ел тула. Хәзер зур шагыйрьнең һәм ялкынлы көрәшченең юбилеен уздыру өчен әзерлек бара. Инде хәбәр ителгәнчә, СССР Язучылар союзы каршында Константин Симонов председательлегендә юбилей комиссиясе төзелде. Аның составына төрле милләтләрнең күренекле әдипләре, җәмәгать эшлеклеләре, газета-журнал редакцияләренең җаваплы работниклары кертелде.

КПССның Татарстан өлкә комитеты республикада шагыйрьнең туган көнен киң күләмдә билгеләү турында махсус карар кабул итте. Юбилейны әзерләү һәм үткәрү өчен республика комиссиясе төзелде. Аның составына түбәндәге иптәшләр керде: М. З. Тутаев — партия өлкә комитеты секретаре (комиссия председателе), Р. Ю. Ярмөхәметова — ТАССР Министрлар Советы председателе урынбасары, Мирсәй Әмир — Татарстан язучылар союзы правлениесе председателе, А. Б. Бадыйгов — профсоюзларның Татарстан өлкә советы председателе, Б. М. Гыйззәтуллин — культура министры, Н. Г. Җиһанов — Татарстан композиторлар союзы правлениесе председателе, Х. А. Якупов — РСФСР художниклар союзының Татарстан бүлеге правлениесе председателе, Гази Кашшаф — язучы, Шәйхи Маннур — язучы, Ш. Х. Хамматов — «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталары редакторы, Н. А. Андрианов — партия өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, А. Н. Гуляев — Казан дәүләт университетының рус әдәбияты кафедрасы мөдире, Ф. Г. Надыйров — ТАССР Министрлар Советы янындагы радиотапшырулар һәм телевидение комитеты председателе, В. С. Морозов — КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре, Р. К. Беляев — ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре, Г. К. Камалиев — Татарстан китап нәшрияты директоры.

Комиссия юбилейга әзерләнү һәм аны үткәрү планын эшләячәк. Газета һәм журнал редакцияләре, радиотапшырулар һәм телевидение комитеты юбилейга әзерлекнең барышын системалы яктыртып барачак. Муса Җәлил иҗатын һәм образын киң пропагандалаячак.

Партиянең шәһәр район комитетларына, культура һәм мәгариф министрлыкларына, профсоюзларның өлкә советына, ВЛКСМ өлкә комитетына юбилейга әзерләнү һәм аны уздыру буенча планнар эшләргә кушылды.

М. Җәлил юбилеен үткәрү шагыйрьне искә алып узу гына булмаячак. Бу уңайдан киң колачлы эш җәелдереп җибәреләчәк. Совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен, шул җөмләдән М. Җәлил иҗат иткән җәүһәрләрне халыкка җиткерү, хезмәт ияләрен эстетик яктан тәрбияләүгә билгеле бер өлеш кертү, бөек шагыйрьнең үлмәс батырлыгын күрсәтү аша өлкән буынның революцион-патриотик традицияләрен яшьләргә күчерү, халыклар дуслыгы һәм пролетар интернационализм идеяләрен пропагандалау әлеге юбилейга әзерләнү һәм аны үткәрүдә партия-комсомол оешмалары, иҗат союзлары, культура-агарту учреждениеләре, уку йортлары һәм мәктәпләр башкарачак күпьяклы эшнең төп юнәлешләре булып торачак.

## ИДЕЛ БУЕ ЖУРНАЛИСТЛАРЫ СЕМИНАРЫ

Июль аенда Казанда, КПСС өлкә комитетының политик мәгариф йортында, «Хәзерге заман православие һәм ислам диннәре» дигән тема буенча Идел буе журналистларының куст семинары булды. Семинарга Башкортстан, Чувашия, Мордовия, Мари, Удмуртия автономияле республикаларыннан, Пенза, Киров, Горький, Ульяновск, Куйбышев өлкәләреннән журналистлар килгән иде. Анда Татарстан республикасы газеталары һәм журналлары, радио

һәм телевидение, кайбер район газеталары һәм күптиражлы газеталарның журналистлары, уку йортлары укытучылары, «Белем» җәмгыяте лекторлары, партия органнары вәкилләре дә катнашты.

Семинарны кыскача кереш сүз белән КПСС өлкә комитеты секретаре иптәш М. З. Тутаев ачты.

Семинарда «Матбугатта фәнни-атеистик пропаганда» дигән темага «Наука и религия» журналының баш редакторы урынбасары Б. Т. Григорьян, «Коммунистик мораль һәм ислам диненең әхлакый өйрәтүләре» дигән темага философия фәннәре кандидаты Р. Г. Балтанов (Казан), «СССРда чиркәү һәм сектантлар матбугатын күзәтү» дигән темага Ленинградның дин һәм атеизм музее фәнни сотруднигы А. А. Осипов докладлары, «Хәзерге заманда дини сектантлык турында» «Политическое самообразование» журналының өлкән консультанты Е. В. Маята һәм «Идел буе матбугатында ислам диненә тәнкыйть» дигән темага Мәскәүнең фәнни атеизм йорты референты Э. З. Бәйрәмов һ. б. чыгышлары тыңланды.

Семинарда катнашучылар матбугатта атеистик пропаганда тәҗрибәсен уртаклаштылар, Казандагы Ленин истәлегенә бәйле урыннарны карадылар.

## ҮЗЕШЧӘН КОМПОЗИТОРЛАР СЕМИНАРЫ

Июль аенда Казан галимнәр йортында Татарстан районнарыннан һәм Горький өлкәсеннән килгән үзешчән композиторлар өчен 20 көнлек семинар оештырылды.

Семинарда музыка теориясе, композиция, нота укырга өйрәнү һәм хор турында лекцияләр укылды.

Танылган композиторларыбыз А. Ключарев, З. Хәбибуллин, музыка белгече М. Нигъмәтҗанов үзешчән композиторларның әсәрләрен тикшереп, аларның уңышлы язылганнарын сайлап алдылар һәм республикабыз матбугатында бастыру өчен тәкъдим итәргә булдылар.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Язучы Рөстәм Кутуй июнь аенда Горький, Чабаксар, Казан, Ульяновск һәм Куйбышев шәһәрләрендә «Идел Алжирга ага» дигән девиз астында уздырылган дуслык фестивалендә катнашты һәм анда үзенең яңа шигырьләрен укыды.

* * *

Шәһәребезнең Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркында драматург Риза Ишморатның «Давылга табан» исемле китабы буенча укучылар конференциясе булды. Китап сөючеләр авторның «Давылга табан» исемле драмасына карата үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар.

* * *

Казан гарнизонындагы хәрби частьта язучы Габдрахман Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» исемле романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Конференциядә катнашкан солдатлар «Мәңгелек кеше» романын яратып укуларын әйттеләр һәм авторга яңа иҗади уңышлар теләделәр.

* * *

Шагыйрьләрдән Мөхәммәт Садри, Нәби Дәүли, Әнвәр Давыдов, Роберт Әхмәтҗанов, Касыйм Фәсәхов һәм язучы Зиннәт Вәли, мехкомбинатның Культура сараенда үткәрелгән китап бәйрәмендә катнашып, мехкомбинат эшчеләренә үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары турында сөйләделәр һәм күп санлы сорауларга җаваплар бирделәр. Культура сараенда китап сату да оештырылган иде. Шагыйрьләр үзләренең китапларын алган китап яратучыларга автографларын бирделәр.

* * *

Өлкән язучы Идрис Туктар Чистай шәһәрендә һәм Чистай районы авылларында китап укучылар белән очрашып кайтты. Ул Мөслим мәктәбендә, Каргалы мәктәбендә һәм клубында, Баганалы мәктәбендә, Чистай шәһәрендәге педучилищеда, 2 нче номерлы мәктәптә, трикотаж фабрикасында чыгышлар ясады һәм үзенең «Ике егет» исемле романы буенча үткәрелгән укучылар конференциясендә катнашты.

* * *

Казанда яшәүче рус язучысы Софья Радзиевская Республика курчак театрында укучы балалар белән очрашты һәм аларга үзенең яңа әсәрләрен укыды.

* * *

Шагыйрь Зәки Нури, республикабыз районнарының культура бүлекләре мөдирләре семинарында катнашып, бүгенге татар әдәбиятындагы яңалыклар турында чыгыш ясады.

* * *

Казанда яшәүче рус язучысы Геннадий Паушкин һәм Мәскәү язучысы Юрий Щербак республикабызның Алабуга, Чистай һәм Түбән Кама районнарында булып кайттылар. Алар ул районнардагы әдәби түгәрәкләр эше белән таныштылар, түгәрәк членнарының әсәрләрен укып, яшь авторларга киңәшләр бирделәр.

* * *

Ленинградтагы «Ленфильм» студиясе герой шагыйрь Муса Җәлил турында тулы метражлы художестволы фильм эшләячәк. Шул уңай белән КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. З. Тутаев, язучы Гази Кашшаф һәм композитор Нәҗип Җиһанов, Ленинградка барып М. Җәлил турындагы фильмны эшләячәк иптәшләр белән сөйләшеп, киңәшеп кайттылар.

* * *

Шагыйрь Мостафа Ногман Пермь өлкәсендәге Бардым районында китап укучылар белән очрашты. Ул, Бардым, Сарыш, Япалчиха авылларындагы урта мәктәп укучылары һәм укытучылары алдында чыгышлар

ясап, үзенең яңа әсәрләрен укыды, хәзерге татар әдәбияты турында сөйләде, китап укучыларның сорауларына җаваплар бирде.

* * *

Балалар язучысы Әминә Бикчәнтәева Арча районындагы Әтнә һәм Күлле Киме мәктәпләре укучылары белән очрашты һәм яшь укучыларга үзенең яңа әсәрләрен укыды, киләчәккә иҗат планнары турында сөйләде.

* * *

Шагыйрь Мөхәммәт Садри, Арча районындагы әдәбият түгәрәге утырышында катнашып, түгәрәк членнарының яңа әсәрләрен тикшерде һәм яшь авторларга иҗади киңәшләр бирде.

* * *

Язучылардан Гариф Гобәй, Әнвәр Давыдов, Самат Шакир, Әминә Бикчәнтәева РСФСР өлкәләреннән һәм Татарстан районнарыннан Казан укытучылар белемен күтәрү институтына укырга килгән башлангыч мәктәп укытучылары белән очраштылар һәм үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары турында сөйләделәр.

* * *

Зәет Мәҗитов, Роберт Әхмәтҗанов, Нур Гайсин, Әминә Бикчәнтәева, Мостафа Ногман, Ян Винецкий «Совет укытучысы көне»ндә Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркында укытучылар алдында чыгыш ясадылар.

* * *

Зәки Нури, Мөхәммәт Садри, Илдар Юзиев һәм Габделхәй Сабитов «Ялкын» журналы редакциясендә Башкортстанның Кушнаренко интернат мәктәбе укучылары белән очраштылар. Очрашуда «Ялкын» журналының җаваплы секретаре И. Юзиев һәм әдәби сотруднигы Г. Сабитов укучыларны редакциянең эше белән таныштырдылар, хәзерге балалар әдәбияты турында сөйләделәр. Аннары З. Нури, И. Юзиев һәм М. Садри үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Риза Ишморат, Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова, Госман Бакиров, Казан укытучылар белемен күтәрү институтында укучы татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашып, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр һәм иҗат планнары белән уртаклаштылар.

* * *

Язучылардан Гариф Гобәй, Ләбибә Ихсанова, Хисам Камалов һәм Татарстан китап нәшриятының балалар әдәбияты редакциясе мөдире Кыям Миңлебаев Идел буе автономияле республикаларында һәм өлкәләрендә яшәүче балалар язучыларының Горький шәһәрендә үткәрелгән семинарында катнаштылар. Алар хәзерге чорда балалар әдәбиятының торышы һәм аны киләчәктә тагын да яхшырту чаралары турында фикер алыштылар, тәҗрибә уртаклаштылар.

* * *

Риза Ишморат, Башкортстанның Янаул районына барып, район китапханәсендә укучылар белән очрашу үткәрде һәм хәзерге татар әдәбиятындагы яңалыклар турында сөйләде, үзенең иҗат планнары белән уртаклашты, сорауларга җаваплар бирде.

## МУСА ҖӘЛИЛ ҺӘЙКӘЛЕ ПРОЕКТЫН ТИКШЕРҮ

Казанда, Кремль алдындагы мәйданда, Муса Җәлилгә һәйкәл куелачагы республика газеталарында игълан ителгән иде инде. Язучылардан Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Риза Ишморат һәм Мөхәммәт Садри Казан шәһәр Советының архитектура бүлегендә әнә шул һәйкәлнең проектын тикшерүдә катнаштылар һәм куелачак һәйкәлнең йөзе Муса Җәлилгә бик нык охшаш булырга тиеш, ә проектта ул аңа охшамаган дигән фикерне әйттеләр.

## КУРГАН ӨЛКӘСЕНӘ ЭКСПЕДИЦИЯ

Казан дәүләт университетының доцент Нил Юзиев җитәкчелегендәге фольклор экспедициясе быел Курган өлкәсенең татарлар яши торган Әлмән һәм Целинный районнарында булды. Беренче курсны тәмамлаган студентлар Тузау, Өчкүл, Әлмән, Мәһди, Иванково, Шәрип һәм Трехозерка авылларында бик күп сюжетлы җырлар һәм әкиятләр язып алдылар. Композитор Фоат Гарипов халык җырларын нотага язып алды.

Экспедициядә катнашучылар, үзләренең төп эшләре белән берләттән, колхозларның һәм совхозларның эшләре белән дә кызыксындылар. Җәйләүдә терлекчеләр арасында һәм колхоз, совхоз клубларында биш әдәбимузыкаль кичә үткәрелде. Бу кичәләрдә Нил Юзиев экспедициянең эше һәм максатлары турында сөйләде, бүгенге татар әдәбиятының торышына, язучыларның яңа әсәрләренә, «Казан утлары» журналының эшчәнлегенә киң тукталды. Шагыйрь Шәүкәт Галиев поэмадан өзекләр, лирик, юмористик һәм сатирик шигырьләр укыды. Композитор Фоат Гарипов тыңлаучыларны үзенең яңа язылган берничә әсәре белән таныштырды. Студентлар күңелле концерт куйдылар.

## ПЕТРОЗАВОДСК АРТИСТЛАРЫ КАЗАНДА

Июль аенда Казанда, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында, Петрозаводск музыкаль комедия театры гастрольләре булды. Бу — күлләр крае артистларының казанлылар белән беренче очрашуы иде.

Петрозаводск музыкаль комедия театрын яшь театр дип әйтергә мөмкин. Шушы елның көзендә ул үзенең унъеллыгын билгеләп үтәчәк. Дөресрәге, сугыш аркасында үз эшен туктатып торганнан соң аның яңадан оештырылуына ун ел тула.

Петрозаводск артистлары коллективы үз спектакльләрен Мәскәүдә һәм Ленинградта күрсәтте, яшьләрнең ике Бөтендөнья фестивалендә катнашты һәм чит илләрдә гастрольләрдә булды.

Театр Казанга Ф. Лоуның «Минем гүзәл ледием», И. Штрауcның «Чегән бароны», Ю. Милютинның «Чанита үбүе» исемле музыкаль комедияләрен, И. Кальманның «Көзге маневрлар», Ф. Легарьның «Шат күңелле тол хатын» исемле оперетталарын алып килгән иде. Шул әсәрләрдәге рольләрне башкаруда катнашкан Петрозаводск актерларыннан РСФСРның атказанган артистлары И. Гридчина, З. Эстрин, П. Паровишник, Карелия АССРның атказанган артистлары Н. Полагаева, А. Селезнев, балет солистлары — РСФСРның атказанган артисткасы С. Степанова, Карелия АССРның атказанган артистлары Е. Павлова, Ю. Сидоров, В. Мельников һәм якташларыбыз — РСФСРның атказанган артисты Мәхмүт Үтикәев, Рауза Сабироваларны Казан тамашачылары аеруча яратып кабул итте.

* * *

Литва ССРның дәүләт рус драма театры да шушы елның июль аенда Казанда гастрольдә булды. Кунаклар Казан тамашачыларына В. Маяковскийның «Кандала», Литва драматургы В. Милюнасның «Акчарлаклар озата», А. Кузнецовның «Хатынлы егет», грек драматургы Д. Псафасның «Ялганчы кирәк» комедияләрен, Ф. Н. Достоевскийның «Идиот» романы буенча эшләнгән инценировканы һәм В. Шекспирның «Кырыс кызны буйсындыру» әсәрен күрсәттеләр. Литва ССРның халык артистлары М. П. Миронайте, Б. А. Красильников, РСФСРның атказанган артистлары Ю. В. Тресняков, Л. П. Перфильева, А. Е. Карантаев, Л. Н. Риттер, Литва ССРның атказанган артистлары Н. И. Трусов, Б. П. Смельцов, В. М. Белицкий башкарган рольләрне тамашачыларыбыз аеруча яратып карадылар һәм, гомумән, Литва дәүләт рус драма театрының Казандагы гастрольләре зур уңыш белән үтте.

### «ЗУР ИДЕЛ» КҮРГӘЗМӘСЕ

Шушы елның 10 июленнән алып 30 июльгә кадәр Казанда, Татарстан АССРның сынлы сәнгать музеенда, Идел буе художникларының күчмә күргәзмәсе булды. Күргәзмәгә «Зур Идел» күргәзмәсендә катнашкан 150 дән артык авторның 250 ләп иң яхшы әсәрләре куелган иде. Алар арасында РСФСРның халык художнигы Х. Якупов, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Л. Фәттахов, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Н. Кузнецов, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе В Кудельки**н**, Горький художнигы, «Революция солдатлары» дигән бик яхшы картина авторы В. Холуев, Волгоград художнигы О. Карташев, Куйбышев художнигы Г. Филатов һ. б. әсәрләре бар иде. Күргәзмәдә графикага да зур урын бирелгән иде.

Республикабыз тамашачылары «Зур Идел» күчмә күргәзмәсен яратып карадылар.

## РӘШИДОВ-ҖАМАНАКЛЫ

Озакка сузылган каты авырудан соң, шушы елның 1 августында, СССР Язучылар союзы члены, коммунист шагыйрь һәм галим Кәрим Рәшид улы Рәшидов-Җаманаклы үлде.

Кәрим Җаманаклы 1905 елның 21 январенда, Кырым өлкәсенең Ак шәех районында, Җаманак авылында, урта хәлле крестьян семьясында туган. Авыл мәктәбендә башлангыч белем алганнан соң, комсомол эшләренә актив катнаша башлаган яшь егет Кәрим 1924 елда Симферополь педагогия техникумына укырга китә. Техникумны тәмамлагач, авыл мәктәбендә укыта, ә 1929 елдан башлап Симферополь педагогия институтының тарих-филология факультетында укый.

1927—1930 елларда «Ирек җырлары», «Балаларга Ленин турында», «Анам җыры» исемле шигырь җыентыклары чыккан Җаманаклы аспирантурада кала һәм институтта әдәбият дәресләре алып бара.

1935 елдан башлап Кәрим Җаманаклы әдәбият фәнни-тикшеренү институтында әдәбият һәм фольклор секторы мөдире булып эшли һәм 1937 елда филология фәннәре кандидаты исемен ала.

Кәрим Җаманаклының Кырым татар халык иҗатын өйрәнүгә багышланган һәм 1933—1941 елларда басылып чыккан гыйльми хезмәтләре арасында «Әдәбият һәм әдәбиятны өйрәнү терминнары», «Шагыйрь Гомәр Ипчи», «Халык җырлары», «Әйтемнәр һәм мәкальләр», «Кырым татар халык әкиятләре» исемле китаплары бар.

Бөек Ватан сугышы башлану белән ул Совет Армиясе сафына китә һәм 1941—1942 елларда немец-фашист илбасарларына каршы сугышларда катнаша.

1944 елда СССР югары белем министрлыгы аны Сәмәрканд педагогия институтына рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасына доцент итеп эшкә җибәрә.

1945 елда Кәрим Җаманаклы Татарстанның Алабуга педагогия институтына кайта. Ул шунда соңгы көннәренәчә рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасы мөдире булып эшләде.

Бер үк вакытта Рәшидов-Җаманаклы иҗат эшен дә дәвам иттерде, ул «Совет әдәбияты» журналында даими язышып килде, герой шагыйрь Муса Җәлил иҗатын өйрәнеп монография чыгарды, 1950 елда «Лирик шигырьләр» җыентыгын бастырды.

Коммунист шагыйрь һәм галим Кәрим Рәшидов-Җаманаклының нурлы истәлеге аның каләмдәшләре күңелендә озак еллар сакланыр.

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ.

## Алдагы саннарда:

Ш. Маннур. Муса романының дәвамы.

С. Баттал. Чирмешән буйларында. Шигъри роман.

Ә. Маликов. Татарстан егетләре Себердә. Очерк.

Х. Хәйри. Бүгенге романнарыбызның жанр үзенчәлекләре. Әдәби тәнкыйть мәкаләсе.

Р. Мостафин. Ф. Хөснинең «Бертуган Таһировлар» пьесасы турында мәкалә.

Яшь шагыйрьләр иҗаты.

Әдәбият тарихына материаллар.

Китап күзәтү.

Сатира һәм юмор әсәрләре.

*Җәүдәт Фәйзи* музыкасы
*Габдрахман Әпсәләмов* сүзләре

# ГӨЛШАҺИДӘ ҖЫРЫ

*(Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романыннан)*

**Сызлама, әрнемә юксынып, йөрәгем,**
**Сагынып, саргаеп өзелмә, үзәгем.**
**Мәхәббәт бер генә, килми ул гел генә,**
**Карлыгач шикелле кичекми һәр язда.**

**Ак күңел, пакъ күңел, бу кадәр ярсыма,**
**Тилереп, шашынып дөньяны тарсынма.**
**Син чыда барсына, сөюең хакына,**
**Ул килер, баш ияр бер заман каршыңда.**

**Хәзергә белми ул, хәзергә күрми ул.**
**Янганың, көйгәнең гел аның утында.**
**Җил исә тын гына, ай йөзә моң гына,**
**Күңелдә ул гына, йөрәктә ул гына.**


Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники,**
**Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский,**
**Сибгат Хәким, Нил Юзиев.**

Производствога бирелде 8/VII-1965 ел. Басарга кул куелды 16/VIII-1965 ел. ПФ 08144. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 20500 экз. Заказ Л-927. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1965 ел.

# ГӨЛШАҺИДӘ ЖЫРЫ



Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73367

*Ежемесячный литературно-художественный*
*и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ